# Хөрмәтле дуслар!

Менә гомеребезнең тагын бер елы үтеп китте. Кызганыч ки, ул бик авыр булды һәм шатлыкларга күмелеп тормады. Әлбәттә, моның сәбәпләренең берсе – яхшы хәбәрләрнең бик аз булуы. Сугыш, санкцияләр, чикләүләр, чирләр, бәяләрнең күтәрелүе...

Боларның барысы да тормышыбызга сөенеч өстәми шул. Шулай да, ул дәвам итә, һәм без якты киләчәккә өметләнәбез. Башкача мөмкин түгел! Бигрәк тә, кечкенә шатлыклар барыбер булды бит. Нindиләр, дисезме? Һәркемнең үз куанычы.

Мәсәлән, без октябрьдә журналыбызның 11 еллыгын һәм “Самар татарлары” сайтының 10 еллыгын билгеләп үттек. Чынлыкта, бүгенге заманда массакүләм мәгълүмат чаралары өчен бу – лаеклы уңыш.

Юбилейлар уңаеннан уздырылган зур бәйрәм турында басма битләреннән укырсыз. Шулай ук милләттәшебез – Рамил Гыйззәтуллин белән танышырсыз. Ул, заманага туры килгән, табышлы бизнес оештырып, үзенең партнеры белән бу турыда китап та язган! Сөенеч түгелме!

Узып баручы ел президентыбыз тарафыннан “Укытучы һәм остаз” елы дип игълан ителгән иде. Мөгаллимнәр алдында без һәрчак баш иябез һәм алар турында “Самар татарлары”нда еш язып торабыз. Бу юлы да укытучылар - Красный Яр районында гомер итүче, 100 яшен тутырган Дәрия Гайнуллина, Гали авылыннан Нәфия Муллабаева һәм шул ук авыл мәктәбе директоры Фидаил Маннанов турында мәкаләләр урнаштырдык.

Алда безне 10 көнлек кышкы каникуллар көтә. Ял вакытында сезгә укырга мәгълүмат булсын, дип, журналны бай эчтәлекле ясарга тырыштык. Һәрбер кеше биредә үзенә кызыклы язманы, һичшиксез, табачак!

Киләчәк Яңа ел белән сезне, кадерлеләрем! Ул безгә күбрәк куанычлар китерсен.



**Данияр СӘЙФИЕВ,**
*“Самар татарлары” журналы мөхәррире*

# Дорогие друзья!

Вот и пролетел еще один год нашей с вами жизни. Год очень непростой и далеко не радостный. Одна из причин тому, конечно же, нехватка позитивных новостей. Войны, санкции, ограничения, инфекции, рост цен... Всё это, как-то мало вселяет в нашу обыденность оптимизма. Тем не менее жизнь продолжается и мы не перестаем верить в светлое будущее. А как же иначе?! Тем более что проблески радости, несмотря ни на что, всё равно случаются. Какие? У каждого они свои. Мы, например, в октябре отметили 11-летие журнала и 10-летие сайта «Самарские татары». В современных реалиях для средств массовой информации – это, я считаю, достойное совершеннолетие. О том, каким классным был этот праздник, вы узнаете на страницах этого номера. А еще мы вас познакомим с Рамилем Гизатуллиным, который не только смог выстроить современный высокодоходный бизнес, но и написал вместе со своим партнером об этом книгу. Тоже ведь радость!

Уходящий год был объявлен нашим президентом Годом педагога и наставника. Учителя, перед которыми мы всегда склоняем головы, и без этого всегда были героями наших публикаций. А в этот раз мы решили рассказать об учителях – Дарии Гайнуллиной из Красноярского района, отметившей свой 100-летний юбилей, Нафие Муллабаевой из Алькино и директоре школы из этого же села Похвистневского района Фидаиле Маннанове.

Учитывая, что впереди целых 10 дней новогодних каникул, этот номер журнала мы постарались сделать насыщенным на материалы. Уверен, каждый найдет в нем что-то интересное для себя. Будьте с нами!

С Новым годом вас, дорогие, и побольше радостей в новом, 2024 году!

РЕДАКЦИОННЫЙ СОВЕТ

**Шакуров Ильяс Гумерович –**
президент СОТО «Туган тел»; председатель правления НКО «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области», член Общественной палаты г.о. Самара

**Хазиев Артур Ахатович –**
председатель Центра Стратегических Исследований «Платформа XXI»

**Сайфиев ДаниярИрекович –**
гл. редактор журнала «Самар татарлары» («Самарские татары»)

**Нуретдинова Римма Равильевна –**
главный редактор сайта samtatnews.ru

**Вакказов Расих Ахметшамилович**
имам-хатыб мечети «Булгарское наследие»

**Ибятова Ляйсян Замиловна –**
член Совета СОТО «Туган тел»

**Надиров Азат Камилович –**
член Совета СОТО «Туган тел»

**Сафин Иршат Халилович –**
старший имам-хатыб Соборной мечети г. Самары

**Хузин Ривгат Туктарович –**
председатель комиссии Общественного совета при ГУ МВД России по Самарской области

**Мифтахов Искандер Фуадович –**
член Совета СОТО «Туган тел»

**Рамазанова Гюзяль Ибрагимовна –**
директор СОТО «Туган тел»

**Юсупов Рамиль Закряриевич –**
член Совета СОТО «Туган тел»

**Юсупов Фагим Ханифович –**
член Совета СОТО «Туган тел»

РЕДАКЦИОННАЯ КОЛЛЕГИЯ

**Биктаев Наиль Данисович**
**Варфоломеева Эльмира Мугаммаровна**
**Галимов Шамиль Хайдарович**
**Мифтахов Искандер Фуадович**
**Файзуллов Рустам Ильясович**
**Салахова Лилия Акрямовна**
**Ширияздaнов Фарид Хамитович**
**Шарипов Руслан Кабирович**

# Содержание:


Парад 7 ноября в «запасной столице»: от истоков к сегодняшнему дню. 6
I Вагыйзов укулары....10
Утыз Имәни нәселе шәҗәрәләре ....15
Гали авылы мәктәбе директоры: “Ышанычлы терәгем булган хезмәткәрләрем – үзенә бер бәхет” ....23
Мөгаллимә дип язылып куелган аның йөрәк түрендә!....28
Илдар Камалтдинов: “Ил өстенә афәт килгәндә, бердәм булырга кирәк”....34
Кешеләр китә, ләкин алар урынына хәтер кала! Эшләре, игелеге, изгелеге кала! ....37
Охотники за возможностями, или Как провинциальным «уставшим банкирам» удалось создать федеральный бизнес ....39
Бер гасыр гомер. Азмы ул, күпме?....44
Без прошлого нет достойного будущего ....46
Дружба народов и журналов....52
Главбух с двумя медалями «За отвагу» ....65
«Первый» двух райкомов....73
Сөю – мәңгелек!....88
Султан Бейбарс. Раб, ставший правителем Египта и оплотом ислама ....91
Дастаннар - халыкның рухи мирасы сагында торучы борынгы әсәрләр... 94
Россия – родина сионизма....97
Жиренә житкереп эшләгәндә генә, жир дә уңышын мул бирә....101
Байтуганның данлы, горур, тугры бер улы ....105
Спорт – это самый лучший жизненный мотиватор ....110
Сайту – 10. Журналу – 11. ....114
Яхшы сүз күңелгә май булып ята....116
Онытылмас бәйрәм мизгелләре....118
Полувековое служение сцене....120
Мөнәҗәтләр – халыкның җан авазы....131
Вәсимә Фәрдиева “Заманы”....136
Как остановить травлю по национальному признаку?....140
Крылатый символ года....143
О некоторых особенностях башкирских свадебных традиций в прошлом и настоящем....145
Наилә Хөсәенова: “Шигырьләрем, сезгә мин җан өрдем...” ....148





13 ХВОРОСТЯНКА ТАТАРЛАРЫ ЖЫЕЛГАН ЖИРДӘ





50 «ЗАКОН ПАССИОНАРНОСТИ» ОТКРЫТ НА БАЗЕ ИССЛЕДОВАНИЯ ИСТОРИИ ДРЕВНИХ ТЮРКОВ





99 ТУГАН ЖИР ИЗГЕ, ТУГАН ЖИР ГАЗИЗ





56 ЧУВСТВИЛИЩЕ СВОЕЙ СТРАНЫ



## Уважаемые друзья!

***Приобрести журнал «Самар татарлары» можно по следующим адресам:***

- **Самара, ул. Революционная, д. 142 (магазин «Кулинария на Революционной»)**
- **Самара, пр. Кирова, 206 (бывшее здание «ИПОЗЕМбанк»),**
- **Самара, ул. Стара Загора, 54 (в магазине внутри Соборной мечети).**

**Стоимость текущего номера с доставкой – 300 рублей, стоимость номеров за 2022 год – 300 рублей, все предыдущие номера – по 700 рублей.**

**Доставка журналов по Самаре – тел.: 8-937-64-044-77.**



Издатель «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области», адрес: 443087, Самарская область, г. Самара, пр. Кирова, 206, оф. 28

**Главный редактор:** САЙФИЕВ Данияр Ирекович
**Корреспонденты:** Миляуша ГАЗИМОВА, Фарид ШИРИЯЗДАНОВ, Шамиль ГАЛИМОВ, Рашид ШАКИРОВ, Нурсина ХАКИМОВА
**Дизайн-макет, верстка:** Александр ГОРБАЧЕВ, Юрий ШВЕЦ
**Фото:** Миляуша ГАЗИМОВА, Анис МИНГАЛЕЕВ
**Корректоры:** Миляуша ГАЗИМОВА, Вадим ОЛЕНИН

**Адрес редакции:**
443087, Самарская область, г. Самара, пр. Кирова, 206, оф. 28
**Телефон редакции:** 8-917-104-44-45
**Электронная почта:** samartatarlary@bk.ru
**www.samtatnews.ru**

**Отпечатано в ООО «СЛОВО»,**
443070, Самарская область, г. Самара, ул. Песчаная, 1, офис 310, тел. (846) 267-36-82

**Журнал «Самар татарлары»** («Самарские татары»), № 4 (41), октябрь–декабрь, 2023 г.
**Учредитель:** «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области»
Журнал зарегистрирован Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций по Самарской области. Свидетельство о регистрации СМИ: ПИ №ТУ63 – 00628 от 15.10.2013 г.
Дата выхода 26 декабря 2023 г.
Тираж 1000 экз. Цена свободная



## **КАМИЛА ВАЛИЕВА** ПОБЕДИЛА НА ЭТАПЕ ГРАН-ПРИ В МОСКВЕ, ДОПУСТИВ ДВА ПАДЕНИЯ

Камила Валиева выиграла шестой этап Гран-при России по фигурному катанию в Москве.

*tatar-inform.ru*

Олимпийская чемпионка начала свою произвольную программу на арене в «Мегаспорте» с падения с четверного прыжка. Далее последовали чистые тройной флип в тройке с двумя двойными акселями, каскад риттбергер-тулуп, тройной сальхов, тройные лутц-тулуп и тройной флип. После этого она неожиданно упала с тройного лутца.

Судьи оценили выступление Валиевой в 144,95 балла. По итогам двух дней это первое итоговое место.

Второе место заняла Вероника Яметова. Фигуристка из Свердловской области смогла сохранить позицию, которую занимала после короткой программы. В произвольном прокате Яметова допустила помарку на двойном акселе, поэтому судьи чуть снизили ее оценки. Всего за два соревновательных дня она набрала 212,75 балла.

Главная соперница Валиевой – Софья Муравьева упала с тройного акселя, после чего пыталась повторить прыжок, но снова не смогла выполнить триксель. Фигуристка ошиблась также в наборе элементов, нарушив правила соревнований. В связи с этим судьи поставили ей два «дедакшена» и ученица «Ангелов Плющенко» осталась третьей.

Напомним, ранее Валиева заняла четвертое место на этапе Гран-при в Казани, а Муравьева – выиграла.

Итоговое положение фигуристок:

1. Камила Валиева – 226,22
2. Вероника Яметова – 212,75
3. Софья Муравьева – 210,25
4. Ксения Синицына – 205,15
5. Ксения Гущина – 201,00

## В ПОДМОСКОВЬЕ ОТКРЫЛИ ПАМЯТНИК ПЕВЦУ РЕНАТУ ИБРАГИМОВУ

На Волковском мусульманском кладбище в Московской области открыли мемориал народному артисту Ренату Ибрагимову. Мероприятие приурочено к памятной дате – 20 ноября певцу исполнилось бы 76 лет.

*tatar-inform.ru*



На памятнике на двух языках написали любимую фразу артиста: «Совершенствуя себя, мы совершенствуем душу. И наоборот...». Сам монумент был создан по мотивам из его автобиографии «По морю жизни».

Кроме семьи и друзей Ибрагимова в церемонии приняли участие вице-премьер Татарстана – полпред РТ в России Равиль Ахметшин, первый заместитель председателя Совета муфтиев России Рушан хазрат Аббясов и глава Автономии татар Москвы Фарит Фарисов.

Напомним, что народный артист умер 14 мая 2022 года. Ему было 74 года.

21 ноября в Москве пройдет концерт в память о Ренате Ибрагимове. Его самые известные композиции исполнят московские и татарстанские артисты под аккомпанемент оркестра Росгвардии.

## ВЫШЕЛ НОВЫЙ ТАТАРСКИЙ КАЛЕНДАРЬ

1 декабря вышел татарский календарь памятных дат и событий на 2024 год.

Настольный перекидной календарь является ежегодным приложением к журналу «Самар татарлары» («Самарские татары»). Он включает в себя юбилейные даты известных представителей татарского народа, даты проведения светских и религиозных праздников, справочную информацию о религиозных и образовательных учреждениях, действующих на территории Самарской области, контакты администраций татарских сельских поселений, перечень национально-культурных общественных организаций, национальных СМИ, сайтов и многое другое. В этом году его создатели дополнили издание информацией о выдающихся татарских мыслителях, национальных традициях, народными пословицами и поговорками.

Красочный и информативный татарский календарь издается в Самаре с 2015 года. Над его созданием трудятся известные краеведы и журналисты. Среди них – Шамиль Хайдарович Галимов, Рашид Мигдэтович Шакиров, Данияр Ирекович Сайфиев. Финансовую поддержку подготовки и издания календаря ежегодно обеспечивают президент Самарского областного татарского общества «Туган тел» («Родной язык») Ильяс Гумерович Шакуров и директор магазина «Кулинария на Революционной» Равиля Гумеровна Киямова. В разные годы он издавался тиражами от пяти до десяти тысяч экземпляров. На этот раз из-за возросшей стоимости типографских услуг тираж календаря ограничился тремя тысячами экземпляров.




Календарь был и остается замечательным подарком для тех, кто ценит историю и культуру татарского народа, чтит национальные и религиозные традиции. Экземпляры календаря бесплатно передаются в школы и региональную библиотечную сеть. Отрадно, что некоторые предприниматели приобретают календарь небольшим оптом для раздачи сотрудникам своих предприятий и организаций, а жители часто берут его для раздачи в качестве садака. От имени создателей календаря всем им хочется сказать огромное спасибо, так как это помогает не только частично компенсировать понесенные затраты, но и дает возможность все большему количеству людей приобщиться к своим корням, узнать что-то новое о своих земляках и в целом о своем народе.

*Приобрести календарь можно по следующим адресам:*

- *Самара, ул. Революционная, д. 142 (магазин «Кулинария на Революционной);*
- *Самара, пр. Кирова, 206 (бывшее здание «ИПОЗЕМбанк»);*
- *Самара, ул. Воронежская, 9, к. 305 (редакция газеты «Бердэмлек»).*

## «НӘНИ ШӘКЕРТ» ЯЗУ ДӘФТӘРЕ ЧЫККАН

Татар федераль милли-мәдәни автономиясе, «Нәни шәкерт» дип аталган язу дәфтәре чыгарып, аны Россиянең татарлар яши торган регионнарына тараткан.

*tatar-inform.ru*



«Татар теле укытучыларына һәм тәрбиячеләренә ярдәмлек итеп язу дәфтәре әзерләдек. Әлеге кулланма татар алфавитын матур итеп язарга өйрәтә», дип хәбәр итә Татар федераль милли-мәдәни автономиясе. Проект Татарстан Республикасы гранты хисабына тормышка ашырылган.

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы 2020 елда үткәргән мониторинг буенча, Россиянең 28 субъектындагы 1077 мәгариф учреждениесендә татар телендә уку һәм татар телен предмет буларак укыту оештырылган, якшәмбе мәктәпләре эшли. Калган 57 субъектта татар теле укытыла торган балалар бакчалары да, мәктәпләр дә юк. Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Россия Федерациясендә яшәүче татарларга ярдәм итүне үз эшчәнлегендә өстенлекле юнәлеш итеп саный, дип ассызыклана хәбәрдә.

«Нәни шәкерт» язу дәфтәре Татарстаннан читтәге татарларга ирештерү өчен бастырылган. Хәзерге вакытта язу дәфтәре почта аша Россиянең 46 регионына таратылган. Барлык материаллар да интернетка урнаштырылган. Аларны күчереп алырга мөмкин.

«Мондый кулланмаларны күпме генә бастырсаң да, кемгәдер җитми калырга мөмкин. Шуңа без аны интернетка урнаштырдык. Теләгән һәр кеше аны үзе күчереп алырга мөмкин», – ди Татар федераль милли-мәдәни автономиясенең башкарма директоры Миләүшә Шәрәпова.

Кулланма төсле рәсемнәр белән бизәлгән, кызыклы биремнәр, шигырьләр урнаштырылган. Бу уку процессын күңелле уенга әверелдерергә мөмкинлек бирә.



## В ТАТАРСТАНЕ БАНКИ НАЧНУТ ОТКРЫВАТЬ «ИСЛАМСКИЕ ОКНА»

В Татарстане банки начнут открывать «исламские окна», клиенты которых получат исламское партнерское финансирование. Об этом представители банковского бизнеса рассказали на круглом столе в Агентстве инвестиционного развития РТ. Помимо республиканских кредитно-финансовых учреждений в проекте примет участие Сбербанк.

*tatar-inform.ru*

«Хочу сказать про наши ближайшие планы. Это открытие офисов в мусульманских республиках: Дагестане, Чечне и Башкортостане. Также мы хотим открыть офисы «Мираса» в Москве и Астрахани. Еще планируется создать выделенные «исламские окна» в отделениях «Мир Бизнес Банка», – сказал заместитель гендиректора – управляющий дополнительным офисом «Мир Бизнес Банка» в Казани Вакили Сейед Саид.

Для повышения качества обслуживания клиентов «Ак Барс Банк» планирует запустить «исламские окна» в офисах нового формата, которые называются «Лучше». В планах открыть «исламские окна» в Казани, Москве и Уфе, рассказал руководитель направления исламского банкинга «Ак Барс Банка» Марат Садриев.

Сбербанк также планирует открыть офисы нового формата, где можно будет воспользоваться продуктами исламского банкинга. Они будут расположены в регионах, которые участвуют в эксперименте наряду с Татарстаном. Аналогичный офис уже работает в Казани.

## В ПЕНЗЕ ОПРЕДЕЛИЛИ ОБЛАДАТЕЛЬНИЦУ ТИТУЛА «ТАТАР КЫЗЫ – ПЕНЗА 2023»

*Татарская автономия Пензенской области*



25 ноября 2023 года, шесть финалисток областного конкурса красоты и таланта «Татар кызы – Пенза 2023» блестяще дефилировали на подиуме, задорно исполняли национальные танцы, пели песни. Всех их объединяла любовь к семейным традициям и ценностям.

В этом году мероприятие проводилось в рамках культурно-просветительского марафона «Счастливая семья – будущее страны». На протяжении всего конкурса девушки проходили различные этапы и мастер-классы по кулинарному искусству, рукоделию, навыкам ухода за детьми для будущих мам, а также занимались с педагогами по хореографии, вокалу и художественному слову.

Итоги конкурса оказались захватывающими, и каждая из финалисток получила заслуженное признание и награду. Обладательницей титула «Мисс Привлекательность» («Иң сөйкемле кыз») стала Ильвина Абдуллина, «Мисс искренность» («Иң ихлас кыз») стала Дина Чуйкина, «Мисс Очарование» («Иң ягымлы кыз») – Ания Мамлеева, «Мисс Скромность» («Иң тыйнак кыз») стала Алсу Казаева, «Мисс Изящество» («Иң нәфис кыз») стала Камиля Дашкина, «Мисс Творчество» («Сәләтле кыз») стала Алсу Качаева.

Мисс «Татар кызы – Пенза 2023» стала Камиля Дашкина.

1-й вице-мисс «Татар кызы – Пенза 2023» стала Ания Мамлеева.

2-й вице-мисс «Татар кызы – Пенза 2022» стала Ильвина Абдуллина.

Обладательницей приза зрительских симпатий стала Камиля Дашкина.

Несмотря на 5 конкурсных заданий в режиме нон-стоп, все конкурсантки выступали так, что зрители получали истинное удовольствие от происходящего на сцене.

Организатором конкурса выступила Региональная общественная организация «Татарская национально-культурная автономия Пензенской области».

# ИНСТИТУТ ИСТОРИИ МАРДЖАНИ ПРИСОЕДИНЯЮТ К АКАДЕМИИ НАУК ТАТАРСТАНА

Институт истории имени Шигабутдина Марджани, Центр перспективных экономических исследований и Научный центр безопасности жизнедеятельности станут частью Академии наук Республики Татарстан.

*milliard.tatar*




Премьер-министр республики Алексей Песошин подписал постановление Кабинета министров Татарстана о присоединении этих государственных учреждений к Академии наук РТ.

Это решение было принято с целью улучшения координации и развития потенциала научных исследований, а также эффективного использования государственного имущества Республики Татарстан.

На проведение реорганизации учреждений отведено 90 дней, а контроль за исполнением постановления возложен на отдел высшего, среднего профессионального образования и науки Аппарата Кабмина РТ.

# В ЯКУТСКЕ ОТКРЫЛИ КАЗАНСКИЙ СКВЕР И ПАМЯТНИК ТАТАРСКОМУ ПОЭТУ МУСЕ ДЖАЛИЛЮ

*ysia.ru*

В Якутске состоялось торжественное открытие Казанского сквера и бюста великого татарского поэта, воина, Героя Советского Союза Мусы Джалиля. Новое общественное пространство создано возле Якутского художественного училища.

В мероприятии приняли участие руководство республики и делегация Татарстана во главе с заместителем премьер-министра республики, председателем Национального совета Всемирного конгресса татар Василем Шайхразиевым.



Решение о возведении сквера было принято в начале 2022 года, а летом того же года в рамках Дней Татарстана в Якутии был установлен символический камень на месте будущего Казанского сквера с участием президента республики Татарстан Рустама Минниханова.

# АНВАР ГОРЛАНОВ ВНОВЬ ИЗБРАН ПРЕДСЕДАТЕЛЕМ

1 декабря в самарском Доме дружбы народов прошло отчетно-выборное собрание татарской национально-культурной автономии Самарской области. Областная татарская автономия успешно действует с 2009 года, является структурной единицей Федеральной национально-культурной автономии татар Российской Федерации и коллективным членом Всемирного конгресса татар. Председатель исполкома автономии избирается один раз в пять лет. Предыдущие два срока эту должность занимал Анвар Имранович Горланов. На состоявшемся в пятницу собрании единогласным голосованием было решено продлить его полномочия на следующие пять лет.



Самарские татары
Самар татарлары

## ! ПЛАНИРУЕТСЯ ИЗДАНИЕ СПЕЦИАЛИЗИРОВАННЫХ ВЫПУСКОВ

Известно, что в Самарской области татары работают в различных отраслях экономики. Начиная с 2024 года журнал «Самар татарлары» планирует начать выпускать специализированные приложения о наших соплеменниках, сумевших успешно проявить себя в различных профессиональных сферах. Пока рассматривается выпуск изданий «Татары в культуре и искусстве», «Татары в медицине», «Татары в образовании», «Татары в СМИ», «Татары в спорте», «Татары в строительстве», «Татары в торговле». Каждый из жителей может предложить своих героев для публикаций или тему для очередного спецвыпуска. Приглашаем рекламодателей и спонсоров!

**Предложения принимаются по тел. 89171044445 или на E-mail: samartatarlary@bk.ru**



Парад памяти 7 XI
Куйбышев-Самара
Запасная столица

*«Гитлер о Москву сломает*
*не только свои хищные зубы,*
*но и свой хребет», –*
*из выступления Маршала Советского Союза К. Ворошилова на параде 7 ноября 1941 г. в Куйбышеве*

# ПАРАД 7 НОЯБРЯ В «ЗАПАСНОЙ СТОЛИЦЕ»: ОТ ИСТОКОВ К СЕГОДНЯШНЕМУ ДНЮ



**Фарит Мубаракшевич Мухаметшин,**
заместитель председателя Комитета Совета Федерации по международным делам, представитель от исполнительного органа государственной власти Самарской области



Осень 1941 года, фашистские войска подступают к советской столице, немецкая пропаганда уже празднует победу, убеждая весь мир, что роковой час для СССР предопределен. Некоторым тогда казалось, что сил для сопротивления уже не осталось. Именно в этот момент возникала объединяющая и вдохновляющая всех сограждан страны и воинов Красной Армии идея – провести 7 ноября 1941 года парад в честь очередной годовщины Октябрьской революции. Парад было решено провести сразу в трех городах – Москве, Воронеже и Куйбышеве. Как показало время, это решение было своевременным и очень символичным, оно сплотило всех без исключения граждан в каждом уголке необъятной страны.

Верховный главнокомандующий Вооруженными силами СССР Иосиф Сталин, выступая на параде Красной Армии в Москве 7 ноября 1941 года, заявил: «Враг рассчитывал на то, что после первого же удара наша армия будет рассеяна, наша страна будет поставлена на колени. Но враг жестоко просчитался… вся наша страна, организовалась в единый боевой лагерь, чтобы вместе с нашей армией и нашим флотом осуществить разгром немецких захватчиков».

Уже к этому моменту город Куйбышев (ныне Самара) указом Государственного Комитета Обороны от 15 октября 1941 года стал «запасной столицей», куда были переведены многие советские наркоматы и правительственные учреждения, а также иностранный дипломатический корпус.

Готовить и принимать парад в Куйбышеве было поручено Маршалу Советского Союза Клименту Ворошилову – «первому красному офицеру», легендарному военачальнику Гражданской войны, ближайшему соратнику И. Сталина. Парад нужно было провести так, чтобы показать всему миру несломленный дух советского народа и рьяную готовность до последнего сражаться за Родину.

Именно парад в Куйбышеве стал самым масштабным и вошел в летопись Великой Отечественной войны, став неотъемлемой частью мировой истории и ярким примером единения нашего народа перед лицом суровых испытаний. О значимости парада для поднятия духа на борьбу с вероломным врагом можно судить по судьбоносным выступлениям его участников.

Гостями парада на трибунах в ноябре 1941 стали члены дипкорпуса, военные атташе, иностранные корреспонденты из более чем более 20 стран, на которых парад произвел неизгладимое впечатление.

Украшением парада в Куйбышеве стала его воздушная часть – над







городом пролетело от 600 до 700 боевых самолетов преимущественно новых типов. В пешем, конном строю и с мехколонной прошло свыше 25 600 человек. Еще 178 тысяч жителей «запасной столицы» прошли в колонне демонстрантов. Эти цифры просто впечатляют. Ведь, если только задуматься, почти каждый третий житель Куйбышева прошел в тот день в парадных колоннах.

При этом, если московский парад 1941 г. был самым коротким в истории и продолжался всего 25 минут, то куйбышевский длился более полутора часов, и еще больше часа шла демонстрация трудящихся. Из воспоминаний очевидцев и участников парада мы знаем, что большинство подразделений вышли в полном боевом снаряжении, так как сразу после него отправлялись на самые сложные участки фронта, включая Московский, Калининский, Волховский и др.

22 ноября – через две недели после «демонстрации сил» в Куйбышеве –премьер-министр Великобритании Уинстон Черчилль писал Иосифу Сталину: «Когда война будет выиграна, в чем я уверен, мы ожидаем, что Советская Россия, Великобритания и США встретятся за столом конференции победы как три главных участника и как те, чьими действиями будет уничтожен нацизм». С похожим посланием к Сталину обратился президент США Рузвельт.

День 7 ноября 1941 года навсегда останется в истории нашей страны как одна из наиболее ярких



страниц, описывающих стойкость духа и волю к победе. Из воспоминаний очевидца парада Василия Савельева, которому тогда было 17 лет: «Промаршировали слаженные колонны солдат, появились самолеты, проехали танки… Парад продолжался полтора часа! А уже на следующий день все эти войска бросили на оборону Москвы. После этого парада мы снова пошли в военкомат проситься на фронт, и нас отправили под Москву». Особенно важной оказалась эта страница и для истории Самары-Куйбышева. В дань этому эпохальному событию появилась новая городская традиция – Парад Памяти.

Проект «Парад Памяти», посвященный истории военного парада, является одним из самых масштабных патриотических событий как Приволжского федерального округа, так и страны в целом. Впервые Парад Памяти прошел в Самаре в 2011 году и с тех пор стал визитной карточкой региона.

С 2018 года, когда губернатором региона был избран Дмитрий Азаров, проект «Парад Памяти» стал одним из важнейших мероприятий в календаре памятных дат нашего региона. Впечатляющий по своим масштабам Парад Памяти прошел в 2018 году, основной темой было «Оружие Победы». Участие в нем приняли представители 13 делегаций иностранных государств, среди них 5 послов. Всего по площади













Куйбышева прошло 104 парадных расчета: часть из них были историческими, часть – военными.

Оргкомитет каждый год подходит к подготовке Парада Памяти творчески, «не для отчета, не для галочки, а сердечно, в память об этом знаменательном событии». При этом главная цель Парада остается неизменной – продемонстрировать, какой значимый вклад наш регион внес в общую Великую Победу. «Парад Памяти должен подчеркнуть преемственность поколений, показать, что и сегодня мы готовы к решению самых масштабных задач... Провести его на самом высоком организационном уровне важно для нас. Считаю, это дело чести», – подчеркивал глава региона в 2018 г.

Парад Памяти 2019 года прославлял солдатскую славу и был посвящен живому Герою СССР 3-й ударной армии, бойцы которой водрузили Знамя Победы над Рейхстагом, участнику легендарного парада 7 ноября 1941 года в «запасной столице», Владимиру Чудайкину. В том же году впервые в рамках Парада Памяти состоялся «марш юнармейцев». В 2020 году в связи с пандемией состоялся первый Всероссийский онлайн-парад. В 2021 году отмечалось 80-летие присвоения статуса «запасной столицы» и легендарного военного Парада 7 ноября, а ключевые памятные мероприятия также состоялись в онлайн-формате.

В 2022 году Парад Памяти вновь вернулся на площадь Куйбышева и прошел под лозунгом «Дорога Победы». Вместе с парадными расчетами Вооруженных сил Российской Федерации, а также юнармейских отрядов из всех регионов Приволжского федерального округа по площади Куйбышева впервые прошли представители Донецкой Народной Республики. Всего в Параде Памяти приняли участие более 8 тысяч человек, и еще более 10 тысяч прошли по площади в колонне представителей городов и районов Самарской области.

В этом году Парад Памяти вновь прошел на площади Куйбышева. По величественной площади нашего города парадным маршем прошли потомки тех, кто защищал страну от немецко-фашистских захватчиков, ковал в тылу оружие Победы, освобождал страны Европы, подарил мир будущим поколениям.

Участие в параде приняли представители всех регионов Приволжского федерального округа, а также гости из Дагестана и Донецкой Народной Республики, в том числе юнармейцы из Снежного – города-побратима Самарской области, чьи отцы сегодня отстаивают свободу и независимость в зоне СВО. Впервые в «Параде Памяти» принял участие парадный расчет из города-героя Брест Республики Беларусь.

Почти 7 тысяч человек прошли торжественным маршем по площади Куйбышева. В составе 125

расчетов – представители подразделений силовых структур, военно-учебных центров, ветеранских и патриотических общественных организаций, промышленных и оборонных предприятий, высших учебных заведений, юнармейских отрядов, кадетских классов. В прохождении парадных расчетов также было задействовано 35 единиц исторической техники времен Великой Отечественной войны.

Губернатор Самарской области Дмитрий Азаров, обращаясь к участникам парада, отметил, что 7 ноября – это годовщина особенного, памятного события. «Это день, который стал символом мужества, единства и твердости духа нашего народа перед лицом смертельной опасности. Парад 7 ноября 1941 года в Куйбышеве сыграл особую роль в разгроме немецко-фашистских войск под Москвой и в целом – в ходе Великой Отечественной войны, – напомнил глава региона. – В самые трудные месяцы войны он продемонстрировал всему миру несокрушимую мощь Красной Армии, основанную на беззаветной любви к Родине, гранитной твердости характера, яром неприятии нацизма».



Губернатор подчеркнул, что в каждой семье есть свои Герои. И потому тема Парада Памяти 2023 года – «Герои и подвиги» – живо откликается в сердце каждого, и всех объединяет стремление сделать все для Победы.

За годы своего проведения Парад Памяти стал поистине народным символом сплочения людей разных возрастных и социальных групп, национальностей и вероисповеданий, политических партий и движений. Это дань памяти нашим героям, навеки вписавшим свои имена на страницы истории Великой Победы.

Сегодня с учетом целей и задач специальной военной операции, как вынужденного ответа на коллективные усилия ряда стран Запада по разрушению России, Парад Памяти приобретает особое значение. Как говорил Президент России Владимир Путин на Параде Победы 9 мая 2023 года: «Против нашей Родины вновь развязана настоящая война, но мы дали отпор международному терроризму, защитим и жителей Донбасса, обеспечим свою безопасность». Это действительно так, ведь сейчас подобно тому, как и в годы Великой Отечественной войны, коллективными усилиями пытаются нанести стратегическое поражение нашей стране, лишить ее суверенитета и права на самостоятельный выбор.

Парад Памяти олицетворяет связь времен и поколений, напоминая нам о несгибаемой воле и непоколебимой силе сплоченного народа, давшего решительный отпор фашизму. Парад Памяти – это не просто важное патриотическое мероприятие, это уникальный момент единения, когда мы вместе чтим всех тех, кто отдал свои жизни за свободу и независимость нашей Родины. Каждый раз, когда я пишу или говорю о событиях Великой Отечественной войны, перед глазами всегда мои родители – Мубаракша Мухаметшин и Рокия Хайруллина – которые прошли через горнило этой трагедии и вернулись с Победой!

Пусть звуки марша парадных расчетов разносятся на тысячи километров, а сердца участников наполняются гордостью за наших доблестных героев, включая тех, кто по примеру своих великих предков с честью отстаивает свободу нашей Родины сегодня! Пусть Куйбышевский парад навсегда останется в наших сердцах и в памяти будущих поколений, чтобы никогда не забывать о тех, кто, пожертвовав многим, даровал нам надежду на будущее!









***7 ноябрьдә Г. Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2023/24 уку елына календарь планы нигезендә татар "Әлифба"сы авторы Вагыйзов Сәләй Гатат улының 115 еллыгына багышланган I Республикакүләм Вагыйзов укулары үткәрелде.***

***Нурания Абзалова***



# I ВАГЫЙЗОВ УКУЛАРЫ

Педагог, галим, методист, 40тан артык методик дәреслек, фәнни хезмәтләр, башлангыч сыйныфлар өчен методик кулланмалар авторы, Татарстанның атказанган укытучысы, Россиянең халык мәгарифе отличнигы, К. Насыйри премиясе лауреаты, К. Д. Ушинский медале иясе Сәләй Гатат улы Вагыйзовның исемен таныту; педагогик, методик мирасын саклау һәм үстерү максатыннан оештырылган әлеге чарада Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы вәкилләре, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, Казан (Идел буе) федераль университеты, Уфа фән һәм технологияләр университетының Стәрлетамак филиалы галимнәре, Самар өлкәсе делегациясе, урта һөнәри, төп гомуми һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмалары педагоглары һәм студентлар катнашты.

Конференция кысаларында пленар һәм секция утырышлары узды, анда катнашучылар С. Г. Вагыйзовның педагогик һәм методик мирасы турында фикер алыштылар, "Әлифба"ның тарихи әһәмиятен дәлилләделәр.

Пленар утырыш кысаларында М. Г. Әхмәтов, И. Г. Һадиуллин, И. А. Сәгъдиев, К. З. Хәмидуллина, Н. А. Мөкимова, Н. М. Абзалова катнашында панель дискуссиясе узды, педагогик хезмәткәрләргә ведомство бүләкләре тапшырылды.

Конференциядә катнашучылар бертавыштан Сәләй Гатат улы Вагыйзовның һәм Рәмзия Гыйләҗ кызы Вәлитованың фәнни һәм методик мирасы һәрьяклап өйрәнелергә тиеш, дигән фикер белдерделәр.

Кунакларны, иң беренче булып, Арча районы башлыгы Илшат Нуриев, аннан соң Татарстанның Дәүләт советы рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, Республика мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин сәламләделәр. Уфа дәүләт университетының Стәрлетамактагы филиалында татар һәм чуаш телләре кафедрасы мөдире, доцент Илсур Мансуров һәм доцент Нәфисә Мөкимова әлеге чарада Рәмзия Вәлитованың якташлары буларак катнаштылар һәм аның нәсел тамырлары турында бәян иттеләр.

– Арчада, Татарстанда һәм башка төбәкләрдә Рәмзия Вәлитованы «Әлифба» һәм башка китапларның соавторы буларак беләләр. Бездә, Стәрлетамакта, аның белән һәркем горурланырга тиеш, – дип сөйләде Нәфисә Мөкимова.

Аларның Вагыйзовлар йортында булып, киленнәре белән сөйләшүе, фотоархивлары белән танышулары киләчәктә Рәмзия ханым белән танышу өчен, исемен күтәрү өчен, ныклы этәргеч булыр, дип белдерде Илсур Мансуров.

Стәрлетамак шәһәрендә 7 Ноябрь урамы бар. Менә шул урам XX гасыр башына кадәр Большая Татарская дип аталган. Менә шул урамның 56 нчы кварталында Вәлитов Гыйләҗетдин Мәҗит улы хатыны Зөһрә, 3 уллары - Әбделкадыйр, Әбделкәрим, Мостафа һәм кызлары Рәмзия белән яшәгәннәр. Менә шул кыз, 8 яшендә ятим калып, Стәрлетамак балалар йортында үсә. Легендар һәм үлемсез татар «Әлифба»сының автордашы була.

Башта әле бу гаиләгә күпме сынаулар аша узарга туры килгән бит. Программаның беренче өлешендә, башка чыгышлар белән бергә, Гүзәл Әдхәмнең «Әлифба» авторларына, аларның гыйбрәтле ачы язмышына багышлап язылган «Меңнәрнең берсе» дип аталган әсәреннән өзек сәхнәләштерелде. Аны караганда залда еламаган кеше калмагандыр. Рольләрне студентлар бик оста итеп башкардылар. Искиткеч катлаулы тормыш юлы узган яшь Сәләй һәм Рәмзия ролен башкару бик катлаулы, минемчә.

Аннан соң, Сания Әхмәтҗанова үзенең «Гыйлем алиһәсе – «Әлифба» шигырен укыды һәм укытучылары Сәләй Гатат улы белән Рәмзия Гыйләҗ кызы турында истәлекләре белән уртаклашты. Остазлар турында җылы истәлекләрен Татарстанның халык укытучысы Камария Зиннуровна Хәмидуллина да сөйләп узды. Камария ханым бездә, Байтугандагы «Әлифба» музеенда, ике тапкыр булды.



Рәсимә Равиловна Шәмсетдинова да Арча көллиятендә озак еллар директор вазифаларын башкарган, «Әлифба» авторларының гаилә дуслары - Илдус Абдрахманович Сәгъдиев та бик эчтәлекле чыгыш ясады. Аның сүзләренчә, әгәр шушы 12 сынау елы узарга туры килмәгән булса, алар диссертация дә яклаган булырлар иде. Ул аларны «халык академиклары» дип атады.

Олы яшенә карамастан (аңа 87 яшь), Илдус Абдрахманович Сәләй Вагыйзов музеенда кунак булды.

Камышлы мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Тамара Фанзыловна Хисмәтова һәм мин дә шушы зур чарада катнаштык. Анда минем Сәләй ага белән беренче һәм соңгы тапкыр очрашуым, аның безне бик дулкынланып каршы алуы, ике ятимне ничек итеп Арча җылы каршы алганны сөйләгәннәре, безне озатканда туган йортын сорашулары тагын бер кат хәтеремдә яңарды да, күзләрем кайнар яшьләр белән томаланды. Безнең белән очрашудан соң улы Камил абыйга: «Авылдашларым килеп, минем гомеремне озынайттылар. Бу минем иң бәхетле көнем булды», – дип әйткән булган.

Бу юлы мин Арчага уникенче тапкыр бардым, бик күп чараларда катнашырга насыйп булды миңа монда. Кыска гына бер җөмлә белән: «Рәхмәт сиңа, Тукайлы, «Әлифба»лы, мәрхәмәтле, кунакчыл Арча!» Арча халкының шулкадәр югары дәрәҗәдә бәйрәмнәр оештыра белүләренә барган саен сокланып кайтам. Арчага барган саен Сәләй аганың нигезенә дога кылып кайтам. Уллары Камил аганың вафатына өч ел тулып килсә дә, киленнәре Лилия апа мине бик җылы каршы ала. Аны монда һәрбер бәйрәмгә чакырмыйча калмыйлар, бик хөрмәт итәләр.

Лилия апай бик кунакчыл, быел да музеебызга китаплар җыеп куйган. Кайткач, ачып карасам, китаплар арасында безнең «Бердәмлек» газетасы да бар. Моны күреп, бик куандым. 1992 һәм 1994 елларда газетада Радик Фәизов Сәләй ага турында бик эчтәлекле мәкалә бастырган булган. Ул вакытта «Туган тел» оешмасы эшләп килгән. Уйлыйм-уйлыйм да, туган тел белгеченә карата нигә шундый салкынлык, игътибарсызлык булды икән, дигән сорау туа. Радик Фәизов мәкаләсендә бик яхшы язылган бит Сәләй аганың халкы өчен күпме көч куйганы. Милләтнең тамыры – тел, тел ачкычы – «Әлифба». Туган телнең дәрәҗәсен күтәрүне шул вакытта ук башларга кирәк булган, минемчә. Мәктәп балаларына легендар якташларын, чын



бөек шәхесне танытырга булган. Ә «Туган тел» оешмасы әгъзаларына Сәләй ага белән очрашырга, элемтәдә торырга булган. Ул елларда ук Казан – Самар аралашуы башланган булган бит. Архив китаплары арасында Зыя Ярмәки, Рөстәм Мингалим, Гадел Кутуй китаплары да бар. Якташларыбыз бит...

Кунакларның барысы да музеййортыбыз турында сораштырдылар. Күбесе аны күргән, күрергә теләүчеләр дә күп икән. Аллаһыга шөкер, музеебыз ишекләре ябылып тормый. Күренекле шәхеснең туган авылы белән танышалар, беренче зал – Сәләй Вагыйзов белән Рәмзия Вәлитовага багышланган, икенчесе – бу җирлектә яшәгән милләтләрнең дуслык йортын бик кызыксынып карыйлар, элекке кием-салым, эш кораллары үсеп килүче буынны әби-бабаларының авыр тормышы белән таныштыра. Дөрес тәрбия бирү өчен, уйланыр өчен бик файдалы, минемчә.

Мәктәп укучылары күренекле «Әлифба» авторлары турында төрле фәнни проектлар язалар. Хәтта Яр Чаллы, Лениногорск, Самар шәһәрләрендә яшәүче укучылар да әлеге темага фәнни эш яздылар. Мин аларга бик теләп ярдәм итәм, билгеле. Алар, музейга килеп, шәхесләребезнең кием-салымнарын, кулъязмаларын, китапларын үз күзләре белән күреп, кирәкле материал туплап, фотоларга төшеп китәләр.

Никах яки туй көннәрендә музеебызга яшь парларның килүе дә матур гадәткә әйләнеп бара. Әйтеп үтәргә кирәк: бу татар милләтеннән булган парлар гына түгел, башка милләт кешеләре дә бик еш киләләр. Бик кыскача гына булса

да, Сәләй ага белән Рәмзия ханымның искиткеч авыр сынаулар узып та, гаиләләрен, мәхәббәтләрен саклап калулары турында сөйләп узарга тырышам. Безнең музеебызда туй көннәрендә кунак булган беренче пар - Филат белән Гөлия Мингалиевлар хәтта кызларына, «Әлифба»дан алып, Әминә исемен кушканнар.

2024 елны Владимир Путин «Гаилә елы» дип игълан итте. Шушы уңайдан, яңа гаиләгә нигез салган көнне музейда кунакта булган парларны Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көнендә, тагын бер кат чәйгә чакырып, алар өчен матур чара оештырырга планлаштырам.

Ел саен «Туган телнең туган көне»н уздырабыз. Үткән елда икенче сыйныф укучысы Риналь Гарипов, «Туган тел» шигырен укып, онлайн бәйгедә I дәрәҗәле дипломга лаек булды. Балалар өчен «Беләсеңме син авылың тарихын һәм аның шәхесләрен» дигән конкурс уздырабыз. 9 майда – Җиңү көнен, 22 июньдә хәтер көнен билгеләп үтәбез. Музей көнен, Музей төнен, Белем бәйрәмен, Укытучылар, Өлкәннәр көнен, сугыш ятимнәре белән очрашулар, күпсанлы күргәзмәләр оештырабыз. Балаларны «Самар татарлары», «Сөембикә», «Салават күпере» журналлары белән таныштыру кичәләре, Бал һәм чәй бәйрәме үткәребез. Гомеренең 50 елын укытучы һөнәренә багышлаган мөгаллимә өчен юбилей кичәсе уздырдык. Музей-йортыбызда дини бәйрәмнәр дә күп оештырабыз. Корбан табыннары, ифтар ашлары, Мәүлид бәйрәме, шәхесләребезне искә алу көннәре, барысын да Раббыбыз кабул итсен, рухлары шат булсын.

18 ноябрьдә музей-йортыбызга 7 ел булды. Шушы гомер эчендә бездә ике яшьтән алып 90 яшькәчә 17000нән артык кеше кунак булды. Алар арасында – 22 фәннәр кандидаты, 8 – профессор.

I Вагыйзов укулары катнашучыларына музей-йортыбыз тормышы турында тәфсилләп сөйләдем, көнкүрешебез белән та-



ныштырдым. Кунакларга «Самар татарлары» журналларын бүләк иттем. Анда Дамир Тазиевнең «Остаз һәм укучы» дигән язмасы басылган иде. Чарада катнашучылар аны бик кызыксынып укыдылар. Оештыручыларга Сәләй аганың туган авылы - Байтуган сурәтләнгән картина бүләк иттем.

I Вагыйзов укулары, һич тә онытылмаслык чара булып, күңелемдә мәңге сакланачак. Бәйрәм югары дәрәҗәдә әзерләнгән, кунакларны шулкадәр зурлап каршы алдылар, андагы җылы очрашулар... Мин Гүзәл Әдхәм белән аралаштым. Ул музеебызны бик күрергә теләве турында әйтте.

Конференция азагында резолюция кабул ителде. Вагыйзов укулары киләчәктә өч елга бер үткәреләчәк һәм «Әлифба» авторларының милли казанышларын мәңгеләштерүгә юнәлтеләчәк. Бу карарны укыганда, күңелем тулып китте һәм Рәмзия ханымның «Әлифба»га багышланган шигъри юллары исемә төште:

*«Әлифба, Әлифба –*
*син минем юл башым,*
*Син белем илендә*
*иң якты кояшым...»*

Кичәдә Рәзил Исмәгыйлевичны да искә алдылар. Барысының да урыннары җәннәттә булсын.

Өйгә кайтканда, юл буе бу шәхесләребезнең татар халкының тарихында нинди тирән эз калдырганнары турында уйландым. Алар мәңгелек данга күмелеп яшәргә тиешләр. Бу - безнең изге бурычыбыз!



**Искәрмә:** Лилия ханым биргән китаплар арасында Сәләй Вагыйзовның кулъязмалары, көндәлекләре дә бар. Анда искиткеч тирән мәгънәле язмалар күп. Сокландыргыч - бу сүзләрне Сәләй ага 92 яшендә язган бит! Язмалар арасында, Рәмзия ханымга багышлап, 1937 елда язылган «Мәңгелек бүләк» дигән шигыре дә килеп чыкты.

## Мәңгелек бүләк

*Хисләремнең артык якынлыгын*
*Сиздермичә йөрдем,*
*Түзмәдем:*
*Мәңгелеккә калып яшәсен, дип,*
*Иң кыйммәтле бүләк эзләдем.*
*Табалмадым. Инде эзләмим дә,*
*Мин бит аны күптән тапканмын!*
*Син булган яшьлек дуслыгымның*
*Мәңге сүнмәс утын якканмын.*
*Энҗеләрдән торган бүләкләр*
*Дуслык булып, мәңге калалмас,*
*Йөрәктән чыкмаса, ул йөрәктә*
*Сөю хисе булып яналмас!*
*Еллар үтеп, чәчләр агарса да,*
*Яшьлек дәртен миндә табарлар,*
*Гөлләр корып, утлар сүнсәләр дә,*
*Сиңа булган хисләр янарлар.*

***Сәләй Вагыйзов.***
*1937 ел, 29 яшь.*

# ХВОРОСТЯНКА ТАТАРЛАРЫ ҖЫЕЛГАН ҖИРДӘ

*11 ноябрьдә район үзәгендә Татар халык мәдәнияте көне узды.*

*Чарага хворостянкалылар гына түгел, җирле татарларның өлкә авылларында һәм шәһәрләрендә яшәүче туганнары һәм дуслары да килгән иде. Мөхтәрәм кунакларны — район башлыгы В.А. Маховны, Самар өлкәсенең авыл хуҗалыгы министры урынбасары Р.М. Насыйрованы һәм башка кунакларны ипи-тоз белән каршы алдылар.*

*Клара ГАЛИМҖАНОВА*
*Сергей ТАЛЮК фотосурәте*



Татар бәйрәменә килгән кунакларны район башлыгы сәламләде. “Бүгенге чара – дуслык һәм аңлашучанлык, бер-беребезне хөрмәт итү бәйрәме ул, – дип билгеләп үтте Виктор Алексеевич Махов. – Шушы болганчык заманда, төрле милләт халыклары арасында дошманлык ялкыны кабызып җибәрүчеләр күбәйгән чакта, безнең регион тынычлык һәм дуслык мохитында яши. Бу - иң мөһиме. Бүгенге бәйрәмдә без хезмәт кешеләрен зурлаячакбыз, нәкъ алар



Хворостянка районы тормышын бай һәм сыйфатлы итүгә зур өлеш кертәләр. Татарларны – оешкан, дус, тәртипле һәм укымышлы халык дип беләбез. Алар мәдәният, мәгариф, сәламәтлек саклау һәм авыл хуҗалыгы өлкәләрендә җаваплы белгечләр булып танылдылар».

Район башлыгы иң эре агрохолдинг җитәкчесе Гамәл Замальтдиновның эшен югары бәяләде. Ул, Новокуровка авылындагы сөтчелек комплексын торгызып, халыкка сыйфатлы сөт продукциясе, эш биргән. Аның кырлары югары уңыш белән куандыра, чәчүлекләр әйләнешенә чирәм җирләр дә кертелә бара. Аның акчасына Хворостянкада менә дигән мәчет төзелгән.

Виктор Алексеевич Хворостянка районы эшчәнлегенә, татар мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен саклауга зур өлеш керткән татарларны – Ринат Курмакаев, Гөлнур Курмакаева, Рифкать Куряев, Наилә Мортазина, Мәзгуть Рәфыйков, Сәмия Рахмаева, Гөлнур Алиева, Аббас Әюпов, Гөлфия Аширова, Зөлфия Батова, Ришат Бигеев, Венера Доронина һәм Ринат Сулиховны Мактау грамоталары һәм Рәхмәт хатлары белән бүләкләде.

Ә иң югары бүләк –“Хворостянка районы алдындагы казанышлары өчен” күкрәк билгесенә Хворостянка мәктәбе укытучысы



Кадрия Абушаева лаек булды. Кадрия Хәйдәровна – кырык еллык педагог стажы булган хөрмәтле укытучы, җәмәгать эшлеклесе, татар халкы гореф-гадәтләрен саклап яшәүче, ике баласы һәм биш оныгында да шушы кыйммәтләрне тәрбияли алган ана һәм әби. Абушаевлар – Әфганстанның утлы юлларын узган Фәрит Мөнир улы һәм Кадрия Хәйдәр кызы бик матур тормыш юлы үткәннәр. Нинди генә хәл килеп чыкса да, туганнары һәм дуслары, ярдәм сорап, Абушаевлар-

га киләләр һәм беркайчан ярдәмсез китмиләр, аларны буш кул белән чыгарып җибәрмиләр.

Якташларын шушы бәйрәм белән котлап, Кадрия Хәйдәровна шундый матур чара үткәрелүе өчен район башлыгына рәхмәтләрен әйтте, туган телендә яхшы сүзләр, моңлы җырлар ишетү мөмкинлегенә бик сөенде.



Самар өлкәсенең авыл хуҗалыгы министры урынбасары вазифаларын вакытлыча үтәгән Розалия Насыйрова зур дулкынлану белән тамашачыларны татар телендә котлады.

– Милләтебез тамырларын белергә, тарихыбызны һәм мәдәниятебезне сакларга, телебезне өйрәнергә, ата-бабаларыбызның гореф-гадәтләрен онытмаска тиешбез. Биредә яшәүче башка милләт халыклары да үз милләтен шулай ук сакласа һәм хөрмәт итсә, без аңлашып яши алачакбыз. Бердәмлектә көч булуын беркайчан да онытмыйк!

Якташларын мөселманнар советы рәисе Рәшит Алиев һәм Хворостянка мәчете имамы Рәфыйк Рахмаев та котладылар һәм Самар өлкәсенең Диния нәзарәте рәисе, мөфти Талип хәзрәт Яруллинның котлау адресын халыкка җиткерделәр.

Тантаналы өлешне йомгаклау өчен сәхнәгә мәдәният идарәсе җитәкчесе һәм чараның алып баручысы С.А Пичугин чыкты:

– Рус һәм татар халкы, гасырлар буе бергә яшәсәләр дә, һәрберсе үз телен, мәдәниятен, милли кием үзенчәлеген саклап кала алган. Бу бик шәп! Без дә балаларыбызга мәдәният һәм тел байлыгын, үз милләтләребезгә генә хас орнаментларны, җыр-моңнарны, бизәнү әйберләрен, аш-су төрлелеген тапшырып калдырырга тиешбез. Алар да, үз чиратында, милли кыйммәтләребезне оныкларыбызга тапшырсыннар. Уртак илебездә дуслык җепләре нык булсын иде.

Бәйрәмнең икенче – күңел ачу өлеше ике сәгатьтән дә артыграк барды, бугай. Татарстанның атказанган җырчысы Раяз Фасыйховның көчле һәм моңлы тавышы тамашачыларны тәмам әсир итте. “Сәйдәш” хореографик коллективының дәртле биюләре, виртуоз-баянчы Ильяс Шәрипов моңнары һәм алып баручы, солист һәм пародист Әбри Хәбриевның мәзәкләре татар җыр-моңына сусаган милләттәшләребезнең күңелләренә май булып ятты.

Өлкәннәр артистларны алкышлаган, Раяз Фасыйхов белән җырлашкан, ә кайберләре хәтта биеп тә киткән арада тәмам ачыккан бала-чагалар фойеда тәмләшкәләр булуын сиземләп алганнар һәм бер-бер артлы фойе ишеге артына килеп югала башладылар. Сөбханаллаһ! Өстәлләр татар халкының милли ризыкларыннан сыгылып тора икән! Чарага килгән һәр татар гаиләсе үзе пешергән татар ашларын алып килгән. Бәйрәм атмосферасы шулкадәр җылы һәм аралашу өчен җиңел булды, әйтерсең лә биредә күптән күрешмәгән бер гаилә әгъзалары җыелган иде.



# УТЫЗ ИМӘНИ НӘСЕЛЕ ШӘҖӘРӘЛӘРЕ

***Бер ел элек, 2022 елның 25 ноябрендә, Лениногорск районының Тимәш авылында ачык һавада күренекле якташыбыз, шагыйрь, мәгърифәтче, фикер иясе Габдеррәхим Утыз Имәнинең мемориал музее ачылды.***

***Ямаева Әлфия Фәрит кызы***
***Төбәк тарихын өйрәнүче, конструктор хезмәте ветераны***
***Әлмәт шәһәре***

18–19 гасырларда ул татар халкының үзаңын үстерүдә, аны укымышлы, фикерле итүдә зур көч куя. Ярты гасырдан артык мәдрәсә шәкертләренә гыйлем бирә. Соңгы 25–30 елын Тимәш авылында яши. Тимәш авылы элек Самар губернасы, Бөгелмә өязенә караган. Хәзер Татарстан Республикасының Лениногорск районына керә.

Музей ачылышында Казаннан Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе В.Шәйхразыев, Лениногорск районы җитәкчесе Р.Хөсәенов, Әлмәттән депутат Р.Шәфигуллин, Чаллыдан профессор Ә.Шәрипов, нәсел туганнары, Тимәш авыл җирлеге җитәкчеләре, авылдашлары һәм башкалар катнашты. Бу эшне оештыруда башлап йөрүче авыл депутаты Айрат Габидуллин булды. Ул, депутат буларак, авылны төзекләндерү фикерләре белән янып йөри: тротуарлар ясау, төнлә урамнарны яктырту, туристларны җәлеп итү... Нияте – бөек якташы Габдеррәхим Утыз Имәни исемен, мирасын халыкка киң тарату, аны популярлаштыру, тарихны искә төшерү. Шул исәптән аның тырышлыгы белән Утыз Имәни сүзләрен эшкәртеп язылган "Тугры дус" җыры иҗат ителде. Утыз Имәни сүзләрен безгә аңлаешлы итеп эшкәртүче – Башкортостан шагыйре Р. Ш. Нурмөхәммәтова.



Кабер ташы төрбә эчендә



Тимәш зиратында Утыз Имәни төрбәсе.



Габдеррәхим Утыз Имәни (1752-1835)

Көен Э. Р. Шиһапов язды. Башкаручысы – Равил Галиев. Әлеге җыр "Фикерләрне пакьләндерүче файдалы киңәшләр" поэмасыннан, "Табылган тугры дусның кадерен белү кирәклеге" турындагы бүлегенә ияреп язылды. Бу җырны, "Тугрыдус" дип язып, ютубта тыңларга мөмкин. Анда ике ролик: Равил Галиевның җыры һәм Э.Шиһаповның көй язу процессы.

Тагын бер айдан (минем тәкъдимем белән) Тимәштә Утыз Имәни иҗатына багышланган конференция узды. Анда галимнәр, район җитәкчеләре, төбәкчеләр, укытучылар, укучылар, туганнары катнашты. Мәктәптә Утыз Имәни турындагы мәгълүматларны тирәнәйтү, ныгыту, иҗат мирасы белән танышуны дәвам итү, сөйләм әдәбиятын өйрәнү, уйлау, фикерләү сәләтен үстерү, милли горурлык хисе тәрбияләү максатыннан һәртөрле дәресләр узды. Укучылар саф татар телендә аның тормыш юлы, әсәрләре, дини эшчәнлеге турында һәм шигырьләрен сөйләделәр. Мин, сәхнәдән шәҗәрәләрнең кемгә, нигә



Тимәштә Мемориал музей. 2022.



Җитәкчеләр Мемориал музей ачылганда. 25.11.22.

кирәген, ничә шәҗәрә буласын сөйләп, аны ясау ысулларын өйрәттем.

Җыелышып яңа төзелгән мемориал музеена бардык. Аннары кемдер, каршыдагы авыл мәчетенә кереп, намаз укыды, кемдер, каберстанга барып, аның каберен зиярат кылды. Конференциянең пленар өлеше Тимәш авылының Мәдәният йортында дәвам итте. Анда мин Утыз Имәнинең нәсел шәҗәрәләрен сөйләдем. Түбәндә язылганнар шул чыгышымнан. Анда сөйләгән чыгышларны җыентык итеп бастырып чыгардылар. Мин моны бик кирәкле гамәл, дип саныйм.

Аның исеме үзе исән чагында ук һәм аннан соң да укучыларга яхшы таныш. Октябрь революциясенә кадәр К.Насыйри, Ш.Мәрҗани һәм Р.Фәхреддиннәр аны югары бәяләп калдырсалар, соңрак Ү.Беляева, М.Госманов, Ә.Шәрипов, Р.Әдһәмов, М.Кемпер һәм башкалар тарафыннан әдипнең эшчәнлеге төрле яктан тикшерелде. Шәхсән миңа Утыз Имәни, Р.Фәхреддин һәм Ш.Мәрҗани хезмәтләре шәҗәрәләрем аша төбәкчелеккә кереп китәргә этәргеч һәм үрнәк булдылар. Идел Болгарстанында рәсми Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү уңаеннан һәм Казанда Утыз Имәни мәчете ачылу тантанасына миннән аның шәҗәрәсен төзүемне сорадылар. Шул уңайдан эшләнгән эшем бу. Утыз Имәнине якташыбыз, дип әйтсәк тә, урынлы булыр, чөнки аның туган авылы Яңа Кади Әлмәттән 100 чакрымда гына, ә яшәгән Тимәше 50 чакрымда. Гомумән, Лениногорск төбәге Утыз Имәнинең нәсел шәҗәрәсендә төп нокталарның берсе булып тора. Карендәшләре тирә-ягыбызда яшиләр, төбәкчеләр арасында да алар бар.

Ул шагыйрь, фикер иясе, филолог, педагог. 1788–1798 елларда Бохара, Кабул якларында гыйлемен арттыра, укый, укыта.

Шәрыкъ әдәбиятын үзләштереп, аларны татар мәдәниятенә кертә. Ул тапкыр сүзле, көчле характерлы шәхес була. Татар, гарәп, фарсы телләрендә яза, таҗик, үзбәк, рус телләрен белә. 100дән артык хезмәтенең яртысы педагогик, гыйльми хезмәт: сүзлек, шәрех, белешмәләр, библиография, медицина, астрономия, сәүдә, икътисад турында. Шуңа философия, дин тәгълиматы, 10 поэмасы өстәлә. Мирасында төп урынны әдәби әсәрләре алып тора: "Замананың укымышлылары", "Замананың мөһим хәлләре", "Читтә йөрүче гарибләргә бүләк", "Бурыч – дуслыкны кисү кайчысы"... Утыз Имәни үз иҗатында дин мәсьәләләре белән бергә әхлак, үгет-нәсихәт проблемаларын да күтәрә. Татар әдәбиятында, дини үгетләүдән тыш, фикерне социаль проблемаларга юнәлтүдә эшли. 1839 елда басылган "Кыйссаи Йосыф" китабының дөрес, җыйнама текстын булдыра.



А.Габидуллин кунакларны каршы ала. 21.12.22.



Тимәштә конференция оештырырга тәкъдим итү.



Шәҗәрәдә үзеңне табу куанычлы.



Күренекле якташыбыз белән горурланабыз

Сәмәрканд шәһәрендә "Мәсҗиде Хуҗа Әхрар"да булган вә хәзрәти Госманга нисбәт ителгән Коръәнне төзәтеп яңарта. Үзенең энциклопедик мирасы, күпкырлы эш-гамәлләре белән ул урысларның Ломоносовын хәтерләтә. Казанда 1986 елда "Шигырьләр, поэмалар" исемле сайланма әсәрләре дөнья күрде.

Гаилә хәленә килгәндә, аның өч хатыныннан 20 баласы туа. Р.Фәхреддин язганча: Хәмидә Габдеррәзакъ кызы (1756–1798), Бәдигылҗамал һәм Фәтхия Рәхманкол кызы Габдеррәзакова (1784). Ү.Беляевада хатыннар башка тәртиптә язылганнар, ул беренче хатыны итеп - Фәтхияне, соңгысы итеп Бәдигылҗамалны саный. Әмма 1834 елгы ревизиядә Фәтхия әле исән, ул 50 яшендә! Димәк, Фәтхия - иң соңгы хатыны. Яше буенча да ул иң яше. Кайбер дуслар аның ике генә хатыны булган, дип исәпләсә дә, егерме баласының да метрикада язылган аналарын гына түгел, балаларының исемнәрен дә белмәгән килеш (моңарчы аның 10–11 баласының гына исемнәрен язалар иде), ничек шулай раслап була? Хәмидәдән 13 баласы туган, Бәдигылҗамалдан - өч кызы, ә Фәтхиядән - ике улы һәм ике кызы. Имам Баһавиның "Мәсәвих" китабына ул 7 баласының исемнәрен язып калдырган. Ул китап Нәкый Исәнбәт китапханәсендә саклана. Мин аның 10 улы һәм 10 кызының да исемнәрен белә алдым: Бәдигылҗамал, Габденнасыйр, Габдрахман, Габделгафур, Фатыймаи Сания, Шаһиәхмәт, Сәхибкамал, Сәхибҗамал, Бибигайшә, Әхмәтҗан, Камалетдин, Хөснетдин, Бибиҗамал, Җәләлетдин, Бибибәдигылҗамал, Җамалетдин, Бәдигылкамал, Хәбибҗамал, Хәбибкамал, Шәйхелсәгъди.

Габдеррәхим Утыз Имәни 1752 елда хәзерге Чирмешән районының Яңа Кади авылында игенче гаиләсендә туа. Аның дөньяда яшәү елларын 1754–1834 дип язсалар да, моның дөрес түгел икәнен аңлыйм. Чөнки үзе яшәгән вакытта уздырылган өч ревизия буенча да, ул 1752 елгы булып чыга: 1762–10 яшендә=1752, 1816–64 яшендә=1752 һәм 1834–82 яшендә=1752 елда туган килеп чыга. 1834 елның 31 мартында 8 ревизия узганда, ул әле исән. Ә бер атнадан, 8 апрельдә, ул вафат булган, диләр. Ревизия бит бер генә көн бармаган, атналар, айлар буе язганнар. Бер атнадан соң вафат булганны язмаслар идеме? Аннары, Тимәш авылының 1834 елгы метрикасында үлүчеләр исемлегендә ул юк! Р.Фәхреддин аны "1835 елның 31 июлендә, җомга көнне вафат булып, җеназасын шул авылда имам вә мөхтәсиб булган Сәфәргали бине Габдеррахман укыган", – дип яза. Мин шунысына ышана төшәм.

Габдеррәхим кечкенәдән зирәк акыллы, җитез табигатьле, тапкыр сүзле, шаян була. Авыл мәдрәсәсеннән соң - Кизләүдә, аннары Оренбург Каргалысында Вәлид ахуннан белем ала. Бер төркем туганнары белән – җәмгысы 10 ир-ат һәм 10 хатын-кыз – Кади, Утыз Имәни авылыннан күчеп, Казан губерна



Әнвәр Шәрипов (уртада) фикердәшләре белән.



Ә.Ямаева шәҗәрә ясарга өйрәтә.

канцеляриясенең 1770 елның 4 август резолюциясе буенча, Тимәш авылына "йомышлы татарлар" булып килеп утыралар. Күченүчеләр арасында Госман Сәрмәкәевнең 4 улы бар: Дөмәй (1743), Уразмәт (1750), Габдеррәхим (1752–1835) һәм Җәгъфәр (1756). Госман үзе 1755 елда вафат булып, Габдеррәхим 3 яшендә ятим кала. Алар белән Тимәшкә күчеп килүчеләр арасында Госманның абыйсы Исмәгыйль Сәрмәкәевнең (1716–1750) шулай ук ятим калган балалары Габделҗәлил (1741) белән Габдулла (1743) һәм Сәли Корманаевның 4 улы бар. Алары инде, минем ирем Ильяс Ямаевның нәсел башы булып, соңында Югары Чыршылыда гомер итәләр.

Иң олысы **Дөмәй** Госман улы туганнары өчен җаваплы һәм тырыш була. Туганнар 20 еллар Тимәштә яшәгәннән соң, кайбер сәбәпләр аркасында тирә-як авылларга таралыша. Дөмәй Әлмәт районының Түбән Мактама авылына күчеп киткәндә, энеләре Уразмәт белән Габделҗәлилне үзе белән иярткә. 1795 елгы 5 ревизиядә инде алар Түбән Мактамада язылганнар. Димәк, Түбән Мактамада Сәрмәкәй Кырым улының Дөмәй (Динмөхәммәт), **Уразмәт** (Уразмөхәммәт) һәм **Габделҗәлил** исемле оныкларының нәсел-нәсәпләре булырга тиеш. Төбәкче Альбин Вәлиевнең алдагы хезмәтләреннән алар турында да белербез, Аллаһы боерса!

Чаллыда дәүләт педагогия институтында укыткан профессор Әнвәр абый Шәрипов – Утыз Имәни иҗатын һәм тормыш юлын өйрәнеп, илле ел элек кандидатлык диссертациясе яклаган кеше. Ул үзенең китапларында Утыз Имәни турында шактый күп мәгълүмат бирә. Әлеге хезмәте, монография булып, 2022 елда кабат бастырылды. Әмма анда иске хаталар барысы да шул килеш калган.

Аңларга җайлырак булсын өчен, мин Габдеррәхим хәзрәтнең нәсел дәвамчыларын яшәгән авыллары белән бәйләп карадым. Лениногорск районының 4 авылында яшәгән туганнарының шәҗәрә агачларын төзедем, өч меңгә якын кеше җыелды.

1. **Тимәш** авылы яклап 12 буында 162 кеше табылды. А.Вәлиев хезмәте.

2. **Югары Чыршылыда** яшәгән 14 буынлы бу нәселгә 1280 кеше керде. Ә схемага барлыгы 185 кеше генә сыйды.

3. **Куакбаш** авылында 12 буында 500 кеше җыелды.

4. **Зәй-Каратай авылыннан** 13 буында 440 кешене табып, шәҗәрәләрен ясадым. Моннан тыш, Түбән һәм Югары Мактама, Сарабиккол, Утыз Имән, Түбән Чыршылы, Стәрлетамак өязе Мерәс авылларында, Чиләбе ягында, Уфа, Сәмәрканд калаларында аның карендәшләре яшәве билгеле. Бу бүлгәләү шартлыча, барысы да шунда яшәгән, дигән сүз түгел. Аларның анда 1800–1900 яки 2000 елларда яшәгән булуы ихтимал. Габдеррәхим хәзрәтнең балалары һәм оныклары да, шушы як авылларының мулла-мөәзин балалары белән никах корып, нәсел үрчеткәннәр. Алар – төбәктә билгеле кешеләр, аталары юлын дәвам итеп, мәдрәсәләрдә укытып, дингә хезмәт иткәннәр.

**Кырым** бабайның бер улы билгеле – Сәрмәкәй (1686–1739) исемле. Алар Кади бабай белән Утыз Имән авылын нигезләүчеләрдән. Ул авылга 1701 елда нигез салына. Ләкин сугыш чыгу сәбәпле, аның йортларын яндырып, авылны юк итәләр. Халкы кайсы-кая таралышып бетә. 1708 елда Сәрмәкәй Кырым улы хәзерге Норлат районы Мамык авылына күченә. 1716 елгы 1 ревизиядә ул гаиләсе белән шунда теркәлгән. Аның уллары да шул авылда дөньяга килгән булырга кирәк. 20–30 еллар узгач, авыл халкы яңадан иске авыл нигезенә



Кади авылының 1762 елгы ревизиясе. Уңда өстә Габдеррәхимгә 10 яшь дип күрсәтелгән.

кайтып урнаша башлый. 1743 елда Кади авылы кешеләре, ата-бабаларының биләмә җирләрен кайтаруны сорап, патшабикәгә үтенеч кәгазе язалар. Ул үтенечтә Исмәгыйль белән Госман Сәрмәкаевләрнең дә исеме бар. Ләкин Кади авылындагы 1745 елгы 2 ревизиядә алар юк әле, чөнки аларның “пропискасы” элек яшәгән авылларында булган. Хатыны Урайкүләй Туймәт кызы (1686) белән 4 улы туып-үскән. 1762 елгы 3 ревизиягә аның өч улы кергән: Исмәгыйль (1716–1750), Госман (1725–1755), Ибраһим (1735). Өчесе дә үз гаиләләре белән язылганнар. Үзенең вафатыннан соң дүртенче улы Морат (1740) туган, ләкин озак яшәмәгән. Ул вакытта Сәрмәкәй үзе исән түгел, 53 яшендә вафат булган.

Патша вакытында, хәзерге кебек, теләсә каян җир алып, шунда яшәп булмаган, аның рөхсәте белән генә. Габдеррәхим Оренбургка укырга Тимәштән киткән. Бохарага киткәндә дә аның “пропискасы” шунда калган. Шуңа күрә 10 ел йөреп кайткач, аңа Утыз Имән авылында җир бирмәгәннәр. Шулай булгач, “аның атасы Тимәшнеке булган”, “Габдеррәхим Тимәштә туган”, дигән сүзләр – шыр ялган! Гомумән, Тимәш авылы 1762 елгы 3 ревизиядә “деревня новопоселенная” дип язылган. Димәк, 1725 елда туган Госман Сәрмәкаев 1745–1762 еллар аралыгында барлыкка килгән Тимәш авылында туа алмаган! Аны “атасы вафатыннан соң туган”, дигән сүзләр дә урынлы түгел, чөнки 1762 елгы ревизиядә күренгәнчә, атасы Госман 1755 елда вафат булган, Габдеррәхимгә өч яшь чагында. Аңардан соң әле аның Җәгъфәр исемле энесе дә туган. Ул инде атасы вафатыннан соң туган булуы бар. Ә.Шәриповның “әтисе белән әнисе өйләнешкәч, алар Тимәштә яшәгәннәр”, дигән сүзләре дә дөреслеккә туры килми. Чөнки аның балалары башка туганнары белән Тимәшкә Госман үлгәннән соң гына күчеп киткәннәр. “Мерәскә уллары Әхмәтҗан белән Җамалетдин 1876 елда гына килгәннәр”, дип язылганы да дөрес түгел, чөнки Әхмәтҗан инде 1849 елда авырып вафат була.

1798 елда Габдеррәхим хәзрәт Урта Азиядән кайтканда юлда дусты Габдеррәхим яшәгән Мерәс авылында туктала. Анда дустының атасы Локман кантон йортында вафат булган улына багышлап уздырган Коръән мәҗлесенә тап була. Габдеррәхим хәзрәт белән аралашкач, ул көчле тавышы, Урта Азия мәкамнәре белән сүрә һәм догалар укып күрсәткәч, Локман кантон аның гыйлемле булуын, кайтып төпләнер урыны булмавын аңлый. Икенче көнне үк калага барып, аны үзенең варисы итеп яздыра. Шул вакыттан Утыз Имәни гаиләсе, балалары Мерәс авылы ревизияләрендә языла башлый. Җамалетдин турында Р.Фәхреддин “Мерәстә яшәп, 1890 елда вафат булды. Нәселе күп һәм таралган. Аны шәкертлек көннәремдә күргән идем”, дип яза. Аның уллары Мерәстә яшәсәләр дә, Тимәш белән араны өзмиләр. Җамалетдиннең улы Әхмәтшакир 1874 елда Тимәштән Хөснетдин кызы Бибинаиләне никахлап ала.

Утыз Имәнинең гыйльми хезмәтләренең шактые өйрәнелгән булса да, гаилә хәлләре, нәсел-нәсәбе аз билгеле. Ул узган катлаулы тормыш юлы хакында 100–150 ел элек галимнәребез тарафыннан язылган мәгълүматлар, табылган архив документлары белән тәңгәл килми. Гәрчә, ул ялгыш фикерләргә күп кенә тарихчылар ияреп, гыйльми хезмәтләр язганнар һәм мәктәп балаларының дәреслекләрендә, библиографияләрдә, энциклопедияләрдә һаман кабатланып торалар. Габдеррәхим хәзрәтнең тормыш юлы кабат өйрәнелеп, ачыклыклар кертүгә мохтаҗ! Без Альбин Вәлиев белән тапкан документлар шуны раслый.

Шәҗәрәләрне өйрәнү өчен, күп галимнәребезнең гыйльми хезмәтләре, язма чыганаклар, тарихи фактлар, ревизияләр, метрикалар, хуҗалык кенәгәләре, кабер ташлары белән таныштым. Кайбер сукмаксыз җирдә эз салырга туры килде. Бик дөрес булмаса да, кыйбласы күренсен, дидем. 270 ел элек яшәгән Утыз Имәни иҗаты турында галимнәр үз сүзләрен бүген дә әйтә киләләр. Мин ул өлешенә кермим, нәсел җепләренең бәйләнешен өйрәнәм. Ул турыда


РЕВИЗСКАЯ СКАЗКА

РЕВИЗСКАЯ СКАЗКА

МУЖЕСКІЙ ПОЛЪ

ЖЕНСКІЙ ПОЛЪ

Мерәс авылының 1834 елгы 8 ревизиясендә 1816 елгы 7 ревизия саннары да бар

быел чыккан “Утыз Имәни нәселе шәҗәрәләре” исемле китабымнан укып белә аласыз.

Ыру көчле булсын өчен, нәсел агачының тамырларын белү кирәк. Мисал китерә алам: Зәй-Каратайдан Мөхәммәтзакир мулла Әхмәткәрим улы Туйкинның бүгенге көндә гомер итүче 80–90 яшьлек оныклары: Чәчкә апа, Нур абый, Сылу апалар да үз әбиләренең Утыз Имәни оныгы икәнен белмиләр иде. Кайсылары кайчандыр нидер ишеткән булсалар да, аның үз әбиләре булуына шикләнәләр, чөнки Закир мулланың никахлы өч хатыныннан 16 баласы булган. “Зәй-Каратай тарихы” (2014) китабына ике кешенең олы хезмәте кергән: яртысын тормыш дәверендә Утыз Имәни онычы Җәләлетдиннең онычы Ибраһим Туйкин (1892–1983) язып барган. Ул йөз ел элек яшәгән кешеләрне күреп-белеп, алардан сорашып, нәселләрен җыйган. Икенче яртысы – фидакарь шәхес Җәүдәт Хәлимов хезмәте. Әмма Ибраһим җизни китабында үзенең әнисе Бәдриҗамалның (1860–1909) Габдеррәхим хәзрәтнең кызы Бибибәдигылҗамалның онычы икәнен, һәм аларның балаларын аерып, яхшылап язып калдырмаган! Хәләл акчамны түләп, архивтан шул документларны чүпләп утырырга туры килде. Шуңа күрә белгәнемне китапка кертергә тырыштым.

**Тимәш** авылында яшәп калган Габдеррәхимнең энесе Җәгъфәр белән туганы Әбдүш Исмәгыйлев тармагы буенча дустым Альбин Вәлиев 2020 елда ясаган шәҗәрәсен һәм аның язмаларын кулландым. 1790 елларда аның өч абыйсы хәзерге Әлмәт районы Түбән Мактама авылына күчеп китәләр. Аларның нәсел эзләре турында Альбинның алдагы китапларында укырбыз, насыйп булса.

**Сарабиккол** тармагы турында Рәшит Якупов 2011 һәм 2014 елларда язып чыкты, шуны файдаландым. Ләкин анда яшәгән кызының исеме, ул язганча, Хәбибкамал түгел, ә Хәбибҗамал. Аның никах метрикасында һәм балаларының туу метрикаларында Хәбибҗамал исеме ачык күренә. Һәм аны Габдеррәхим үзе кияүгә бирмәгән, чөнки 1848 елда инде ул күптән вафат булган. Никах метрикасына кызның җизнәсе – мулла Гыймадетдин мулла Котлыбай улы, вәли вәкил булып, кул куйган. Метрикаларда авылның борынгы атамасы Әби исеме дә очрады.

**Куакбаш** авылы тарихы күләмле, элек тә зур авыл булган, хәзер дә. 19 гасыр башында Габдеррәхим хәзрәт Куакбашта укыткан. Бу якларда беренче булып, анда мәдрәсә салдырган, димәк, авылда потенциал барын яхшы аңлаган. Бу авыл турындагы кайбер мифларны да дөрес түгел, дип саныйм, чөнки ул Куакбашта укытканда, булачак кияве Гыймадетдин әле тумаган да булган һәм мәдрәсә төзеткәндә дә (оныкларына төзеткән, дип язалар) кызы Бибибәдигылҗамал әле 6–7 генә яшендә була. “Туган авылым – Куакбаш” китабының авторы Мәмдүдә Вәлиуллинага сокланып туя алмыйм – авыл кешеләрен белеп, тирән төшеп, шәҗәрәләре белән язган. Әле бүгенге көндә дә Мәмдүдә апа, яңа табышлар белән кызыксынып, тапкан архив документларын папкаларга теркәп бара. Киләчәктә аның ул язмаларына алынып, эшен дәвам итәрлек кеше таба алмавына борчылып яши. Гомумән, Куакбаш авылында Утыз Имәнинең нәселе бик таралган, зур, һәм алар ерак бабалары белән горурланып яшиләр. Март аенда китабымның презентациясен дә Куакбаш Мәдәният йортында ясадык. Аны язучы Дамир Таҗи хатыны Минзилә (ул үзе дә шул нәселгә керә) белән башлап йөрделәр. Туганнары, авыл халкы – барысы да кызыксынып катнашты, ярдәм иттеләр. Зур рәхмәт аларга!

**Түбән Чыршылыда** яшәгән тармакны Р.Сальманова “Иманлы төбәк җәүһәрләре” китабында яктыртты. Дөрес, анда архив документлары бик аз, күбесе музей материаллары! Китап хатларга, кешеләрнең шәхси истәлекләренә таянып язылган. Өстәмә, ачыш һәм ялгышлар Рәсим Хәбибуллинның “Түбән Чыршылы – гыйлем чишмәсе” исемле китабында дәвам итә. Мин дә аларның китапларына таянып язган идем, димәк, үземдә дә хаталар бар! Урысларның “От многократного повторения ложь не становится истиной” – дигән сүзләре бик дөрес! Соңгы вакытта табылган дәлилләр бу фаразларны исбатлый алмады. Дөреслек каядыр яшеренгән, һич очына чыгарлык түгел. Р.Хәбибуллинны Утыз Имәни нәселе белән бәйли торган әбисе табылмады. Монда минем пенсия акчасы гына җитми, архивлардан күп документларны сатып алырга кирәк. Кызыксынган, үзләре шул нәселгә кергән кешеләр җиң сызганып тотынса, очына чыгарлар, дип уйлыйм.

Утыз Имәнинең **Югары Чыршылы** авылында яшәүче карендәшләре миңа иң якыны булды, чөнки казанында кайнадым. Зиннәтулла Насыйбуллинның (1913–1987) кульязмасын файдаланып, 2004 елда “Чәшелем – асыл илем” исемле уртак китабыбыз чыкты. Анда 200 ел буена авылда яшәгән ун мең кеше исәпкә керсә дә, Габдеррәхим Утыз Имәни исеме телгә алынмады. Әмма китапның башында ук Утыз Имән авылыннан килеп төпләнүчеләр турында язылган иде. Чөнки әле ул вакытта интернет та юк, архив материалларын табу да авыр иде. Анда, авылда яшәүчеләрне 62 нәселгә туплап, 7–8 буынлы шәҗәрәләр ясадым. № 28 нәсел башында Абдул Колмәт улы тора. Аның улы Тәминдар көчле кеше булган, атаклы ыру башы. Бүген дә аның дәвамы авылда яши. Азнакайда 20 ел җитәкче булган Әнәс Исхаков шул нәселдән. Ул 7 буын нәсел шәҗәрәсен кемнәндер ясатып алган, ләкин аны башка Абдулга кушып куйганнар иде, Утыз Имәнигә түгел. Икенче китабымда 15 мең кешенең 12–14 буынлы шәҗәрәләре бар. Төпкә төшкән саен алар кушыла барып, нәсел саны 14кә генә калды. Анда авылда 300 ел буе яшәгән һәр

кешенең исеме һәм шәҗәрәсе бар. “Ай нурында нәсел сукмагы” исемле китабымда инде Утыз Имәни турында белгәнемне яздым. Югары Чыршылыда яшәгән нәсел-нәсәбе 1280 кешегә җитте. Габдеррәхимнең абыйсы Исмәгыйльнең онygы Тәминдар гайрәтле кеше булган, атаклы нәсел. Бүген авылда яшәүче алты бертуган Вафиннар шул нәселдән, авылны тотып торалар.

**Габдеррәхим хәзрәтнең** (1752–1835) 20 баласы туган:

1. Бәдигылҗамал (1774) [имам Баһавиның “Мәсавих”китабында язылган].

2. Габденнасыйр (1782–1817). Бохара ягында һәм Тимәштә яши.

3. Габдрахман Акча шәһәрендә балачагында вафат була.

4. Габделгафур Акча шәһәрендә балачагында ахирәткә күчә.

5. Фатыйма-и-Сания 1788 елда Бохарада туа.

6. Шаһиәхмәт 1790 елда Шәһимәрдәндә туа, шунда ук дөньядан уза.

7. Сәхибкамал 1789 елда Туфида туа. Никахы Зариф хаҗи белән Чиләбедә яши.

8. Бибигайшә 1796 елда Һиратта туа.

9. Сәхибҗамал никахы Мөхәммәт белән Чиләбедә Күбәкәйдә яши.

10. Әхмәтҗанның (1808–1849) хатыннары Сәгыйдәбикә (1809) һәм Бибигалимә (1812). Тимәштә азанчы була.

11. Камалетдин (1813–1818), балачагында вафат.

12. Хөснетдин (1815–1820), балачагында вафат.

13. Бибибәдигылҗамалның (1815–1853) никахы Гыймадетдин (1813) бине Котлыбай бине Мирас бине Иманай бине Үтәш, Куакбаш имамы.

14. Җәләлетдин (1818), Куакбашта имам була.

15. Бәдигылҗамал (1818) никахы Әхмәтҗан Фәйзулла Яңа Кадидән.

16. Җамалетдин имам була, (1820–1890). Тимәштә, Мерәстә яши.

17. Бәдигылкамал (1822).

18. Хәбибҗамал (1824–1890), никахы 22.08.1848 Әхмәтҗан Шәмсетдин улы Сарабикколдан.

19. Хәбибкамал (1828).

20. Шәйхелсәгъди.

Бу балаларның язмышы төрле чыганакта төрлечә язылган. Мәсәлән, **Сәхибкамалны** Риза Фәхреддин Зариф хаҗи белән Чиләбедә яшәгән, дип яза. Ә.Шәрипов аның онygының онygы Кәримов Әхмәтҗанның Кара Чишмәдә яшәвен яза. Ә 21 декабрьдә Тимәшкә конференциягә килгән өч укытучы аны Утыз Имән авылы кешесе, дип аңлаталар. Шул кешенең фотосурәтенә нигезләнеп, Тавил Хаҗиәхмәтов 1985 елда Утыз Имәнинең портретын ясаган.

**Әхмәтҗан** Габдеррәхим улы Тимәштә яши, азанчы булып тора. 1816 елгы Мерәс авылы ревизиясендә “төшеп калган”, дип язалар. 1834 елда аңа – 26 яшь. Ике хатыны бар: Сәгыйдәбикәгә – 25, Бибигаатасы Габдеррәхим хәзрәтнең төрбәсеннән ерак түгел, уң яктарак.

Габдеррәхим Утыз Имәнинең кызы Бибибәдигылҗамалның (1815–1853) никахы Куакбаш имамы Гыймадетдин Котлыбай улы (1813) белән. Ул 1847 елның 12 декабреннән Куакбашның җәмигъ мәчетенә имам-хатыйб һәм мөгаллим булып билгеләнә. Аның хатынының исемен дә төрле урында төрлечә язалар. Куакбаш авылы метрикаларында Бибибәдигылҗамал дип язылган (бу иң дөресе!), ә Ә.Шәриповта һәм Куакбаш китабында Бибиҗамал дип. Аларның алты баласы туып-үсә: Минһаҗетдин (1833), Мөхәммәткамил, Җәләлетдин (1836–1908), Бибигайшә (1845), Бибисафия (1847) һәм Бибимәстүрә (1851). Алдагы ике улы сабый чагында вафат булалар. Җәләлетдин Куакбаш авылында имам булып тора. Хатыны Габидә Шәмсетдинова (1837), икенчесе – Иске Ярмәктән



Гранит такталарда шагыйрьнең шигырьләре.

лимәгә 22 яшь. Улы Мөхәммәтсафа Габделгазиз Әсән улының кызы Галимәгә өйләнә. Аңа “вәгазендә мөселман кануннарын бозып сөйли”, дип, хөкем эше кузгаталар. Җәсаде Тимәш авылы каберлегендә, имам Галәветдин кызы Бибинурдидә. Аларның уллары Мөхәммәтсәгыйть, Мәхмүт, Шиһабетдин, Гамилетдин дә, аталары юлын дәвам итеп, халыкка дин хезмәте күрсәтеп яшиләр. Кызлары Маһирә-

нең никахы Түбән Чыршылыдан имам Хәниф Габделкаюм улы. Бәдриҗамал – Зәй-Каратайдан мулла Мөхәммәтзакир Туйкин җәмәгате. Бибихәмидә (1872) Иске Госман



Бер елдан соң Илдус хәзрәт Маликов дога укый. 25.11.23.

авылы имамы Әхмәдулла Мөхәммәтшәрипов никахында гомер итә.

Бибихәмидәнең никахы Самар ягы кешесе буларак, никах метрикасын куям, бәлки, нәсел дәвамчылары табылыр? Бибихәмидә Куакбаш карьясендә туып-үсә. 20 яшендә Иске Госман авылы имамы Әхмәдулла белән никахы була. Кызның атасы Җәләлетдин мулла вәли вәкил. Кияүнең вәли вәкиле – Госман авылы мөәзине. Дүрт шаһит та Куакбаштан, кызның абзыйлары. Ә никах хөтбәсен укырга Түбән Чыршылының данлыклы ишаны Мөхәммәтхәниф мулла Габделкаюм улын чакырганнар. Ул вакытларда мәһәргә ат белән сыер, түшәк-ястык, акча һәм күчтәнәчләр бирү булган. Ә аларның сыйфаты тормыш дәрәҗәсенә карап аерылган. Мәсәлән: яшь айгыр, карт алаша, тай. Сөтле сыер яки бозау һәм башкалар.

*1893 елның 11 гыйнварында Богырыслан өязе* ***Иске Госман*** *авылының имамы Әхмәдулла мулла Гатаулла улы Мөхәммәтшәрипов (1867) белән никах укыйлар. Кыз 20 яшендә, кияү 25тә. Һәр икесенең әүвәлге никахлары. Кыз тарафыннан атасы Җәләлетдин мулла Гыймадетдин улы, вәли вәкил булып, кулын куя. Кияү тарафыннан Иске Госман авылы мөәзине ясаклы Кәлимулла Фәхретдин улы Шәмгылов тамга сала.*

*Кызның ризалыгы шаһитлары: кардәше Мәхмүт Җәләлетдин улы Гыймадетдинов кул куя. Шиһабетдин Җәләлетдин улы Гыймадетдинов кул куя. Кияүнең ризалыгы шаһитлары: Куакбаш авылының типтәр Мөхәммәтшакир Гыймадетдин улы Котлыбаев кул куя. Типтәр Әхмәт Шәрәфетдин улы Котлыбаев кул куя. Мәһәр – 100 сум көмеш: 1 җирән алаша (40 сум), 1 сыер (15 сум), түшәк-ястык, тимерле сандык, 1 шәл, 1 юрган (30 сум көмеш) һәм 15 сум көмеш акча – бары мөгъҗәл. Хөтбә укучы имам Түбән Шәлчәле авылының Мөхәммәтхәниф мулла Габделкаюм улы. Куакбаш авылының сәни имамы Мөхәммәтзакир мулла Гыймадетдин улы.*

*Гаделлек шаһитлары: типтәр Җамалетдин Мөхәммәтрәхим улы Котлызаманов кул куя. Сәни шаһит типтәр Вилдан Гыйрфан улы Гобәйдуллин кул куя.* Ә.Шәрипов язганча: “Бибиҗамалдан туган 82 яшендәге Фазыл карт” дигән сүзләр дөрес түгел, чөнки Фазыл Гыймадетдин улы 1870 елда туган, 1950 елда үлгән. Ә Бибиҗамал 1853 елда, ул туганчы ук, 17 ел элек вафат булган. Куакбашның 1853 елгы вафат булганнар метрикасы № 7 язмада: “Указлы мулла Гыймадетдин хатыны Бибибәдигылҗамал мартның 29 көнендә, 36 яшендә, тир зәхмәте берлән вафат булды”, – диелгән. Фазыл яшь хатынының улы.

Бибисафия Гыймадетдин кызы 26.03.1867 елда Кирлегәчтән мулла Җамалетдин мулла Биктимер улына никахлана. Аларның кызлары Һәдия – Куакбашның Хәсән мулла Котлыбаев җәмәгате. Аның җиде баласының дәвамчылары бүгенге көндә дә Куакбашта яшиләр. Бибимәстүрә Гыймадетдин кызы (1851) 10.01.1870 елда Карабаштан Исмәгыйль мулла Биккол улына (1848–1898) никахландырыла. Аларның 8 балалары Карабашта туып-үсәләр.

Тимәштә Утыз Имәнигә мемориал ачылганда, Чаллыдан һәм Казаннан Мөэмин-Каратай тумасы Гатаулла Крымовның нәсел дәвамчылары кайткан иде. Эзләнүләр нәтиҗәсендә А.Вәлиев аларның башка нәселдән булуларын ачыклады. Алар кенәз Крымовка мөнәсәбәтле булып чыктылар, әбиләре әйткән Утыз Имәнигә түгел.





Утыз Имәни кызыклы һәм катлаулы тормыш юлы узган. Аның гыйльми хезмәтләрен бөтен мөселман дөньясы белә. Безгә дә Утыз Имәнигә йөз белән борылыр вакыт житкәндер. 50–150 ел элек язылган дәлилсез фактларны алып ташлап, тормыш юлын документлар аша өйрәнеп, хезмәтләр язып, гыйльми әйләнешкә кертеп җибәрергә кирәк.

Дәреслекләргә, белешмәләргә һәм энциклопедияләргә дөресен язу зарур.

# Гали авылы мәктәбе директоры: “ЫШАНЫЧЛЫ ТЕРӘГЕМ БУЛГАН ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕМ – ҮЗЕНӘ БЕР БӘХЕТ”


Фидаил Маннанов укучыларны бүләкли

***Похвистнево районының Гали авылында туып-үсеп, биредә гомер итүче Мәҗит улы Фидаил Маннановка Аллаһы Тәгалә мәктәп директоры вазифасын юкка гына насыйп итмәгәндер инде. Затлы нәсел дәвамчысы, төпле, һәр сүзен үлчәп сөйләүче, зыялы, интеллигентларга хас кыяфәтле, югары тәрбияле Фидаил әфәнде нәкъ үз урынында, дияр идем. Ә бит әле агроном хезмәтен башкарган вакытларында ул укытучы, бигрәк тә мәктәп директоры, булырмын, дип уйлап та карамаган! Ә хәзер аңа карата “Урын кешене бизәми, кеше урынны бизи”, дигән гыйбарәне тулы ышаныч белән кулланырга була. Фидаил әфәнденең исеме дә җисеменә туры килеп тора бит әле - ул “мәрхәмәтлек кылучы, яхшы сыйфатларга ия, дәрәҗәле, абруйлы” дигән мәгънәне аңлата.***

***Миләүшә Газимова***

Үз эшен намус белән, җиренә җиткереп башкаручы, итагатьле, мәрхәмәтле, коллективы өчен җан атып торучы җитәкчегә хезмәткәрләренең дә ихтирамы зур.

Авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган милләттәшебез ничек итеп уку йорты директоры булып куйган? Гали авылы мәктәбе бүген нинди хәлдә? Шушы һәм башка сораулар буенча Фидаил абый Маннанов белән әңгәмә кордык.

***– Татар халкы “Оясында ни күрсә – очканында шул булыр”, дигән бик акыллы сүзләр әйткән. Сезнең уңышлы тормышыгызда да әти-әниегезнең хезмәте зурдыр?***

– Әйе, һичшиксез, шулай, дип әйтә алам. Әти-әни тәрбиясе кешенең язмышына, тормышына зур йогынты ясый. Әлһәмдүлилләһ, әткәй белән инәкәй безне яхшы үрнәк күрсәтеп үстерделәр. Тәртипле, эш сөючән, тырыш, ярдәмчел кешеләр буларак, балаларында да шушы сыйфатларны тәрбияләделәр. Алар безнең һәр башлангычыбызны хуплап, акыллы киңәшләрен бирделәр, ярдәм кулын суздылар. Әти-әниебезне хөрмәтләп, сүзләрен тыңлап үстек һәм хәзер дә шулай ук.

Без гаиләдә дүрт бала. Олы абыем Наил Оренбург өлкәсендә гомер кичерә, авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнә. Апам Зөлфия үз авылыбызда, әти-әниебез күршесендә генә яши. Энем Рафаил Оренбургның үзендә тора, сәүдә белән эш итә.

Раббыбызга шөкер, әткәй белән инәкәй тигезлектә, иминлектә, бәхетле булып гомер итәләр. Әтием Мәҗит 84 яшендә, әнием Фәния 82 яшен тутырды. Аларга без һәрвакыт күз-колак булып, ярдәм күрсәтеп торабыз.

2000 елда хәләл җефетем белән туган авылыбызга кайтып урнаштык.

Кинель-Черкасста теплицаларда яшелчә үстереп сату эше киң җәелгән бит. Мин анда бу бизнесның кайбер нечкәлекләренә



Газиз кешеләре - әтисе Мәҗит, әнисе Фәния

Әткәй 40 елдан артык колхозда машина йөртүче булды. Лаеклы ялга чыккач, күп еллар мәчеттә имам хезмәтен башкарды. Ә инде олыгайгач, вазифасын яшьләр кулына тапшырды. Әмма бүгенге көндә дә Аллаһы йортына йөреп, гыйбадәтләрен кыла.

Инәкәй дә башта – колхозда, ә пенсиягә китәр алдыннан мәктәптә сәркатиб булып эшләде.

Әткәебез белән инәкәебезгә үз гомеребездә рәхмәтле булачакбыз. Газиз кешеләребезне Аллаһы Тәгалә Үзенең киң рәхмәтеннән ташламасын.

***– Фидаил абый, агроном белгечлеген алып, ничек итеп укытучы булып киттегез?***

– Мәктәптән соң Куйбышев авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, Кинель-Черкасс районындагы Кабановка авылында үз һөнәрем буенча эшләдем. Аннары инде, колхозлар таркала башлагач, төшенгән идем. Һәм Галигә кайткач, йортыбызда теплица салып, яшелчәчелек белән шөгыльләнә башладык. Хәер, бу эшебез әле бүгенге көнгә кадәр дәвам итә.

Ә 2004 елда авылыбыз мәктәбенең директоры Исламнур улы Мөхтәр Алтынбаев мине эшкә чакырды. Балаларны яратканга, аның тәкъдимен кабул итеп, биология укытучысы хезмәтенә керештем. Әлбәттә инде, педагогик белем алырга кирәк булды. Һәм мин, Мөхтәр абыйның сүзен тыңлап, Мәскәү дәүләт педагогика университетының Самарадагы филиалында магистратура тәмамладым, диссертация якладым.

Кызганыч ки, Мөхтәр әфәнде якты дөньядан иртәрәк китеп барды шул. Күңеле алдан сизгәндәй, мине үз урынына әзерләп калдырды ул. Шулай итеп, аның вафатыннан соң вакытлыча директор вазифаларын башкардым. Ә бер елдан соң, коллектив хуплавын алып, мәктәпне җитәкләдем һәм бүгенге көнгә кадәр биология дәресләрен алып барам.

Биредәге хезмәтемә 19 ел үтеп киткән инде.

***– Хәзер мәктәптә ничә бала укый?***

- 162 укучы белем ала. Аларның саны елдан-ел кими бара шул. Мин директор вазифасына керешкәндә мәктәптә 221 бала иде.

***– Татар теле укытыламы?***

– Атнасына ике сәгать керә. Шунысы кызганыч ки, кайбер ата-аналар балаларына ана телен укытуны кирәксенмиләр. Алар белән даими рәвештә аңлату әңгәмәләре алып барабыз, татар теленең кирәклеге турында сөйләп торабыз да бит. Шулай да, бу проблема һаман да кала бирә.

***– Укучылар нинди чит ил телен үзләштерәләр?***

– Бездә инглиз теле укытыла.

***– Мөгаллимнәрегез күпме? Аларга кытлык юкмы?***

– Минем белән бергә барлыгы 20 укытучы – Хәсән кызы Әлфия Шиһапова, Николай кызы Надежда Иванова, Камил кызы Раилә Морта-



Фидаил һәм Фәһимә Манნановлар оныклары Кәрим белән

зина, Гомәр кызы Гүзәл Гозәерова, Минтин кызы Нурия Сәйфетдинова, Хәйдәр кызы Рәйхан Нуриева, Хәмәтнур кызы Рушания Манашева, Виктор улы Владимир Фогель, Абдулла кызы Фәния Мөхәммәдиева, Мингазиз кызы Гөлия



Ике улы - ике терәге, Фаил белән Раил

Мөхәммәтова, Зәйнулла улы Равил Искәндәров, Рәис кызы Гөлчәчәк Таҗетдинова, Фәрит кызы Ләйлә Гозәерова, Дәрҗеман кызы Раилә Маннанова, Мөхәсим кызы Әлфирә Гайнанова, Шәрифулла кызы Фирдәүсә Йосыпова, Әхәт улы Халит Шәһиев һәм бүгенге көндә декрет ялында булган Рәис кызы Айгөл Габдуллина белән Василий кызы Александра Латыйпова.

Коллективыбызның нигезен инде күптән эшләүче мөгаллимнәр тәшкил итә.

Әлегә, шөкер, укытучыларга андый ук кытлык кичермибез. Әмма алар олыгая бара шул. Яшьләр бик аз бездә.

Әле менә пенсиягә киткән ике мөгаллимәне яңадан эшкә кайтуларын сорарга туры килде. Татар теле дәресләрен алып барган Нәзахетдин кызы Зөлфим Асылгәрәева лаеклы ялга чыккач, аның урынына яшь укытучы Искәндәр Латыйпов килгән иде. Әмма ул озак эшләмәде, кайбер сәбәпләр аркасында мәктәптән китте. Хәзер татар телен ветеран укытучыбыз Мингазиз кызы Гөлия Мөхәммәтова укыта. Инглиз теленнән дә лаеклы ялда булган Абдулла кызы Фәния Мөхәммәдиева белем бирә. Соңгы ел укытам, ди дә ул, без сорагач, тагын эшкә чыга. Үтенечләребезне кире какмаганнары өчен, аларга Аллаһының рәхмәтләре яусын.

***– Гомумән, коллективыгыз турында ни әйтер идегез?***

– Хезмәткәрләрем – үзенә бер бәхет ул. Бердәм, дус, бер гаиләдәй без. Барысы да – үзебезнең кешеләр. Аңлашып, ярдәмләшеп эшлибез, Аллаһыга шөкер.

Менә мин мәктәпне биш ел җитәклим инде. Берәр укытучы канәгатьсезлек белдерсә, караңгы чырай күрсәтсә! Тәкъдимнәрне хуплап каршы алалар, үзләре дә инициатива күрсәтәләр, һәрьяклап булышалар. Алар – минем ышанычлы терәгем. Һәрберсенә рәхмәтем зур. Алга таба да бергәләп матур гына хезмәт итәргә язсын!

Ветераннарыбыз белән дә элемтәдә торабыз. Эчкерсез мактауга, олы хөрмәткә лаек булган бу мөгаллимнәребезне төрле чараларга чакырабыз, аралашып утырабыз. Алар безнең өчен үрнәк, маяк булып торалар.

***– Директорның хезмәте авырмы?***

– Җиңел, дип әйтмәс идем. Һәр җитәкченең өстендә зур җаваплылык ята бит. Ә балалар белән эш иткәндә – бигрәк тә.

Аннары, хәзер кәгазь мәшәкате күбәйде. Мониторинг, анкеталау, анализ ясау, хисап бирү һәм башкалар, һәм башкалар.

***– Мәктәбегезнең уңышлары турында да әйтеп үтсәгез иде.***

– Шатлыгыбызга, ел саен медалистларыбыз була. Менә быел гына юк иде.

Балалар югары уку йортларына керәләр. Элегрәк күбесе Самарның аэрокосмик, политехник, медицина университетларын сайлап алалар иде. Ә менә соңгы елларда Казан шәһәренә китүчеләр күбәйде. Анда алар дәрәҗәле уку йортларында белем алалар. Шөкер, йолдызчыкларыбыз бар, дип әйтәсем килә.

Укучыларыбыз, төрледән-төрле конкурсларда, олимпиадаларда катнашып, җиңүләр, призлы урыннар яулыйлар. Авылыбызның укытучылардан торган "Мирас" фольклор төркемендә җырлыйлар, бииләр, төрле төбәкләргә чыгыш ясарга йөриләр.

Куанычлы ки, тәртипләре ягыннан да битебезгә кызыллык китергәннәре юк. Һәр баланың әти-әнисен, нәселен яхшы беләбез. Һәрберсенә җаен табып, психологиясен исәпкә алып эшләргә тырышабыз. Ата-аналар белән мөнәсәбәтләр яхшы, алар һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер.

Белем бирү сыйфатын ачыклау һәм бу юнәлештә нәтиҗәлелекне



Укытучылар

арттыру өчен, Самар өлкәсенең Мәгариф һәм фән министрлыгы ел да мәктәпләр рейтингын төзи. Һәр районда гыйлем һәм тәрбия бирү нәтиҗәләре буенча лидер мәктәпләр ачыклана. Шатлыгыбызга, Гали авылы мәктәбе 2021, 2022 елларда «Самар өлкәсенең иң яхшы уку йорты” исеменә лаек булды.



Дүрт бөртек, бертуган - Фидаил әфәнде, абыйсы Наил , апасы Зөлфия һәм энесе Рафаил

Бездә волонтерлар, юл хәрәкәте иминлеге отрядлары бар. Гомумән, укучыларыбыз иҗтимагый оешмалар эшчәнлегендә актив катнашалар.

Сүз уңаеннан шуны да искәртеп узасым килә – киләсе елга 1904 елда ачылган мәктәбебезгә – 120 ел, ә яңа бинага – 50 ел тулачак. Шушы юбилейлар уңаеннан, Аллаһы бирсә, февраль аенда зур бәйрәм үткәрергә ниятлибез.

***– Бүгенге көндә нинди дә булса проблемалар белән очрашасызмы?***

– Шул кадрлар мәсьәләсе күңелне борчый. Әйткәнемчә, элегә укытучыларыбыз җитә. Ә менә алга таба ничек булыр?! Яшьләр авылга ашкынмыйлар, аларга тормыш көтәргә кирәк. Галидә дә эш урыннары бармак белән санарлык бит – администрация, мәктәп, балалар бакчасы, хәләл колбаса җитештерү цехы, олыларга социаль ярдәм күрсәтү үзәге. Халык күбесенчә мал асрый, теплицада яшелчә үстереп сата, шулай көн күрәләр.

Аннары, укытучы булу, балалар, аларның ата-аналары белән эшләве дә җиңел түгел бит инде.

***– Мәктәпкә ярдәм кулын сузучы кешеләр бармы?***

– Әйе, әлһәмдүлилләһ, андыйлар бар. Авылдашыбыз, хәзерге көндә Казанда яшәүче Әсхәт кызы Дания Тулова безгә һәрдаим бик зур ярдәм күрсәтә. Ышанмассыз, ун ел элек ул үз акчасына өч катлы мәктәп бинасына капиталь ремонт ясатты! Диварлардагы штукатурканы кирпечкә кадәр куптарып, янәдән сыладылар, идәнгә яңа такталар һәм линолеум җәйделәр, түшәмнәрне ясадылар, утүткәргечләрне, сигнализация системасын алмаштырдылар һәм башкалар, һәм башкалар. Бинаның фасады җылытылып, сайдинг белән капланды. Гомумән, галәмәт булды ул ремонт. Әле бит видеокүзәтү камералары куелды, һәр класс – проектор, һәр укытучы компьютер белән тәэмин ителде. Безгә мәктәпне шул хәлдә саклап, тәртиптә тотып, җылы, матур, якты бинада рәхәтләнеп эшләргә генә кала. Дания ханым Туловага Аллаһының олы рәхмәте яусын!

Бу эштә ул вакыттагы директор Мөхтәр абый Алтынбаевның да хезмәте зурдан. Җитәкче буларак, күп көч куйды ул.

*Исламшәриф улы Наил Баһаутдинов,*
*Миргазиз улы Рамил Мостафин,*
*Шәйхулла улы Халит Йосыпов,*
*Габдулла улы Сәйфулла Маннанов,*
*Әбүбәкер улы Камил Исхаков,*
*Әсхәт улы Рәфкать Исхаков,*
*Мингани улы Радик Сафиуллин,*
*өч бертуган – Шамил уллары Рафаэль, Равил, Салават Галимуллиннар шулай ук мәктәбебезгә гел булышып торалар.*




Фидаил әфәнде укучыларын олы тормыш юлына озата

Игелекле гамәлләре, балаларга ярдәм иткәннәре өчен һәрберсенә Раббыбыз савапларын арттырып кайтарсын. Алардан башка безгә бик кыенга туры килер иде.

***– Һәр мәктәпнең үз юнәлеше була бит. Сез нинди кыйбладa эшлисез?***

– Безнең юнәлешебез – татар телен, мәдәниятен, милли гореф-гадәтләребезне саклау, аларны үстерү һәм пропагандалау.




Мәктәптә балалар Сабан туе

Дини йолаларга да зур игътибар бирәбез. Укучыларыбыз төрле төбәкләрдә уздырылган дини бәйгеләрдә катнашалар, призлы урыннар алып кайталар. Бу яктан алар белән Мөхәммәтнур кызы Кәүсәрия Шәйхетдинова яхшы эш алып бара. Җәйләрен нарасыйлар авылыбыз мәдрәсәсендә оештырылган лагерьга йөриләр.

Менә инде 25 ел буена мәктәптә балалар Сабан туе үткәрелеп килә. Аны да Кәүсәрия апалар оештырып җибәргәннәр иде. Былтыр без аны район күләмендә уздырдык. Төрле авыллардан, хәтта башка районнардан да кунаклар килде. Концертлар куеп, төрле ярышлар оештырып, бик күңелле итеп үтә бу милли бәйрәмебез. Көрәштә җиңгән малайларга, гадәт буенча, тәкә бирелә.

***– Хәзер илнең барлык мәктәпләрендә директорның тәрбия эше буенча киңәшчесе, ярдәмчесе вазифасын кертәләр. Сез моңа әзерме инде?***

– Похвистнево районындагы берничә мәктәптә бу гамәлдә йөри инде. Яңа елда бездә дә әлеге вазифа кертелергә тиеш. Коллектив белән үз арабыздан кандидатураны сайлап алдык инде, бу юнәлештә махсус курсларда да укып кайтты ул. Тарих фәненнән белем бирүче яшь укытучыбыз, оста оештыручы булган Шәрифулла кызы Фирдәүсә Йосыпованың яңа вазифаны лаеклы рәвештә башкарачагына шикләнмибез.

***– Мәктәптә эш яхшы барсын өчен, нәрсәләр таләп ителә?***

– Һәр кеше үз хезмәтен зур җаваплылык белән башкарырга тиеш. Шул чакта уңышларга ирешергә мөмкин.

***– Хәзер, балалар булмау сәбәпле, кайбер авылларда урта белем бирүче уку йортларын ябалар. Ә сез мәктәбегезнең киләчәген ничек күзаллыйсыз?***

– Аллаһы теләсә, ул яшәр, дип уйлыйм. Галидә яшьләр, бәби табучылар барыбер бар әле, алга таба да, инша Аллаһ, алар булыр.

Балалар бакчасына бүгенге көндә 52 бала йөри, дүрт тәрбияче эшли.

Раббыбыз ярдәме белән, мәктәбебезнең дә, авылыбызның да киләчәге булыр, дип ышанам.

***– Фидаил әфәнде, кешенең тормышында иң ышанычлы тыл – ул гаилә. Сездә дә шулаймы?***

– Бәхетемә, нәкъ шулай! 1991 елда, 24 яшемдә, авылыбызның Фәһимә исемле кызына өйләндем. Ике бала тәрбияләп үстердек. Икесе дә Самар шәһәрендә яшиләр.

Олы улыбыз Фаил реклама өлкәсендә эшли. Киленебез Ирида белән безгә Кәрим оныгыбызны бүләк иттеләр. Үзенә алты яшь тулды инде.

Кече улыбыз Раил әлегә өйләнмәгән. Төзелеш тармагында хезмәт куя.

Гаиләбез тату, Аллаһыга шөкер, малайларыбыз безне сөендереп яшиләр, киленебез үз кызыбыздай якын.

Хәләл җефетем Фәһимә – өлешемә төшкән көмешем! Барысы өчен дә аңа мең-мең рәхмәт. Бәхетле тормышта яшәвем өчен Раббыбызга шөкер кылам.

***– Балаларыгыз татар телендә сөйләшәме?***

– Әйе, ана телен яхшы беләләр алар. Без үзара гел татарча гына аралашабыз. Шунысы да сөендерә – киленебез Ирида, Самарда туып-үскән булса да, саф татар телендә сөйләшә. Кызларына тиешле белем-тәрбия биргәннәре өчен, кодабыз Марс белән кодагыебыз Юлиягә рәхмәт.

***– Хезмәтегезне яратып башкарасызмы?***

– Бу сорауга түбәндәге шигъри юллар белән җавап бирсәм, барысын да аңларсыз, дип уйлыйм:

*“Фани дөнья гүзәллеген күрү өчен,*
*Җиргә туа, матур итеп яши кеше,*
*Максат куя һәм ирешә, үргә менә,*
*Булса әгәр чын күңелдән*
*сөйгән эше”.*

Дөресен генә әйткәндә, директор вазифасына караганда, укытучы эше күңелемә якынрак, чөнки, әйткәнемчә, балаларны яратам мин.

Яшь чакларда да, институтны тәмамлап, эшли башлагач та, укытучы булырмын дип уйга да килмәгән иде. Әмма әле Кабановка авылында эшләгән чакта андагы мәктәп яныннан үтеп барганда никтер: “Ә мин мәктәптә эшли алыр идемме икән?” – дигән фикернең башымнан йөгереп узганын хәтерлим. Ул вакытта Раббыбыз күңелемә мөгаллимлек орлыгын салган булса кирәк. Һәм мин шул орлыкның, шытым биреп, ныклап үсеп китүе өчен Аллаһыга чиксез рәхмәтлемен.

# МӨГАЛЛИМӘ ДИП ЯЗЫЛЫП КУЕЛГАН АНЫҢ ЙӨРӘК ТҮРЕНДӘ!

*Мөгаллимнәрне зурлап, 2023 ел илебездә "Укытучылар һәм остазлар елы" дип игълан ителде. Әйе, бу һөнәр ияләре мондый хөрмәткә, һичшиксез, лаек! Мөгаллим, ата-аналар белән беррәттән, балага белем дә, тәрбия дә бирүче, кечкенә нарасыйдан зур шәхес үстерүче, олы тормышка юл күрсәтүче дә бит ул.*

***Миләүшә Газимова***



Һәр кеше укытучы була алмый. Бу дәрәҗәле һөнәргә киң күңелле, акыллы, эш сөючән, белемле, сабыр, мәрхәмәтле, гадел, ә иң мөһиме, балаларны ихлас яратучы шәхес кенә ия булырга мөмкин.

Нәкъ шундый күркәм сыйфатлары булганга, Аллаһы Тәгалә язмам герое – Рәис кызы Нәфия Муллабаевага мөгаллимлек сәләтен биргәндер дә инде.

Похвистнево районының Гали авылында туып-үскән һәм шушында яшәүче милләттәшебез 41 ел гомерен балаларны укытуга багышлаган. Фидакарь хезмәтен югары бәяләп, аны Мактаунамәләр белән бүләкләгәннәр. Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан бирелгән Мактау грамотасы да бар аның.

– Нәселебездә бер мөгаллим булмаса да, мин бу һөнәргә кечкенәдән мөкиббән. Балачакта һәрвакыт укытучы булып уйнадым. Сеңелләремне, күрше-тирә кызларны утыртам да, кулыма указка тотып, үзләренә дәрес бирәм. Әле бит, укытучы апабызга охшарга тырышып, носки эченә шүре (шпулька) тыгып, үкчәле туфли ясый идем (көлә).

Аннары, беренче мөгаллимәм – Гыйззетдин кызы Әминә Хөснетдинова безнең күршедә яшәде. Мин аның кызлары белән дус идем. Алардан чыкмадым да, дияргә була. Әминә апаның да тәэсире тимичә калмагандыр, – дип, ни өчен укытучы белгечлеген сайлавын аңлата Нәфия апа.

Мәктәптә сигезенче сыйныфны бетергәч, ул Подбельскиның педагогика училищесында белем алган. Укуын тәмамлагач, башлангыч сыйныфлар укытучысын Кече Толкай авылындагы тәрбиягә авыр бирелүче балалар өчен каралган махсус мәктәпкә җибәргәннәр. Би-

редә эшли башлагач, Нәфия ханым читтән торып Куйбышев педагогика институтының математика бүлегенә укырга кергән.

– Кече Толкайда бер ел укыттым мин. Аннан соң Алешкино авылында да эшләп алдым. Ә бервакыт вокзалда Гали мәктәбенең директоры Юныс абый Шәгалиев-



Нәфия ханым ире Идрис белән

ны очраткач, ул миңа авылыбызга кайтырга тәкъдим итте. Туган җиремне өзелеп яратучы кеше буларак, чит якларда тилмереп йөрисем килмәде. Шуңа күрә шунда ук шатланып ризалаштым. Мине ул вакытта авылыбыз мәктәбенә эшкә чакырганы өчен, мәрхүм Юныс абыйга бүгенге көндә дә рәхмәтлемен.

Башта тәрбияче булып урнаштым, аннары инде математиканы укыттым.

***– Ә ни өчен нәкъ бу фәнгә тукталдыгыз?*** – дип кызыксындым әңгәмәдәшемнән.

– Бу предметны мәктәптә яратып үзләштердем. Ул миңа җиңел бирелде. Берәр нинди авыр мәсьәләне чишәргә туры килсә, очына чыкмыйча, йокларга ятмый идем. “Коры фән”, дип саналса да, математика күңелемә ятты минем.

***– Нәфия апа, балачак елларыгыз ничек үтте? Әти-әниегезне дә искә төшереп алыйк әле.***

– Без алты бала үстек – биш кыз, бер малай. Әти-әнием колхозда эшләделәр. Әни күбрәк кырларда көч түкте. Әти склад мөдире дә, ревизор да, бригадир да булды.

Балачак, яшьлек елларыбыз матур, бәхетле узды безнең. Әти-әниебезгә мең рәхмәт. Башкалардан ким-хур итмәделәр, яхшы, рәхәт яшәдек, Аллаһыга шөкер. Безне, биш кызны, югары уку йортларында укытып чыгардылар. Төпчек энебез техникум бетерде. Ата-анабыз ярдәмендә кеше булып чыктык.

Әтиебез дә, әниебез дә күркәм сыйфатларга ия иде. Без алардан үрнәк алып үстек.

Әтием Рәиснең кызып киткән чаклары булса да, йомшак күңелле, юмарт, ярдәмчел кеше иде ул. Якты дөньядан иртә китеп барды шул, 66 яшендә вафат булды.

Әнием Нәфисәнең сабырлыгына, мәрхәмәтлелегенә исләрең китәр! Шундый нәзакәтле, түземле, йомшак иде. Кызганыч ки, ике ел элек, 84 яшендә, ул да бакыйлыкка күчте. Гомумән, кайгы-хәсрәтләр кичерергә туры килде шул. Бик тә авыр булды. Әнием һәм ике сеңелем бер-бер артлы үлеп киттеләр. Раббым үзләренә Җәннәт түрләрендә урын насыйп итсен иде.

***– Гаиләгез белән дә таныштырып үтсәгез иде. Ничә яшегездә кияүгә чыктыгыз? Иregезнең нинди сыйфатларына кызыктыгыз?***

– 23 яшемдә Идрис исемле авылдаш егетенә тормышка чыктым, параллель сыйныфларда укыдык без. Үзен армиягә озатып, көтеп алдым. 1982 елда өйләнештек. Әлһәмдүлилләһ, яратышып, матур яшәдек һәм яшибез.

Идрис бик сабыр, тыныч, йомшак, мәрхәмәтле. Менә инде 20 елдан артык авыл башлыгы булып эшли ул. Халыкка карата шулкадәр игелекле. Беркайчан тавышын



Муллабаевларның тату гаиләсе



күтәрмәс. Авылдашларына туганнарына карагандай карый, аларга гел яхшылык кылырга тырыша.

41 ел бергә гомер итәбез. Идрис гаилә җанлы, балаларыбыз, оныкларыбыз өчен өзелеп тора. Ул, кызларыбызның һәр башлангычын хуплап, аларның теләкләрен, карашларын хөрмәт итеп, ярдәмен күрсәтте һәм хәзер дә шулай ук. Дөрес, кызларыбыз да, әлхәмдүлилләһ, битебезгә кызыллык китермәделәр, укыдылар, тырыштылар.

Олы кызыбыз Нәсимә Самар медицина университетында терапевт һөнәрен үзләштерде, үз белгечлеге буенча эшли.

Кече кызыбыз Рәсимә Самар дәүләт университетында, физика һәм математика бүлегендә укыды. Аның ире – табиб. Бергәләшеп үз клиникаларын ачтылар.

Кияүләрем Рафаэль белән Шамилдән дә уңдым, дип әйтә алам, шөкер. Икесе дә булдыклы, миһербанлы, сабыр, ярдәмчелләр.

Рафаэль – хирург, бүгенге көндә Украинада махсус хәрби операциядә катнаша.

Кода-кодагыйларыбыз белән дә тату без, аралашып, күрешеп яшибез.

Дүрт оныгыбыз – күз нурыбыз бар. Дианага 15 яшь инде, тугызынчы сыйныфта укый. Әмир – бишенче класс баласы, баскетболчы, төрле шәһәрләрдә узган ярышларда катнаша. Дүртенче сыйныфта белем алучы Камил йөзү белән шөгыльләнә, шулай ук төрле җирләргә ярышларга йөри. Кәримебез икенче класста, ул – футболчы.

***– Авыл башлыгы хатыны булуы авырмы?***

– Җиңел, дип әйтмәс идем (елмая). Иртән иртүк өйдән чыгып китә, соң гына кайтып керә. Төнлә чыгып киткән чаклары да була. Кайда ут сүнә, кайда янгын чыга һәм башкалар. Проблемалар җитәрлек инде, барысын да хәл итәргә кирәк бит.

Аннары, Идрис бит – башлык, җитәкче кеше, аңа үрнәк булырга кирәк. Аның эчке дөньясы гына түгел, өс-башы да пакь, чиста булырга тиеш. Ирнең пөхтә киенеп йөрүе – ул хатынының бурычы. Гел карап, юып, чистартып торырга кирәк.

Моңардан тыш, рухи ярдәм күрсәтү дә мөһим. Җаны тыныч булсын өчен, гаиләдә дустанә мөнәсәбәт хөкем сөрергә тиеш. Өйдән чыгып киткәндә кәефе яхшы, күңеле күтәренке булсын. Ул бит кешеләр янына бара, халык белән эш итә. Кайтуына да өйдә чиста, ашарга пешкән. Аны һәрвакыт ачык йөз белән, елмаеп каршы алырга, күңелен төшермәскә тырышам.

Гомумән, хәләл җефетемне хуплап, аңа булышып яшим. Тормышта төрле хәлләр була бит инде ул. Берәр нинди күңелсез сәбәп килеп чыгып, эштән кәефсезләнеп кайткан чакларында, барысы да җайланыр, дип үзен юатам, тынычландырам. Шуңа күрә иремнең эше нинди җаваплы булса, минем өстемдә дә шулай ук зур җаваплылык ята, дип әйтәсем килә.

***– Гаиләдә дә ирегез башмы?***

– Әлбәттә, ул – минем таянычым, терәгем, гаилә башлыгы. Әмма Идрис, мин – хуҗа, минемчә генә булырга тиеш, дип күкрәген киереп йөрми. Шөкер, барлык мәсьәләләрдә дә киңәшләшеп торабыз.



Оныклары - бәгырь җимешләре

***– Бәхетле булыр өчен, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр нинди булырга тиеш?***

– Бер-береңне ихтирам итеп, аңлап, санлап, юл куеп, ярдәмләшеп яшәргә кирәк.

***– Нәфия апа, дүрт ел элек лаеклы ялга чыккансыз. Мәктәпне сагынасызмы? Гомумән, хезмәтегез күңелегезгә нәрсәсе белән якын булды?***



– Мәктәптә эшләгән еллар сагындыра, әлбәттә. Укучыларымны яраттым, үз балаларымдай якын булдылар алар миңа. Үзләренә “улым”, “кызым”, дип эндәшә идем, барысын да бертигез күрдем.

Коллективыбыз бик яхшы, дус булды. Хезмәттәшләребез белән туганнарча аралаштык, хәтта өйдә сөйли алмаган кайбер серләребезне алар белән уртаклаша идек.

Хезмәтемне яратып башкардым. Эше генә күп, ә болай миңа бер дә авыр булмады. Балалар тәртипле, тыңлаучан, кушкан йомышны үтәргә әзерләр, апа, апа, дип кенә торалар иде. Рәхәтләнеп эшләдем.

Бүгенге көндә дә укучыларым мине онытмыйлар, хәлләремне беләләр. Очрашкач, озаклап сөйләшеп утырабыз. Ямьле мәктәп елларын искә төшереп, көлешеп тә, елашып та алабыз.

***– Балаларда математика фәненә кызыксыну уятыр өчен, нинди ысуллар кулланып эшләдегез?***

– Кечерәк сыйныфларда күбрәк уен формасын кулландым. Олы классларда укучыларга бу фәннең никадәр кирәкле булуын сүз белән аңлатырга, җиткерергә тырыштым, төрле дәлилләр китерә идем.

Математик кичәләр, викториналар кебек класстан тыш чараларны да күп үткәрдем.

Укучыларым олимпиадаларда уңышлы катнашып килделәр. Ә бер елны бердәм дәүләт имтиханнарында җыелган балларның саны буенча район күләмендә икенче урынга да чыккан идек әле. Бу – яхшы күрсәткеч.

Аллаһыга шөкер, укыткан балаларым лаеклы кешеләр булып үстеләр, мәктәпне медальгә тәмамлаучылар да булды. Төрле тармакларда эшлиләр, араларында дин әһелләре дә бар. Мәсәлән, Зубчаниновка бистәсе мәчетенең имамы Расих хәзрәт Вакказов – минем укучым.

***– Тормышта киңәшчеләрегез кем?***

– Әниемә, каенанама бөтен серләрем сыйды, киңәшләренә һәрвакыт колак салдым. Бианам Гамбәр белән 24 ел бергә гомер иттек. Ул бик акыллы хатын иде. Аллаһыга шөкер, сүзгә килмәдек, дус тордык.

Бүгенге көндә дә киңәшерлек кешеләрем бар. Ике сеңелем, энем, туганнарым, иремнең апалары белән туганлык җепләрен саклап, аралашып, күрешеп яшибез.

***– Тормышыгызны яңадан башларга туры килсә, берәр нәрсәне үзгәртер идегезме?***

– Бернәрсәне дә үзгәртмәс идем. Тормышымнан канәгать мин, Аллаһыга шөкер. Кадерле ирем, газиз бала-оныкларым, сөекле туганнарым, хөрмәтле авылдашларым булуы, туган җиремдә гомер итүем – олуг бәхет.

Яраткан эшемне башкардым. Балаларга белем бирү, үзләрен тәрбияләү – җитди хезмәт бит ул. Һәм шуның уңай нәтиҗәләрен күрү минем өчен, әлбәттә инде, зур сөенеч булып тора.

Әлһәмдүлилләһ, Раббыбыз дин юлыннан атларга насыйп итте. Намазларымны калдырмаска тырышам, мәдрәсәгә укырга йөрим. Вафат булган якыннарым рухына догалар кыла алам. Бу аерым бер олы бәхет булып тора.

Аллаһы Тәгаләдән дөньяларыбыз тыныч, барыбызның да киләчәге якты булсын, дип үтенәм.

Нәфия Муллабаева белән бергә эшләгән укытучылар хезмәттәшләре турында түбәндәге фикерләрен җиткерделәр.

***Суфия Сәлимова:***

“Без Нәфия белән әле Алешкино авылында бергә эшләдек. Мине анда директор итеп куйдылар, ә ул укытучы иде. Бер бүлмәдә яшәдек, яхшы иптәшләргә әйләндек. Гали мәктәбенә күчкәч тә, дуслыгыбыз дәвам итте. Гаиләләребез белән йөрештек.

Нәфия – акыллы, тыныч, сабыр холыклы, ипле хатын.

Минем Лилия кызымның, Шамил улымның сыйныф җитәкчесе иде ул.

Мәктәптә бөтен күңелен биреп эшләде, укучыларының һәрберсенә игътибарлы булды, аның балалары укуда да, класстан тыш чараларда да гел актив, алдынгылардан саналдылар. Яхшы тәрбия дә бирде ул аларга. Укучылары тәртипле, җаваплы, тыңлаучаннар иде.

Гомумән, Нәфия ханым – зур хәрефтән язарлык Укытучы!”

***Рушания Манашева:***

“Нәфия апа мөгаллимә буларак та, кеше буларак та, бары тик мактау сүзләренә лаек. Тыйнак, түземле, ярдәмчел, дусларының кадерен белүче кеше ул.

Аны укучылары да, хезмәттәшләре дә бик яратты. Үз фәнен үтемле итеп аңлата иде ул. Без дә, балалар да Нәфия ханымны сагынабыз.

Мин, укытучы һөнәрен үзләштереп, туган мәктәбемә эшкә урнаштым. Мөгаллимнәребез миңа, яшь белгечкә, ярдәм кулын суздылар, акыллы киңәшләрен, үгет-нәсыйхәтләрен бирделәр. Шуңа күрә эшләп китүе җиңел булды. Барысына да Аллаһының рәхмәтләре яусын.

Нәфия апа минем балаларымны укытты. Аларга яхшы тәрбия, математика фәненнән тирән белем биргәне өчен аңа бик рәхмәтлемен”.

***Нурия Сәйфетдинова:***

“Нәфия ханым турында рәхәтләнеп сөйләргә була, чөнки ул – искиткеч яхшы кеше. Бик тәртипле, оялчан, уңган, аш-суга да оста.

Бер коллективта рәхәтләнеп эшләдек, туганнарча мөнәсәбәттә, бердәм идек без. Аны бик сагынабыз. Эштән иртәрәк китте шул, дип күңелсезләнәбез. Яңадан мәктәпкә килегез, дип чакырганыбыз да бар, әмма ул хәзер вакытын оныкларына багышларга тели.

Нәфия ханым – үз эшенең остасы, югары профессионал, затлы укытучы, чын остаз. Язучы, шагыйрь Фәнис Яруллинның “Сез иң гүзәл кеше икәнсез” дигән шигъри юллары Нәфия ханым Муллабаевага бигрәкләр дә туры килә инде!”

Мәкаләмә Нәфия апа укыткан укучыларның фикерләрен дә өстәсәм, язмам эчтәлеклерәк булыр, дип, аларга мөрәҗәгать иттем.

***Алсу Әбүзәрова (кыз фамилиясе – Маннанова):***

“Нәфия апа 5–11 сыйныфларда безнең класс җитәкчебез иде. Аны бары тик җылы хисләр белән искә алам мин.

Ул таләпчән, әмма гадел укытучы булды. Мәрхәмәтле, кеше хәленә керүчән, сокланырлык






шәхес. Үз һөнәрен һәм укучыларын чын күңелдән яратып эшләде, һәрберебезгә игътибарлы иде. Кирәк чакта ачуланып та ала, вак-төякләргә күзен дә йома белде ул. Без, укучыларының, проблемаларын тыңлап, акыллы киңәшләре белән һәрвакыт ярдәм итте. Ә Нәфия апа табигать кочагында үткәргән класстан тыш чараларны онытырлык түгел!

Мөгаллимәбезгә фидакарь хезмәте, укучыларына күрсәткән искиткеч мөнәсәбәте өчен Аллаһының рәхмәтләре яусын!”

***Рания Гәрәева:***

“Безнең сыйныф җитәкчебез Нәфия апа – һәрьяклап килгән, сәләтле, акыллы кеше. Елмаючан, сөйкемле, ачык йөзле ул, матурлыкны күрә белүче. Таләпчән, гадел, укучыларына карата һәрвакыт әдәпле (тактичный) булды, безне әниләрчә яратты, хөрмәт итте.

Гомуммәктәп чараларның барысында да диярлек без беренче урыннар яулап килдек, чөнки Нәфия апа оста оештыручы да, фантазиясе дә бай аның, һәм ул, безне һәрвакыт хуплап, яңа уңышларга этәрде.

Безнең өчен Нәфия апабыз – иң яхшы укытучы һәм иң яхшы сыйныф җитәкчесе! Ул безгә тирән белем генә түгел, яхшы тәрбия дә бирде”.

***Лилия Гыймадиева (кыз фамилиясе – Сәлимова):***

“Нәфия апа күркәм сыйфатларга ия. Аны гел сагынып, яхшы сүз белән генә искә алабыз без. Бөтен укучыларын бертигез күрде ул, барысын да бертигез яратты. Көчле укытучы, темаларны шулкадәр яхшы аңлата, үз фәненә мәхәббәт тәрбияли белә иде.

Мәктәптә без актив класс булып саналдык. Сыйныфыбызда яхшы укучылар, биючеләр, җырчылар күп булды. Нәфия апа, безнең барлык идеяларыбызны хуплап, булышлык күрсәтеп торды.

Укытучыбыз бездә җаваплылык, миһербанлык, ярдәмчеллек, эш сөючәнлек сыйфатларын тәрбияләде. Әле дә исемдә – сыйныфташыбыз Шамилгә операция ясагач, Нәфия апа, бөтен классны җыеп, безне аның хәлен белергә алып барды.

Аның җитәкчелегендә төрледән-төрле чараларда катнаша идек. Авылыбыздагы Бабкай чишмәсен чистарту буенча өмәгә барганыбыз да хәтеремдә.

Гомумән, үз эшен өзелеп яратучы мөгаллимәбез өчен мәктәп икенче өе иде, ә безне үз балаларыдай якын күрде ул. Шулкадәр тырышып, бөтен йөрәген биреп эшләгән, укучыларын лаеклы кешеләр итеп тәрбияләгән Нәфия апабызга Аллаһы Тәгалә исәнлек, гаилә бәхете, озын гомер, җан тынычлыгы насыйп итсен!”

Язмам герое, аның хезмәттәшләре, укучылары белән аралашканнан соң, Нәфия апаның һөнәре аңа Аллаһы Тәгаләдән бирелгән вазифа, дип уйлап куйдым. Чыннан да, бу ягымлы ханымның йөрәк түрендә мөгаллимә дип язылып куелган!

# ИЛДАР КАМАЛТДИНОВ: “ИЛ ӨСТЕНӘ АФӘТ КИЛГӘНДӘ, БЕРДӘМ БУЛЫРГА КИРӘК”




## Ни өчен отставкадагы офицерлар тагын кайнар нокталарга баралар?

***Хәрби кеше гомер буе хәрби булып кала, диләр. Яшь гомерләренең бер өлешен, кулларына корал тотып, Ватанны саклауга багышлаган элекке хәрбиләр, запаска яки отставкага чыккач, дәүләт түләгән лаеклы пенсияне алып, ташламалы санаторий, шифаханәләрдә дәваланып, тыныч тормышның тәмен татып яшәргә хокуклы. Әмма алар арасында, көч-куәтләре, исәнлекләре нык булганда, Ватанына файдалы булырга теләүчеләре дә шактый.***

*Эльмира Сәйфуллина*

Өч дистә ел гомерен эчке эшләр системасында хезмәт итүгә багышлаган, Төньяк Кавказ (Чечен Республикасы) якларында кайнар нокталарда күпсанлы командировкаларда булган кешене, лаеклы ялга чыккач та, хәрби хезмәтен дәвам итәргә нәрсә мәҗбүр итә соң? Әлеге соравыма җавап табарга Камышлы районының Иске Ярмәк авылында туып-үскән, отставкадагы офицер Илдар Камалтдинов ярдәм итәчәк.

Якташыбыз хезмәт юлын тәмамлаган елларда башта авылда яшәүче әнисе бакыйлыкка күчә, аннан соң әтисе бөтенләй сукырая. Шулай итеп, Илдар берничә ел карт әтисен карый. Ул да мәңгелеккә күзен йомгач, мәкаләм герое илебезнең төрле төбәкләренә сибелгән хәрби дуслары белән киңәшләшә, һәм алар Украинада барган махсус хәрби операциягә китәргә булалар. Шулай итеп, майор Илдар Салахетдин улы хәрби хезмәтен «Барс» (ав-









тор искәрмәсе: *Боевой армейский резерв страны или Боевой армейский резерв специальный (БАРС)* – Россия Федерациясе Оборона министрлыгының мобилизацион резервы) батальоны составында дәвам итә. Аны беренче көннән үк взвод командиры итеп билгелиләр.

Иң элек, тәҗрибәле офицер, һәрбер солдат белән танышып, кемнең кем икәнен ачыкларга тырыша.

– Хәрби биремнәр үтәгәндә, янәшәңдә ышанычлы, сыналган, бер-береңне күз карашыннан аңлый белүче кешеләр булырга тиеш. Мәрхүмә әбием: «Дустың үзеңнән яхшы булсын», – дип әйтә иде. Кайнар нокталарда бу әйтемнең никадәр дөрес булуына кабат-кабат инанасың. Гомумән, яу кырында, бер йодрык кебек, нык команда булырга кирәк. Син эшлә дә, син эшлә, дип торышлар булырга тиеш түгел.

Минем взводта төрле кайнар нокталарны узган хәрбиләр дә, элек кулына автоматны тотып та карамаганнары да бар иде. Шуңа күрә мин, алар белән сөйләшеп, хәрби хәрәкәттә катнашырга әзерме-юкмы икәнлекләрен белештем, үзләренә белгертмичә генә, бертөрле психологик тест үткәрдем, дисәм дә була. Украинада барган конфликтны моңа кадәр телевизордан гына күргән кешеләрдә, чынбарлык белән очрашкач, хәрби операциядә катнашу теләге юкка чыгарга мөмкин. Мин моңа бер дә гаҗәпләнмим һәм аларны гаепләмим. Һәрбер кешенең үз фикере, карары булырга тиеш. Бу турыда мин солдатларга да әйттем, алгы сызыкка кергәнче, әйбәтләп уйларга тәкъдим иттем. Карарының дөрес булуында икеләнүчеләргә бу куркыныч эшкә алынмаска киңәш бирдем. Хәтта берничә кайнар ноктада булып кайткан тәҗрибәле хәрбиләр дә, берникадәр тыныч тормышта яшәгәннән соң, ут эченә кергәч, бераз каушап калалар. Калырсың да, уен эш түгел бит.., – ди Илдар.

***– Сез – утны-суны кичкән, ничә кайнар ноктада булган кеше бит инде. Лаеклы ялга чыккач, үз теләгегез белән кабат хәрби операциядә катнашырга сезне нәрсә этәрде?***

– Бу сорауны миңа күп тапкыр ишетергә туры килде. Кайнар нокталарга акча эшләр өчен баралар дип уйлаучылар да шактый... Кеше гомереннән дә кыйммәт нәрсә юк, минемчә, шуңа күрә алай уйлаучылар белән бәхәсләшеп торуны урынсыз, дип саныйм.

Украинага баруымның сәбәбе: яшь егетләрнең гомерен саклап калырга ярдәм итү. Хәрби тәҗрибәм, чыннан да, зур. Айлар буе тау-таш арасында, урманлыкларда, ашамыйча-эчмичә, дошманга каршы торырга туры килде. Ә махсус операциядә катнашучы егетләрнең күпчелеге хәрби тактика төшенчәсен ишеткәннәре дә юк, автомат һәм башка сугыш коралларын, бәлки, китапларда яисә телевизордан күргәннәрдер. Шуңа күрә мин үземне алар янында файдалырак итеп хис итәм. Аяк астындагы «ле-



пестоk» миналар, «растяжкалар» һәр тарафта сибелгән. Бер ялгыш адым да кешенең гомерен өзәргә мөмкин. Яшь солдатлар янында, һичшиксез, күпне күргән офицер булырга тиеш. Үзем белгәннәрне, бераз гына булса да, үзләренә өйрәтә алсам, алар, киләчәктә бу тәҗрибәне кулланып, үз-үзләрен сакларлар иде, дип бардым мин махсус операциягә, – ди майор Камалтдинов.

Аның чираттагы командировкага җыенуын соңгы көнгә кадәр, балачак дусты, кодасы Марс Йосыповтан башка, беркем дә белмәгән. Бу хәбәрне гаиләсеннән ни өчен яшергәне аңлашыла инде. Әтиебез инде лаеклы ялда, Аллаһыга шөкер, дип җиңел сулап куйган тормыш иптәше Фәридә, улы Ленар, кызы Азалия өчен гаилә башлыгының бу карары күңелсез «сюрприз», билгеле.

– Кая барасымны белдем. Шуңа күрә, алай-болай була калса, гаиләмне авыр хәлдә калдырмас өчен, үлемтекләр, сәдакалар һәм башка кирәк-яракларны качырып кына үз кулларым белән әзерләп куйдым. Бу турыда Фәридәгә хәрби комиссариатта саубуллашкан чакта гына әйттем.

Кызганыч, әмма минем белән киткән хәрбиләрнең үз аяклары белән туган якларына әйләнеп кайта алмаучылары да шактый булды, – дип авыр сулап куйды Илдар.

***– Сугышчан бүләкләрегез турында да кызыксынмыйча булдыра алмыйм.***

– Өч дистә елга якын хезмәт иткән дәвердә 17 медаль, 13 мактау билгесе белән бүләкләндем. Ләкин мин аларны тагып йөрергә дә, күрсәтергә дә яратмыйм. Чөнки кайнар нокталарга бүләк алу өчен бармадым. Ә һәрбер медаль ниндидер авыр сынау, каты бәрелеш, зур югалтулар белән бәйле. Алар минем генә казаныш түгел, һәрберсендә сугышчан дусларымның, тормыш иптәшем Фәридәнең дә өлеше бар, дип саныйм. Мин командировкаларда вакытта ул ике балабызны тәрбияләп үстерде. Гаилә өчен җаным тыныч булмаса, яу кырында миңа кыен булыр иде. Беренче көннән башлап, минем өчен ышанычлы тыл булганы өчен Фәридәмә бик зур рәхмәт.




***– Улыгызның сезнең юлны дәвам итәргә теләвен ничек кабул иттегез?***

– Ата кеше буларак, улымны чын ир-егет итеп тәрбияләргә тырыштым. Ул сайлаган юлны, карарын хөрмәт итәм. Баланы үз теләгенә каршы нәрсә белән булса да шөгыльләнергә мәҗбүр итү яхшы нәтиҗәгә китермәячәк. Бүгенге көндә улым үзе дә әти кеше – ике кызы үсеп килә, кызыбыз да тормышта. Мин алар өчен, беренче чиратта, әти булсам, икенчедән, дус булырга тиеш, дип уйлыйм. Ата-ана буларак, без балаларыбызның тормышын читтән генә күзәтеп, кирәк урында киңәш яки башкача ярдәм итәргә әзер торабыз. Аларның үз тормышлары, үз юллары, һәрнәрсәгә үз карашлары.

***– Илдар, әйтегез әле, хәрби операцияләрдә җиңү яулау өчен, берәр төрле универсаль «рецепт» бармы?***

– Илгә куркыныч янаганда, шәхси проблемалар, сәяси карашларның төрле булуы, үзара килешмәүчәнлекләр турында онытып, берләшергә һәм дошманны тар-мар итәргә кирәк. Дәүләт эчендәге мәсьәләләрне, ыгы-зыгы тынычлангач та, хәл итеп була бит. Бөтен асылы менә шул, минемчә...



# Кешеләр китә, ләкин алар урынына хәтер кала! Эшләре, игелеге, изгелеге кала!

***Рөстәм Хисмәтов Камышлы районында гына түгел, ә аннан читтә дә бик әйбәт билгеле иде. Лаеклы ялга чыкканчы, ул, стоматолог буларак, үз якташларына гына түгел, ә төрле төбәкләрдә яшәүче кешеләргә дә югары сыйфатлы хезмәт күрсәткән. Аның рәхмәтле клиентлары, авырту турында онытып, Россиядә Төньяк Пальмирадан Себергә кадәр, хәтта Грециядә һәм Беларусь Республикасында да тормышларына шатланып яшәүләрен дәвам итәләр.***

***Эльмира Сәйфуллина***




Әйе, кызганычка, бүгенге көндә Рөстәм Әхсәнович турында үткән заманда сөйләргә туры килә. Чөнки ул 2023 елның 16 сентябрендә, юл һәлакәтенә эләгеп алган җәрәхәтләрдән терелә алмыйча, мәңгегә күзен йомды.

Ләкин аңа якташлары тешләрен дәвалаган өчен генә рәхмәт әйтми. Рөстәм Әхсәнович һәрвакыт гаилә һәм мәдәни кыйммәтләрне ныгыту, бәхетле балачак, яшьләрнең белем һәм иҗади уңышларын үстерү өчен шартлар тудыру максатыннан төрле чаралар оештыруда актив ярдәм итә иде.

Камышлыга 10 яшендә кайтып төпләнгән булса да, бу якларны ул үзенең туган ягы, кече Ватаны дип санаган. Гаиләсе Казахстаннан Самар өлкәсенә күченгәч, әтисе колхозда эшләгән, ә әнисе җиде бала тәрбияләү белән шөгыльләнгән. Табиб булырга уйламаган да ул. Куйбышев медицина институтына дусты артыннан барып кына укырга кергән. Ә стоматологка, башка юнәлешләргә караганда, бер елга азрак укырга кирәк булганга, шушы һөнәрне сайлаган. Һәм нәкъ менә бу һөнәр аның өчен гомерлек яраткан эшенә әверелгән.



Илле яшенә кадәр Рөстәм Әхсәнович башта Кләүле үзәк район хастаханәсендә, аннары Камышлы үзәк район хастаханәсендә эшли. Һәм теш авыртуыннан интегүчеләр һәрвакыт нәкъ менә аңа эләгергә омтылганнар. Башка табиблар эшсез утырганда да, Хисмәтов кабинеты янында чират беркайчан да бетмәгән. Мондый ышанычны ул югары дәрәҗәдәге һөнәри профессиональлеге һәм пациентларга игътибарлы булуы белән яулаган.

Шуңа күрә, шәхси стоматология клиникасы ачканнан соң, клиентларга кытлык беркайчан да кичермәгән.

«РуСтома» башта Рөстәм белән Гөлсинәнең шәхси йортының бер бүлмәсендә урнаша. Бераздан Хисмәтовлар, өйләренә өстәп, бина төзиләр, һәм шунда чын мәгънәсендә клиника эшләп китә. Анда комплексы стоматологик ярдәм өчен барлык кирәкле җиһазлар, шул исәптән рентген-аппарат та бар. Шәхси бизнеста гаилә башлыгы 13 ел эшли. Аннары үз эшен өлкән улы Маратка тапшыра. Ул, энесе Ринат кебек үк, Кләүле үзәк район хастаханәсендә стоматолог булып эшли. Рөстәм һәм Гөлсинәнең өченче улары Руслан да әтиләре эзләре буенча киткән. Ә төпчекләре Илнар исә, әнисе сукмагы буйлап, икътисади юлны сайлаган.

Уллары белән Рөстәм Әхсәнович аерым горурлана иде. Аларга ул тормышта уңышларга ирешергә ярдәм итүче хезмәт сөючәнлеген һәм максатчанлыгын җиткерә алган. Күптәннән якташларының хөрмәтен яулаган гаилә башлыгы дүрт улы һәм оныклары өчен чын үрнәк булды. Рөстәм Әхсәновичның район һәм өлкә дәрәҗәсендәге күпсанлы бүләкләрен атап чыгар өчен, журналның тулы бер битен биләргә туры килер иде. Иң югары дәрәҗәлеләре арасында «Меценат» номинациясендә өлкә премиясе лауреаты дипломы, 2017 елда «Ир-ат - гаилә башлыгы» өлкә иҗтимагый акциясенең «Ел ир-егете» номинациясендә алган титулы, авыл һәм район алдындагы казанышлары өчен медальләр дә бар.

Инициативалы һәм эшлекле, кече Ватанның барлык проблемаларын йөрәгенә якын кабул итүче кеше буларак, Рөстәм Хисмәтов лаеклы ялда да кул кушырып утырмый. 2019 елда «Туган як» иҗтимагый оешмасын оештыручыларның берсе була. Оешманың төп бурычы итеп җирле дәрәҗәдә милли мәдәниятне һәм традицияләрне күтәрү куела. Шулай итеп, «Туган як» Камышлыда Бөтенроссия авыл Сабан туен оештырудан һәм үткәрүдән читтә калмый. Оешманың президенты Раилә Сафина, директоры Рөстәм Хисмәтов һәм оешма активистлары туган якны өйрәнү, нәсел шәҗәрәләрен төзү һәм үстерү, гаиләдәге элемтәләрне һәм буыннар бәйләнешен ныгыту гамәлләрен дә оешманың төп бурычлары исемлегенә кертәләр. “Туган як” оешмасы районның топонимик (географик атамалар) электрон картасын булдыру өстендә дә эш алып бара. Шактый авыл-



ларда активистлар тырышлыгы белән чишмәләрнең, елгаларның, калкулыкларның, урамнарның һәм башка географик объектларның исемнәре, аларның ничек барлыкка килүе турында язып алынган. Авыл зиратларында элек җирләнгән кешеләрнең исемлеге дә булдырылачак һәм киләчәктә дә алып барылачак. Кызганычка, Камышлыда элек зират дәфтәре булмаган. Оешма активистлары, җирләнгән кешеләрнең исем-фамилияләрен язып алып, электрон картотека төзегәннәр. Шундый эшләр Яңа Усман, Дәүләткол авылларында да башкарылган.

2021 елда оешма “Туган як” дип аталган зур бәйге уздырган. Төбәкне өйрәнүгә юнәлтелгән бу чарада яше дә, карты да катнашкан. Рөстәм әфәнде КВН, «Авыл чибәре» кебек район күләмендә узган бәйгеләрдә дә төп иганәчеләр исемлегендә еш очрый иде.

Рөстәм Әхсәнович туган як табигатен бик ярата иде. Язын-көзен өмәләр, Сок елгасы ярларында даими тәртип урнаштырулар оештыра иде. Хәтта коронавирус пандемиясе вакытында да ул өйдә кул кушырып утыра алмаган һәм, яр буена чыгып, чүп-чар җыйган. Сок буенда туган авылында ял итү зонасы булдырырга хыялланган. Авылдашлары һәм авыл кунаклары, анда ял итеп, Камышлы җиренең матурлыгыннан ләззәт ала алсын, дип тырышкан.

Бераз буш вакыты булганда, якташыбыз, кармагын һәм фотоаппаратын алып, табигать кочагында вакыт уздырырга ярата булган. Аның фотосурәтләре Камышлы якларының гүзәллеген еракларга танытты. Туган авылында Хисмәтов фотокүргәзмәләре күп тапкырлар оештырылды. Хәтта аның вафатыннан соң да, 2023 елның октябрендә, Камышлыда чын комсомол, патриот һәм гражданин, матурлыкны бәяли белүче, профессионал һәм чын Кеше Рөстәм Әхсәнович Хисмәтовның фотокүргәзмәсе узды.

Кешеләр китә, ләкин алар урынына хәтер кала! Эшләре, игелеге, изгелеге кала! Һәр кеше Җиргә үз миссиясен үтәү өчен туа. Кешеләргә яктылык, бәхет һәм сәламәтлек бүләк итә, башкаларга ярдәм күрсәтә, дөньяны матуррак итә. Кайберәүләр үзе белән таныш булган һәр кеше күңелендә якты эз калдыра. Андыйларның күңел җылысы, вакытында әйтелгән яхшы сүзе, аларның тормышлары, якты йолдыз кебек, дөньяны барыбыз өчен дә яктыртып тора.

Рөстәм Хисмәтов нәкъ шундый кеше булган. Аның турында үткән заманда сөйләве бик авыр, «иде» сүзе Рөстәм Әхсәнович турында сөйләгәндә туры килми. Ул үзе, җан җылысы, игелекле, якты елмаюы, кешеләргә карата яхшы мөнәсәбәте, аның иҗаты мәңгегә якты маяк булып калачак.




# ОХОТНИКИ ЗА ВОЗМОЖНОСТЯМИ,

## или Как провинциальным «уставшим банкирам» удалось создать федеральный бизнес




***Осенью этого года вышла в свет книга наших земляков Рамиля Гизатуллина и Владимира Борзунова под названием «Бизнес с гарантией». Бизнес-роман, а именно так свою творческую работу обозначили известные самарские предприниматели, повествует от имени создателей федеральной консалтинговой компании «Тендер Консалт» о том, как парням из провинции удалось построить масштабный бизнес, создать первоклассную команду единомышленников, выйти на миллиардные продажи и успешно продолжать масштабировать свою деятельность.***

***Данияр Сайфиев***

Первоначально книга была издана тиражом всего 300 экземпляров и предназначалась для сотрудников и друзей компании. Однако увлекательное и легкое повествование, основанное на реальной истории успешного бизнес-проекта, не оставило равнодушными не только коллег авторов этого проекта и тех, кто только задумывается о создании собственного дела, но и людей совершенно далеких от предпринимательства. Поэтому было решено выпустить дополнительный тираж этого издания, а книгу уже сегодня каждый желающий может приобрести на маркетплейсе OZON.

С одним из авторов этого бизнес-романа Рамилем Гизатуллиным изначально я планировал поговорить именно о книге, а в итоге у нас получился интересный и продолжительный разговор о компании и целой бизнес-философии, которая привела «Тендер Консалт» к успеху.

***– Рамиль, я поздравляю тебя с выходом первой книги, и хотелось бы узнать: какие цели авторы ставили цели, создавая этот роман?***

– Книга – это воплощение той идеологии, которой мы придерживаемся в нашем бизнесе. Мы себя позиционируем себя как открытая компания. Честность и открытость являются основными нашими принципами. Мы активно присутствуем в социальных сетях, где рассказываем о том, что у нас происходит, показываем наших сотрудников, рассказываем о том, каких успехов мы добиваемся, делимся своим опытом и наработками. Всё это позволило «Тендер Консалт» стать одним из лидеров на российском рынке. Работая над книгой, мы ни в коем случае не ставили цели написать

про «успешный успех» или давать кому-то нравоучения. Исходили из того, что кому-то может стать полезным наш опыт, поможет избежать тех ошибок, которых в своем становлении допустили мы. С моим партнером Владимиром Борзуновым изначально строили системный и открытый бизнес, который сегодня конкурирует с федеральными компаниями и банками. Нам удалось собрать замечательную команду. Мы знаем рынок, наших конкурентов, и знаем, куда и как нам двигаться дальше. Открытость в социальных сетях привлекает к нам не только клиентов, но и наших конкурентов, с которыми мы также предельно откровенны и, как это ни странно, делимся своими кейсами. Рынок большой, и места на нем хватит всем.

***– Давай сразу проясним для читателей специализацию вашей фирмы...***

– Мы помогаем компаниям и юридическим лицам получать банковские гарантии, кредиты, факторинг, лизинг, страхование. Одним словом, всё, что связано с финансами. Например, та или иная организация выигрывает на «Госзакупках» конкурс, но без банковской гарантии контракт не будет подписан. Государство специально придумало и создало такую конкурентную площадку, чтобы бюджетные средства тратились максимально эффективно и без рисков для бюджета. Получается, что банки поручаются за тех, кто исполняет госконтракт. Строится, к примеру, школа стоимостью в 1 миллиард рублей. Нужна банковская гарантия на 300 миллионов. Мы помогаем такую гарантию получить. И если клиент не успевает получить гарантию и контракт не подписан, то он попадает в реестр недобросовестных поставщиков и больше уже не сможет нигде участвовать. А, значит, такой бизнес рушится. Сегодня в нашей компании обсуживается порядка 6 тысяч юридических лиц со всей России – от Калининграда до Находки. Сейчас в работе нашего отдела продаж находятся почти 20 тысяч юрлиц, которых мы обрабатываем. Работа эта не быстрая: иногда от знакомства с клиентом и до первой его заявки в нашу компанию может пройти года два и больше. В среднем, конечно, меньше. Мы работаем почти со ста банками страны. Приходя к нам, клиент получает доступ во множество банков. Также мы работаем с лизинговыми, факторинговыми и страховыми комрпаниями, так как клиенты достаточно часто страхуют свои контракты.

***– Но ведь у каждого банка есть свои отделы по работе с клиентами. Для чего им посредники?***

– Это только кажется, что у них есть классные отделы продаж. Их, по сути, заменяем мы, работая на аутсорсинге. Продажи – это одна из самых сложных структур в любом бизнесе – и по созданию, и по управлению. Чтобы привлекать клиентов со всей России банки должны содержать гигантские отделы продаж, которыми нужно управлять, повышать компетенции сотрудникам. Не каждая финансовая организация на такое способна. Сейчас в России нет ни одного банка, который полностью бы работал через собственные отделы продаж. Все они постепенно переходят к той системе, в которой мы работаем. Мы не только предоставляем им классный сервис, но и избавляем от головной боли по администрированию своих отделов и даем поток клиентов. Банкам это дешевле, удобнее и быстрее.

***– Насколько высока конкуренция в этой сфере?***

– Она большая. Системных крупных компаний, как наша, в стране порядка двадцати, но на рынке есть еще и частные брокеры, работающие из дома. По нашим оценкам, их осталось около пяти тысяч, но и среди них мы наблюдаем тенденцию к укрупнению. Наш бизнес, с точки зрения захода в него, достаточно прост. Главное – нужно уметь привлекать клиентов. Это самая большая компетенция, которая есть в нашей компании. Причем клиентов не только привлекать, но и системно их обслуживать. У нас от поступления заявки до реагирования на нее проходит не более 13 минут. Чтобы достичь такого уровня, мы потратили порядка трех лет. Это – огромная работа, когда приходится менять всю систему, совершенствовать CRM (управление взаимоотношениями с клиентами). Все это требует немалых капиталовложений, которые частники и малые компании позволить себе не могут. Частник, который не смог справиться с поступившей заявкой, часто отдает ее своему конкуренту. Таим образом может образоваться целая цепочка посредников. В итоге клиент получает услугу по цене в 2–3 раза выше ее рыночной цены. Мы же работаем без посредников, и это огромное наше преимущество. В неделю мы привлекаем порядка 30–40 новых юридических лиц. Да, не все из них в итоге становятся нашими клиентами, но из тех, кто заключает с нами договор, в 92% случаев получат банковскую гарантию. Мы стараемся искать «портретных» клиентов, то есть тех, кто постоянно пользуется кредитами и гарантиями. И возвращаемость клиентов у нас не плохая. В месяц в виде гарантий мы выдаем порядка 1–2 миллиардов рублей. Это огромная цифра, учитывая, что весь российский рынок гарантий оценивается в 100 миллиардов в месяц. Мы сегодня занимаем порядка 1,5–2 процента рынка. Наша глобальная задача – выйти на 10 процентов. Мы знаем, как это сделать. У нас есть план, и в нашей стратегии – стать крупнее любого банка в стране.

***– Вы хоть и федеральная компания, но все-таки с самарской пропиской. В вашем пакете клиентов какое место в процентном соотношении занимают наши региональные компании?***

– Их около 10 процентов, и, как ни странно, самарских клиентов

с каждым годом становится все меньше. В Самаре рынок достаточно ограничен. Уже в самом начале, когда мы только создавали «Тендер Консалт», поняли, что не получится работать только на самарском рынке. Когда только сняли первый офис, с коллегой Кириллом Артюковым задумались можно ли продавать наши услуги где-то еще. Обзванивали начиная с 6–7 утра Дальний Восток, благо, что часовые пояса у нас разные, потом уходили на работу. Удалось привлечь клиентов из Сибири. Со многими из них мы до сих пор работаем. А то, что мы находимся в Самаре, а допустим, не в Москве – это еще одно немаловажное наше конкурентное преимущество. Ведь это – экономия и на аренде офиса, и на зарплатах, хотя они у нас очень достойные. Делать классный бизнес можно и отсюда, при этом полноценно конкурировать с коллегами.

***– Рамиль, в твоей книге не раз попадался термин «уставший банкир». Ты же и сам, проработав 14 лет в банках, относишься к этой категории. Ты создал собственную компанию и все равно продолжал работать в банке. Почему? Не верил в успех компании или чувство ответственности за благополучие семьи тебя сдерживало? Если бы с головой ушел в собственный бизнес, может, и развитие пошло бы быстрее?***

– Могло быть, наверное, по-другому, но произошло так, как произошло. Конечно, у меня были обязательства, семья, дети – двое мальчишек, которым сегодня 10 и 15 лет. Гарантийный бизнес – это лучшее, что я умел делать в банке. Филиал банка, в котором я тогда работал, мы сумели сделать самым крупным по выдаче гарантий. В 2011–2012 годах этот рынок только начинал формироваться. Когда однажды я поехал к одному из наших крупных клиентов, он рассказал, что пришлось срочно оформить банковскую гарантию, которую за три дня ему смог сделать какой-то парень из Москвы. Этот «парень из Москвы» несколько лет не выходил из моей головы. Неужели я не смогу сделать то, что смог сделать он?! Еще работая в банке, начал предпринимать какие-то попытки в этом направлении, но понял, что лучше двигаться в партнерстве. В итоге с Владимиром мы создали то, что создали. Мы с ним вместе учились, работали в одном банке, хотя и на разных направлениях. Он хороший технарь. Еще до создания нашей компании у нас



уже было сделано CRM и мы изначально строили системный бизнес с прицелом на то, что в последующем он станет лучшей компанией. Позже он сделал сайт, оцифровал все наши бизнес-процессы. Нам никогда не хотелось делать «киоск». Это – не наша история. Когда мы входим в какой-то проект, мы должны видеть перспективы. Мы научились мыслить масштабно. Даже на наших собраниях мы не обсуждаем мелочи, по типу как нам заполнить какую-то форму гарантии. У нас всегда разговоры идут о том, как нам захватить ту или иную долю рынка. Мы говорим о стратегии. Я не думаю, что мы потеряли какое-то время. Нет, продолжая работать в банке, мы тратили время на создание основы своей компании, результаты от которой мы сегодня пожинаем. Со временем мы поняли, что это идеальная формула партнерства. Когда ты в чем-то не разбираешься, а партнер разбирается, – получается симбиоз, способствующий успеху общего дела. Мне очень повезло с партнером. И с коллективом тоже. Сейчас у нас в компании работают около 60 человек и каждый занимается своим делом. И это очень круто. У каждого есть свой участок, они друг другу не мешают, мы можем масштабироваться, строить отделы, привлекать сотрудников и строить грандиозные планы.

Основная ценность нашей компании – это свобода. Во-первых, мы создаем классные условия для работы наших сотрудников, платим более, чем достойные зарплаты. Люди могут прийти на работу чуть позже и уйти чуть раньше, если есть такая необходимость, могут вообще работать из дома, если нет острой нужды приходить в офис…

***– …ну, после ковидных ограничений это становится уже всеобщей тенденцией…***

– Это сейчас тенденция, а у нас этот принцип работает с 2015 года. Мы предоставляем людям свободу. Дело в том, что и я, и мой партнер Владимир, мы – выходцы из банков. И знаем, что такое ограничения, когда ты должен приходить к определенному времени на работу и также в определенное время уходить. Мы хотели создать такую атмосферу, когда люди сами хотят идти на работу. Ведь не случайно у нас есть понятие «уставший банкир». Мы набирали людей (особенно в первое время) с банковским прошлым, которые были прекрасными специалистами, но устали жить по регламенту, не видели перспектив и не знали, что с этим делать. Здесь они свободны и более эффективны.

***– Для многих компаний найти компетентного грамотного сотрудника – это целый квест. Как вы решаете эту проблему? Где берете кадры? Сами их готовите или опять ждете, когда кого-то уволят из того или иного банка?***

– Каждому времени своя формула и свой рецепт. В самом начале мы опирались на банковских работников, искали работников через знакомых. Так продолжалось до 2019 года. А потом «уставшие банкиры» закончились. Вскоре один из крупных федеральных банков начал интенсивно набирать людей и вскоре так же интенсивно увольнять своих сотрудников. Грамотные и дисциплинированные ребята. Кого-то из них мы взяли в отдел сопровождения. Потом закончились и они. Начали искать людей на свободном рынке. Создали свой отдел кадров. Тогда же сделали для себя открытие, что руководитель вовсе не обязательно должен быть специалистом, а классный специалист, вероятнее всего, никогда не станет хорошим руководителем. Руководители не всегда вырастают из специалистов, и с этим надо смириться. Сегодня у нас работает слаженная профессиональная команда, способная меняться и внедрять новые подходы. Меняемся и мы сами, и управление бизнесом. Ведь одно дело управлять коллективом в 10–15 человек и совсем другое, когда в команде 60 человек.

Соответственно меняются цели и ставятся новые задачи. Я уже говорил, что мы своим сотрудникам стараемся создавать максимально комфортные условия. Хороший продажник может получать у нас 300–500 тысяч в месяц. И это официально. Мы делаем светлый бизнес, чтобы у нас у всех было светлое будущее. И этим очень горжусь. Многие, когда узнавали про наши условия, раньше крутили пальцем у виска, а теперь сами перенимают наш пример. Я – патриот своей страны и считаю, что она дает классные возможности для бизнеса, кучу налоговых режимов. И в правовом поле делать бизнес намного лучше, выгоднее и спокойнее, чем с использованием каких-то серых схем. Если это интервью будут читать молодые предприниматели, пусть они об этом задумаются. Ведь играя «вбелую», ты сможешь и кредитоваться, твои сотрудники могут оплачивать ипотеки, будут развиваться и расти, принося пользу организации. В противном случае ты получаешь риски, которые рано или поздно выстрелят. Нужно платить налоги, чтобы на что-то претендовать. По-другому это не работает.

***– Ты когда-нибудь задумывался о создании собственного банка?***

– Мы об этом думали, но отказались. У нас другая система работы, другой подход и нам нужна свобода. Нужна она и нашим сотрудникам. Мы и так, как банк, только лучше и масштабнее небольших региональных банков

***– Рамиль, ты рос в сельской местности в Новом Мансуркино. Когда ты понял, что ты хочешь стать банкиром? Это же неприсущая для сельских ребятишек ролевая модель.***

– У меня был очень хороший пример – руководитель Волжского универсального банка Наиль Манцурович Вахитов, который имеет отношение и к нашему селу и которого я очень уважаю. Зная о нем, я хотел работать в банке. Тогда я еще не догадывался, что это за работа, но знал, что это классно, и стремился стать банкиром. Учась в экономическом университете, после третьего курса я попал в его банк на практику. Был под огромным впечатлением. Для меня Наиль Манцурович был человеком, воплощающим все те мечты, о которых я задумывался. Был максимально горд, что работаю в банке. Я почему-то всегда думал, что стану банкиром…

***– А откуда предпринимательская жилка?***

– От родителей. Они всегда торговали чем-то. Возили мясо в Альметьевск, в нашем дворе реально было можно сказать, что было действующее предприятие. Делали сани, дровни, обменивали их по бартеру на скотину. Всё это резалось в промышленных масштабах и продавалось. Конечно, вся эта атмосфера не могла не сказаться на моем формировании. Это был огромный колоссальный сельский труд. Это ведь не просто содержать 2 коровы, у нас бывали времена, когда в сарае по 40 лошадей было, я уже не говорю о другой живности. У родителей была и есть сегодня своя пасека, выращивали до 200 гусей. Огромная ферма. Мы с сестрой чем могли помогали родителям. У нас всегда был достаток, новые машины. Но это ни в коем случае не прибавляло нам какой-то гордыни, но давало ощущение свободы. Родители всегда привозили какие-то вкусняшки, которыми я угощал своих друзей. Родители неделями были в поездках. Вставали в час-два ночи и ехали. Застревали зимой, ночевали в дороге, бывало, слетали с трасс. Куча таких историй. Мотивация на деньги, на благополучие – она была с детства. В нашей семье так было всегда еще со времен дедушки и бабушки, которые тоже были очень трудолюбивыми. Я считаю, что человек должен любить деньги, потому что – это возможности и свобода в разной степени ее воплощения. Это – возможность помогать, путешествовать, развиваться. Наверное, поэтому я не хочу, чтобы у меня в компании работали люди, которые не любят деньги. Я хочу, чтобы люди приходили и зарабатывали. Просто сидеть и протирать штаны – это точно не наша история.

***– Ты всегда говоришь, что деньги – это свобода. Но, судя по твоим командировкам, постоянной занятости, свободой здесь и не пахнет. Тебя в семье-то видят вообще?***

– По сравнению с банком, занятость стала значительно выше.

В течение года много приходится ездить по командировкам. Вот и в этот понедельник опять улетаю. Это меня пока не тяготит, ведь командировки – это тоже своего рода свобода воплощения возможностей. Стараемся вместе с детьми проводить каникулы, съездить на море или куда-нибудь погулять. В этом году хотели в деревне Новый год отметить, но уже 3 января мне нужно быть в Москве. Что-нибудь придумаем.

***– Сам ты рос в предпринимательской среде, а своих детей с супругой как воспитываете?***

– Я пытаюсь не очень навязчиво им намекать, что быть самодостаточными – это круто. Но у них мозг устроен по-другому. Такого стремления у них я пока не наблюдаю. Они – спортсмены, благодаря им я сам начал заниматься спортом. Младший – Руслан считает, что всего будет добиваться через спорт, через призму своих достижений. Старший – Рустам начинает задумываться о предпринимательстве, но такой вот прям мечты нет. Он еще не определился. Они совершенно разные ребята у нас. Предпринимательского начала, мне кажется, у них пока нет в силу их возраста. Хотя был период, когда старшему платили зарплату за то, чтобы он мыл полы в офисе. Заработал себе тогда на кроссовки.

***– Цену деньгам они знают?***

– Нет удобного ответа на этот вопрос. У меня у самого отношение к деньгам в последнее время философское. Я стараюсь о них вообще не думать. Они отвлекают внимание. У меня всеми финансовыми делами занимается супруга Юлия (она, кстати, тоже из Нового Мансуркино) – и на работе, и дома. У меня нет бумажника. У детей также. Младший Руслан копит деньги. Они летом ездят к бабаю в деревню, помогают с пчелами. У Рустама и Руслана там есть свой улей. Бабушка мед продает и деньги от продажи отдает им. У Руслана есть своя копилка, но денег он оттуда не берет, но стабильно каждый месяц контролирует, сколько процентов «натикало» на его инвестиции. А старший как будто безразличен к деньгам, но за обновками в магазин ходить любит.

***– Дети на татарском языке разговаривают?***




– Старший разговаривает, младший понимает, но не говорит. У нас прямо аномалия какая-та. В деревне бабушка с дедушкой пусть и на ломаном, но всё равно говорят с внуками по-русски. Рустам говорит на татарском, эбика отвечает на русском. К сожалению, дома тоже мы больше говорим на русском языке. Хотя с супругой – исключительно на татарском.

***– Рамиль, в конце нашего интервью не могу не спросить о планах компании. Когда-то вы ставили планку в ежемесячную выдачу гарантий на 1 миллиард рублей. Ее вы перешагнули. Что дальше?***

– После миллиарда эта мечта перестала быть мечтой, а придумать новую оказалось очень-очень не просто. Но мы с этой задачей справились и увеличение нашей доли на российском рынке до 10 процентов, кажется хоть и амбициозной, но вполне досягаемой очередной мечтой. Тем более с той командой, которая меня окружает. Также в наших планах – объединить усилия и компетенции крупных игроков рынка и создать свою профессиональную ассоциацию. А для меня эта идея подкреплена еще и практическим опытом. Дело в том, что я являюсь еще и президентом Самарского регионального отделения бизнес-сообщества «Эквиум», объединяющим основателей с крутым бизнесом. Скажу так, что, когда у нас выручка была 50–60 миллионов, у многих членов этого сообщества уже тогда она достигала 300–500 миллионов, а у кого-то и миллиард. Круг предпринимателей разной сферы, общение, обмен опытом, разбор кейсов, связи… Все это очень ценно для любой компании. Именно там мы подчеркнули для себя такие понятия, как «стратегическая сессия», «мозговой штурм», «бюджетирование», внедрение которых позволило нам справляться с возникающими трудностями и экономить месяцы, а то и годы, для увеличения результативности нашей работы. Не зря же говорят: одна голова хороша, а две лучше. Мы понимаем, что вместе всегда можно сделать больше.

***– Спасибо, что нашел время и согласился на интервью. Надеюсь вскоре увидеть продолжение вашего с Владимиром бизнес-романа.***

# БЕР ГАСЫР ГОМЕР. АЗМЫ УЛ, КҮПМЕ?

**Красный Яр районының Яңа Кызылсу авылында яшәүче Дөрия Исхак кызы Гайнуллинага 17 октябрьдә 100 яшь тулды**

***Йөз ел... Ул бит әйтергә генә җиңел. Шушы дәвер эчендә ил тарихында нинди генә вакыйгалар булмаган да, халкыбызга нинди генә сынаулар аша узарга туры килмәгән! Мәкаләбезнең герое, гомеренең 40 елын балалар укытуга багышлаган хезмәт ветераны, зур сугышлар, илебезне хәрабәләрдән торгызу чорларын күргән Дөрия апаның тормыш юлы китап язарлык.***

***Эльмира Сәйфуллина***



Юбилярыбыз 1923 елда Елховка районының Губан күл авылында Исхак һәм Хәдия Рамазановлар гаиләсендә беренче бала булып туган. Исхак абзый башта - гражданнар сугышында, аннан соң Бөек Ватан сугышында катнашкан.

Туган авылында башлангыч мәктәпне тәмамлагач, Дөрия укуын 20 чакрым ераклыктагы Тупли авылы мәктәбендә дәвам итә. Җиденче сыйныфтан соң бик тырышып укыган кызга бүләкләр тапшырып, Мәләкәс педагогика училищесына укырга җибәрәләр. Ике як әби-бабалары да, гыйлемле булып, мәдрәсәдә укыткангамы, Дөриягә укытучы һөнәре бик якын була. Мәләкәстә ул инсафлы һәм бик акыллы Хәлифә исемле мулла кызы белән дуслаша. Башлангыч сыйныфлар укытучысы дипломын алгач, кызлар Мулла авылына эшкә дә бергә кайталар. Әмма андагы мәктәптә укытучылар штаты тулы булу сәбәпле, аларны Кызылсу мәктәбенә җибәрәләр.

- 1941 ел, сугыш бара. Без, яшь белгечләр, хезмәт юлыбызны бик зур авырлыклар белән башладык. И-и-и, балакаем, без күргәннәрне яза башласаңмы!.. - дип авыр сулый Дөрия апа.

Кызылсуда бераз эшләгәннән соң, кызларны янә Мулла авылына чакырталар. Анда җәйге каникул вакытында укытучылар колхозда эшлиләр, Дөриягә «учетчица» булырга да туры килә. Ул авыл хатын-кызларының хезмәтен җентекләп язып бара. Табигате буенча бик гадел укытучы буларак, ул тол хатыннар һәм нужа тартсенә яшьли җигелергә мәҗбүр булган үсмерләрне кызгана. Шуңа күрә алар эшкәрткән җирләрнең бер сантиметрын да исәпкә алмыйча калдырмый.

Шулай, кызып китеп эшләп ятканда, яшь мөгаллимнәрне берничә айга хәрби укуларга алалар. Алар арасына Дөрия дә эләгә. Укытучыларны җыеп, Тимашево шикәр заводы янындагы хәрби лагерьга китереп урнаштыралар. 1943 елда, яңа уку елы алдыннан, мәкаләбез герое Мулла авылына кайта. Әмма аның урынына башка кешене алган булалар инде. Шулай итеп, Дөрияне кабат Кызылсуга җибәрәләр. Шул вакыттан башлап, ул бу авылдан беркая да китми. Дөрия апа Кызылсуны туган авылы, дип саный, аны бөтен җаны-тәне белән ярата, барлык кешеләрен хәтерли, бакыйлыкка күчкән барлык авылдашлары рухына изге догаларын укып тора.

Олы яшенә карамастан, аның хәтере бик әйбәт, күзләре күрә, аяк-куллары эшли, Аллаһыга шөкер. Тик менә колаклары гына бераз начар ишетә.

Дөрия апа татар матбугатын да укып бара икән. Мәсәлән, “Бердәмлек” газетасын беренче саныннан ук алдырып килә ул. Һәр санын сагынып көтеп ала, бер генә хәрефен дә төшереп калдырмыйча укып, барысын да кадерләп җыеп куя. Минем шушы газета хәбәрчесе икәнлегемне белеп алгач, ул бик зур хыялы чынга ашкан сабый баладай шатланды, йөзе яктырып, балкып китте. «Бердәмлек»кә нигез салучыларга, беренче мөхәррире Рәфгать абый Әһлиуллинга, бүгенге көндә газетаны чыгаручыларга, елый-елый, ихлас күңеленнән догалар кылды, саулык-сәламәтлекле озын гомерләр, дөньялыкта – дәүләт, ахирәттә Фирдәвес җәннәтләре насыйп булсын, дип теләр...

де. Сүз уңаеннан Кызылсу өчен бик күп изге эшләр башкарган авылдашы Шамил абый Галимовка да чиксез рәхмәтләрен җиткерде. Шулай ук Дөрия апа, кыюсыз гына, бер үтенече барлыгын да әйтте:

- Мин яшәгән дәвердә әллә ничә ил башлыгы алышынды, ә менә Владимир Путин кебек җитәкче булмады. Илебезне шулай алып барганы өчен Аллаһының рәхмәте яусын аңа! Мин үзенә исәнлеклесаулыклы озын гомер, Россияне озак еллар әйдәп баруын теләп, догалар кылам, - диде.

Искиткеч! Бүгенге көндә күз алдына да китерергә кыен булган тормыш сынауларын, күпме югалтулар, ачы кайгылар күргән кешенең никадәр көчле булуына карап сокланмыйча буламы соң?

Дөрия апаның әтисе Исхак абзый сугышта чакта, хатыны һәм ике кечкенә улы, асептик ангина белән авырып, үлеп китәләр. Училищены әле генә тәмамлаган 19 яшьлек кыз, Румия исемле 2 яшьлек сеңелесен кочаклап, япа-ялгыз кала. Үзенә ничек кенә авыр булса да, яу кырындагы әтисенә кайгылы хәбәрне ул мөмкин кадәр «йомшартып» җиткерергә тырыша. Румияне, әтиләре сугыштан кайтып, кабат өйләнеп, тормышы бераз нygыганчыга кадәр тәрбияли. Сеңелесен әтисе үз янына алгач, Дөрия 1950 елда



фашистларны тар-мар итеп кайткан сугыш ветераны Юныс Гайнуллинга тормышка чыга. Тиздән - уллары Котдус, аннары кызлары Наилә туа. Юнысны Куйбышев Югары партия мәктәбенә укырга җибәрәләр. Ул аны «5»ле билгеләренә генә тәмамлап кайта. Ул арада Кызылсу мәктәбенә күрше Михайловка авылы балалары да килеп кушылалар, урын җитми башлый. Парторг Юныс Гайнуллин тырышлыгы белән авылда зур яңа мәктәп төзелә һәм аны мәктәп директоры итеп куялар. Шулай итеп, гаилә башлыгына читтән торып педагогика институтын да тәмамларга туры килә.

Дөрия һәм Юныс Гайнуллиннар озак еллар бергә эшлиләр. Юныс ага география һәм тарих фәннәрен укыта. Аның кызыклы дәресләрен олы яшькә җиткән укучылары бүген дә сагынып искә алалар. Инде җитте-булды, дип, лаеклы ялга киткән Юныс абыйга, укучылары һәм ата-аналар үтенече буенча, янә үз эшенә кайтырга туры килә. Шулай итеп, ул соңгы сулышына кадәр һөнәренә тугры булып кала, 1994 елда яман чирдән вафат була.

Ә менә Дөрия апаны укучылары бик таләпчән, урыны белән кырыс, әмма бик гадел укытучы буларак искә алалар. «Аның «4»леләре бик күп «5»леләрдән дә югарырак иде», - дип сөйлиләр әниләре сыйныфында укыган Котдус абый белән Наилә апа.

«Үз балаларыңны, коллегаларыңның балаларын укытудан да авыррак сынау булмагандыр минем өчен, - ди Дөрия апа. – Гаделсезлек булмаса ярар иде, ул балаларны тигез күрми, дип әйтмәсәләр ярар иде, дип кайгыра идем. Минем өчен бөтен укучылар да бертигез булдылар, мин барысына да таләпчән идем».

Дөрия апа үз-үзенә карата да бик таләпчән булган. Ул һәрдаим белемен үстерү өстендә эшләгән. Камышлы педучилищесында, Куйбышевның укытучылар белемен үстерү институтында узган курсларда укыган, танылган якташыбыз Минзакир Шакир улы Нуретдиновның шәкерте булган.

Уллары - балачактан рәсем ясарга яраткан Котдус, Тольятти педучилищесының сәнгать графикасы бүлеген тәмамлагач, шул ук юнәлеш буенча Харьковта югары белем ала. Бүгенге көндә ул - Россия рәссамнары берлеге әгъзасы. Аның картиналары илебезнең төрле күргәзмәләрендә катнашалар, Япония, Финляндия, Франция кебек Аурупа илләрендәге шәхси коллекцияләрдә урын алып торалар. Газетабызның даими укучылары Котдус Гайнуллинның иҗаты белән таныштыр, дип уйлыйм. Котдус абыйның бер кызы һәм ике оныгы бүгенге көндә Самарда яшиләр. Ә үзе тормыш иптәше белән әниләре янында гомер итә.

Наилә апа да әти-әнисе юлын сайлаган. Ул, Куйбышев педагогика училищесында мәктәпкәчә белем бирү белгечлегенә укып чыгып, өченче санлы балалар йортында, аннан соң балалар бакчасында эшли.

Тормышка чыккач, Суходолга күченә һәм лаеклы ялга чыкканчы тәрбияче була. Аның да хезмәт стажы, Дөрия апаныкы кебек үк, 40 елга якын. Наилә апаның ике улы һәм биш оныгы үсеп килә. Бер оныгы әби-бабалары һөнәрен дәвам итәргә әзерләнә – педагогика көллиятендә белем ала.

Педагог һәм остаз елында үзенең 100 яшьлек юбилеен билгеләп үткән Дөрия Исхак кызы Гайнуллинага исәнлекле тыныч көннәр, җан тынычлыгы, балалар-оныклар шатлыгы телибез!

Укытучы дигән бөек исемне һәрбер кеше дә йөртә алмый. Аның өчен табигать биргән зур илаһи көч, сабырлык, зирәклек һәм акыл тирәнлеге, өмет, ышаныч һәм нык лы иман кирәк.

Дистәләгән сабыйлар күңеленә ачкыч табып, аларны мәгърифәт дөньясына җитәкләп керүегез өчен чиксез рәхмәт сезгә, Дөрия апа!



# БЕЗ ПРОШЛОГО НЕТ ДОСТОЙНОГО БУДУЩЕГО

***4 декабря свой 65-летний юбилей отметил Гумар Мулланурович Батршин – известный самарский предприниматель, меценат и благотворитель, основатель и руководитель культурно-исторического фонда «Булгарское наследие», человек, посвятивший свою жизнь возрождению и популяризации славного прошлого великого древнего государства – Волжской Булгарии.***

***Данияр Сайфиев***

Фондом Гумара Батршина построена мечеть в поселке Зубчаниновка, которая получила название «Булгарское наследие», инициировано строительство и установка памятного знака «Летящий барс» на Поповой горе в селе Ширяево, на том самом месте, где примерно находилась Южная граница Волжской Булгарии. Здесь же к 1100-летию принятия ислама Волжской Булгарией установлен памятный знак, а совсем недавно историческую площадку украсила еще и конная статуя основателя древнего государства – хана Котрага. Правда, то, что на коне восседает именно Котраг, известно не многим. Установка данного памятника вызвала немало споров и исто-





рических разногласий как среди некоторых жителей, так и местных властей. Поэтому до сих пор и нет на нем соответствующей таблички, указывающей на то, кому этот памятник поставлен.

Несмотря на возникающие трудности, Гумар Мулланурович привык доводить начатое до конца. По всей видимости, передалось это ему от его предков. И по отцовской, и по материнской линии предки Батршина в годы репрессий были раскулачены. Фигурируют в их непростых судьбах и ссылки, и тюрьмы. Несмотря на нечеловеческие условия, они сумели выжить, а позже обосноваться в Куйбышеве. Историю своего рода Гумар Мулланурович знает очень хорошо и может рассказывать о ней часами. Хотя в семье от детей тщательно скрывалось то, через какие испытания и трудности пришлось пройти их бабушкам, дедушкам и родителям. Чтобы узнать больше о своем роде, основатель «Булгарского наследия» обращался к ученым-историкам, которые помогли ему составить родословную и избавиться от многих «белых пятен» в истории своей семьи. Спустя годы эта работа нашла свое отражение в книге «Возвращение к истокам», которая, как и многие другие издания, была выпущена при поддержке фонда «Булгарское наследие». Так что в его увлечении событиями минувших дней есть очень много личного.

Страсть сына к познанию прошлого всегда поддерживалась и мамой Гумара Рабигой Харисовной, в доме которой хранилась богатая библиотека с книгами на разных языках. Повзрослев, Гумар



стал задумываться не только об истории своего рода, но и своего народа, родной земли.

– Я думаю, что желание познавать истинную суть истории своего народа пробилось из глубинных слоев моей души и сознания. Возможно, это некий зов наших предков, дошедший до нас как эхо тех славных времен. Ну а если объяснить более приземленно, то это началось с самого раннего детства. Когда мы переехали из города Альметьевска в Самару, я вообще не знал по-русски. При первом же выходе на улицу меня обозвали «татарской мордой» и разбили нос. В слезах пришел домой, а бабушка, разузнав, что произошло, стала успокаивать меня и сказала, что нашими предками были прославленные булгары. Именно эта весть крепко вцепилась в мою память, и с годами любопытство по этому вопросу возрастало. Познав обрывочные сведения об истории булгар, я поразился тому, что со времени завоевания Казанского ханства история булгар прервалась и вовсе исчезла, – говорит о своем увлечении Гумар Батршин.

В 2003 году меценат вместе со своими соратниками создал фонд «Булгарское наследие», и продвижение темы древнего булгарского государства стало вестись уже на системной основе.

А до этого шло становление Батршина как предпринимателя. После школы устроился работать на завод. Затем выучился на водителя и ушел служить в ар-

мию. Вернувшись, поставил себе цель – купить автомобиль. Для осуществления мечты пришлось без выходных работать водителем в облпотребсоюзе. Достигнув желаемого, понял, что нужно двигаться дальше. Поступил в плановый институт, окончив который, стал работать заведующим складом заготовительной конторы Нефтегорского района. С началом в стране перемен создал кооператив с незамысловатым названием «Урожай». Занимался сельским хозяйством, продажей и переработкой зерна, подсолнечника. Любовь к Волге и отдыху на воде определили направление его будущего бизнеса. В 1997 году ему предложили приобрести 14 гектаров земли в районе Царевщины. Там он построил дом себе, своему брату, друзьям. Тогда комплексная загородная застройка в Самаре только зарождалась, а сегодня строительная компания Гумара Батршина насчитывает уже с десяток благоустроенных коттеджных поселков на берегу Волги. Это и «Лукоморье», и «Муромский-1», «Муромский-2», «Булгари парк» и другие. Так что его можно смело отнести к первопроходцам девелоперского бизнеса.

Успехи в предпринимательстве дали возможность помогать людям и реализовывать большие общественные проекты. Одним из них стало строительство мечети в поселке Зубчаниновка, официальное открытие которой состоялось в 2010 году. Удалось привлечь к участию в богоугодном деле самарских предпринимателей.



Особенно примечательно то время, когда в Египте правили мамлюки и во главе государства стоял султан Бейбарс. А правителем могущественного государства Золотая Орда, охватывающего территории Евразии, тогда был хан Берке. Эпоха правления Бейбарса – это еще одно яркое доказательство того, какой яркий след в истории оставили тюрки-булгары (предки современных татар), царствующие роды которых назывались «серебряными барсилами». Их история овеяна загадками, связанными с эпохой зарождения всего человечества, сохраненная в сказках, легендах и дастанах древнего татаро-булгарского народа (до появления классической исторической науки, то есть до начала XVIII, века сведения об истории назывались «сказками». Например, «ревизские сказки». Сведения об уникальной истории владычества «мамлюков» берет свое начало с эпохи правления султана Байбарса и длится до начала XIX века, то есть до момента завоевания Египта Наполеоном. Период правления Египтом султана Байбарса примечателен и тем, что он установил прочную связь с империей Золотая Орда.

При заключении взаимовыгодного союза Египта с Золотой Ордой султан Бейбарс отправил делегацию с дорогими подарками, среди которых был Коран, сшитый золотом и подписанный самим халифом Мухтадиром. Его приветственное письмо было написано на тюркском языке, что особенно поразило хана Берке. В итоге сложился прочный союз между этими мощными тюркскими державами, который продлился на века. В ту эпоху Египет и Золотая Орда определяли вектор цивилизационного развития стран и народов, которые населяли территории Азии, Европы и Северной Африки. Эти территории были единой экономической зоной с единой денежной системой. Дирхем был конвертируемой валютой и имел хождение во всем мире. А тюрко-татарский

язык был интернациональным средством общения. Египетский султанат, которым правил Байбарс, тогда называли империей тюрков – Даулат-аль-Аттюрк. Вся документация в империи и переписки велись на тюркско-татарском языке. Это было время, когда огромная империя Чингисхана уже была поделена между его четырьмя сыновьями: Джучи, Хулагу, Хубилаем и Чагатаем. Каждый из них управлял отдельными завоеванными территориями. Хулагу завоевал Иран и другие страны Ближнего Востока и Северной Африки. Завоевав халифат, он казнил и убил халифа. Следующей его целью было завоевание Египта. Поскольку Хулагу был ярым противником мусульман, тогда также велась война и между двумя представителями чингизидов – ханом Золотой Орды Берке, который был мусульманином, а Хулагу – буддистом. После завоевания многих стран, в том числе и Ирана, монгольский завоеватель Хулагу стал задуматься о покорении Египта. Но благодаря коалиции и содружеству правителей Египта и Золотой Орды удалось предотвратить эту угрозу. К тому времени султан Бейбарс одержал уже немало побед, в том числе он освободил Ближневосточные земли от насилия крестоносцев и прослыл непобедимым воином и искусным правителем, заключив союз с ханом Золотой Орды Берке.

Про Золотую Орду мы много наслышаны и сейчас кое-что знаем о событиях, которые происходили тогда. Но о том времени, когда Египтом правили кипчаки-мамлюки, мы вряд ли можем сказать что-то вразумительное. А о загадочной империи тюрко-кипчаков Деште-Кипчак – тем более. Так кем же были кипчаки-мамлюки с тюркскими корнями? Слово «мамлюк» в переводе с арабского означает «раб». И как же рабы оказались на вершине власти Египта? Как они среди арабов-бедуинов создали мощную тюрко-татарскую державу? Я на всю жизнь запомнил фильм «Мамлюки», который посмотрел в 1960-е годы, будучи юношей. Особенно в память врезался эпизод из фильма, когда в смертном бою столкнулись два бойца: один – мусульманин, мамлюк, а другой – француз. Когда мамлюк сразил француза, тот упал с лошади и умер, произнося слово «мама» на их родном языке. Мамлюк по имени Мухамед по необычной форме уха узнал своего друга детства и навзрыд плакал, обнимая его уже мертвое тело. При этом он вспоминал, как когда-то их вместе угнали в рабство и продали на невольничьем рынке. Этот фильм потряс меня до глубины души и запомнился навсегда. Всю жизнь слово «мамлюк» и сюжет фильма для меня оставались непознанной тайной. Второй загадкой было имя Бейбарса – правителя Египта, то есть мусульманской страны. Ведь оно не подходит ни под стандарты арабизма, ни мусульманской терминологии. Оно явно имеет древнетюркские, то есть кипчакские корни и относится к тюрко-булгарским «барсилам». В-третьих, мне совершенно непонятно было то, как тюрок-кипчак, будучи рабом, смог стать правителем Египта и превратил арабскую страну в тюркскую?! Познать суть этих вещей тогда просто было невозможно. Многое стало ясно лишь потом, после детального изучения одного из славных периодов тюрко-кипчакской татарской истории. В XI–XII веках огромная страна Дешт-Кипчак, которую по-другому называли Великой Степью, была растянута от Дальнего Востока, то есть от китайского Хингана и до Черного моря. Хозяевами Великой Степи были кипчаки-тюрки. Великая Степь – это не географическое понятие, а название мощной




тюркско-кипчакской державы и кочевой цивилизации. Кипчаки – прирожденные воины, которых в разное время нанимали Византия, Иран и другие империи для ведения различных войн. Секреты высокого боевого духа, храбрости и бесстрашия тюрков, в частности кипчаков, заключается в их особом душевном устройстве, строгих правилах воспитания и непоколебимой вере в Небесного Тенгре. Это отчетливо проявилось в истории мамлюков. Сейчас кажется уникальным явлением то, что кипчаки, будучи даже в самом бесправном положении, смогли подняться на вершину власти и создать могучую державу, способную спасти мир от двух страшных зол – нашествий крестоносцев и непреодолимой силы монгольских войск Хулагу. Возможно, это кажется чудом. Но история тюрков-татар сплошь пронизана подобными фактами и явлениями. Например, даже тогда, когда этот народ был полностью подавлен, стоило подняться и воспрять духом одному из родов и племен тюрков – приходил в движение

весь тюркский мир. Вот и историю мамлюков, вопреки здравому смыслу, сейчас хочется сравнить с таким явлением: вдруг сплотились бы все пески в пустыне и они превратились в огромную каменную глыбу. Когда то вот такими глыбами были огромные тюркские державы, которые придавали мощные импульсы в ходе цивилизованного развития истории всего человечества. История мамлюков начинается так: поскольку кипчаки прослыли непревзойденными воинами, в эпоху нашествия крестоносцев правитель Египта султан ас Салих Наим-ад-Дин стал формировать войска из числа рабов – кипчаков. Семи-восьмилетних мальчиков они покупали на невольничьих рынках и воспитывали их настоящими воинами. При этом они давали им достойное образование. Со временем мамлюки становились военной элитой. Из их среды вышли даже знаменитые полководцы. В их числе был и Бейбарс – будущий султан Египта. Бейбарс был выходцем из кипчакского рода эль Бария. Еще ребенком он попал в рабство монгольским завоеаателям. На невольничьем рынке его купили египтяне за 800 дирхемов и воспитывали в школе воинов-мамлюков. Мамлюки – наемные воины, в основном состояли из кипчаков. Они считались самыми храбрыми и искусными воинами в мире. Со временем Бейбарс стал военачальником. Затем, свергнув Туран шаха. стал султаном Египта. Бейбарс правил Египтом на протяжении 17 лет. Ну а государство мамлюков, созданное им, просуществовало начиная с XII века и до начала XIX века, вплоть до завоевания Египта Наполеоном. Эпоха правления Бейбарса стала яркой страницей не только в истории Египта. Когда происходило невиданное до того времени столкновение двух цивилизаций – мусульманского и христианского миров, он укрепил границы Египта, создал боеспособную армию, флот, восстановил крепостные сооружения, В систему вооружения впервые ввел артиллерию. Будучи искусным политиком, он заключил мирный договор с византийским императором Михаилом Палеологом, а затем – с Золотой Ордой, взяв в жены дочь хана Берке. Он подчинил Ливию, Судан. Под его контролем тогда были торговые пути, проложенные из Европы, Малой Азии, Ближнего Востока к Индийскому океану. А также торговые пути, идущие из Китая, Монголии, Средней Азии и Индии – в страны Европы. Благодаря доходам от торговых путей он прослыл правителем самой богатой страны в мусульманском мире того времени. Он ввел и развивал банковские системы и финансовые институты и отменил джизью – налог на немусульманское население. Байбарса тогда считали защитником ислама и его мечом. Он освободил Палестину, Сирию, Иорданию от захвата крестоносцев, а затем и другие мусульманские государства. Он восстановил халифат, после того как многие мусульманские страны были завоеваны крестоносцами и монголами – войсками хана Хулагу, который казнил халифа Мухтадира. Тогда уже стали говорить о закате всей мусульманской цивилизации. Однако при султане Бейбарсе халифат как бы обрел второе дыхание. Возобновилось интенсивное строительство в Каире, Александрии. По всему мусульманскому миру развернулось строительство ирригационных сооружений. Было построено свыше 150 мечетей, медресе, мавзолеев. За это нарекли его именем Рукн-ад-Дин (Опора исламской веры). Современники сравнивали его Александром Македонским. Султан Бейбарс по праву был признан тогда самым великим правителем в мусульманском мире. В огромном крае он повсюду запретил спиртные напитки и уничтожил все запасы вина, заменив их кумысом. С корнем вырвал мятежи. Запретил проституцию и способствовал развитию многоженства. При Бейбарсе воины, инвалиды получали пожизненные пенсии. Под свое покровительство он взял ученых, артистов, музыкантов и представителей искусства.



Монета эпохи Байбарса

Чтобы усилить армию, он привлек кочевых туркмен. Помногу покупал кипчакских рабов и воспитывал их настоящими воинами. Византийский ученый Вильгельм Трипольский назвал его «эмиром эмиров» и сравнивал с Юлием Цезарем. Он говорил, что Бейбарс отличался храбростью, могуществом и красотой тела, изяществом черт характера и благородством. Эпоха правления мамлюков, особенно эпоха султана Байбарса, была ознаменована резким подъемом уровня культуры, образования и экономики. Широко развернулось строительство дворцов, мечетей, караван сараев, научных центров и школ. Широкое развитие получила медицина, особенно офтальмология. Уже тогда в Египте успешно лечили катаракту. Таким образом, Египет дал новый толчок для развития исламской цивилизации во всем мире. Тогда мамлюки стали защитниками и мечом ислама. Примечательно и то, что султанов тогда стали избирать. И это означало, что страной стали управлять самые достойные люди. Например, со временем правитель ибн Хальду стал первым социологом и политологом в нынешнем понятии. Он стремился к всенародному счастью, считая, что только тогда может быть мир и спокойствие в стране, когда все люди, живущие там, будут довольны своей жизнью.

# ДАСТАННАР - ХАЛЫКНЫҢ РУХИ МИРАСЫ САГЫНДА ТОРУЧЫ БОРЫНГЫ ӘСӘРЛӘР

*Суларында - балык,*
*Урманында – киек.*
*Җырын саклап калган*
*Халык җаны бөек.*
*Г. Афзал.*

***Татарстан Җөмһүрияте 2023 елны «Дастаннар елы» дип игълан итте. «Дастан» сүзен ишеткән булсак та, күпләребез аның татар халкы язмышында никадәр зур урын алганлыгын белмибез. Чөнки чынбарлык тарихыбызны һәм эпос-дастаннарны пропагандалау тыелгач, алар озак еллар дәвамында тоткынлыкта булдылар.***

***Фәрид Шириязданов***

Соңгы елларда галимнәр тарафыннан дастаннарны өйрәнү киң җәелсә дә, халык арасында аларны пропагандалау әлегә тиешле дәрәҗәдә түгел.

Ә менә Урта Азиядә яшәүче төрки телле халыкларда дастаннар әлегәчә кулланышта булдылар. Бу уңайдан үземнең Үзбәкстанда эшләгән елларда Памир тауларының өч мең метр биеклектәге кар таулары итәгендәге җәйләүләрдә маллар көтеп яшәве, кыргызлар белән аралашкан вакытлар искә төшә.

Берзаман кыргыз юртасы алдына атының сыртына зур-зур капчыклар аскан бер кыпчак килеп туктады. Аның бөтен кыргыз көтүлекләрен әйләнеп чыгып, шуларга тормыш кирәк-яраклары сатып йөрүче алып-сатар – «Автолавка» хуҗасы икәнлеге беленде.

Хуҗалар үзен зурлап кабул иткәч, ул табын янында, думбрасын алып, дастан «әйтә» башлады. Шунда бу кешенең төрки халыкларда дан казанган чичән-акын икәне дә беленде.

Бу – мәзәк тә, мавыктыргыч та тоелган күренеш әллә кайсы борынгы заманнарга кертеп җибәргәндәй булды. Аның ашкынулы «җыруында» ургып чапкан атларның тояк тавышы, ирекле дала җиленең сызгырып үтүе, һавада

Акын чачан



очкан бөркетләр, ат пошкыруы, кылычлар чыңлавы, ниндидер каһарман егетнең батырлыклары да күз алдыннан узды кебек. Бу чәчәннең дәртле «җыруында» ялкынлы мәхәббәт, саф сөю хисләре дә яңгырады.

1970 еллар башында булган бу вакыйгада мин беренче тапкыр «дастан», «чичән», «акын», «җыру» кебек серле сүзләр ишеттем. Шунда күңелемә дастаннарга карата кызыксыну «корты» кереп калды, һәм ул, гел кыймылдап, бу хакта күбрәк белү теләген көчәйтә торды. Тик бу еллар, халкыбызның милли үзаңын тәрбияләүче дастаннар онытылып, искелек калдыгына әверелгән һәм тарихыбызны ялганнар баскан заман иде.

Ни кызганыч, хәзер киң мөмкинлекләр ачылса да, халыкта үз милләтенең үткәндәге язмышы хакында нидер белү теләге инде шактый сүрелгән, сүнгән хәлдә бит.

Дөрес, галимнәр арасында бу юлда җанлы эшчәнлек бара. Тик шуларны пропагандалап, халык тарафына җиткерү эшләре генә куандыра алмый шул.

Хәзер дастаннар турында сөйләгәндә: «Нәрсәгә кирәк инде бу үткән-беткәннәр, искелек калдыклары өстендә казынулар?!» – диючеләр дә табылыр. Чынлап та, нәрсәгә кирәк соң болар хәзерге заманда? Нәрсәсе белән алар мондый игътибарга лаек булып торалар?

Милләт буларак, халыкны күп нәрсә берләштерә: аның теле, гореф-гадәтләре, дине, уртак тарихы, сәнгате һәм әдәбияты. Менә шул эпос-дастаннарда халкыбызның милли байлыгы гасырлар буена камилләшеп һәм сакланып килгән дә инде.

Дастаннар – татар халкының яшәү рәвешен тулысынча үз эченә сыйдырган рухи хәзинәләр. Алар, халыкның конституциясен, яшәеш программасын тәшкил итеп, аның милли үзаңын тәрбияләп, дөньяга карашын киңәйтеп, рухын үстергәннәр. Монда намус, әхлак һәм башка кыйммәтле кешелек сыйфатлары тәрбияләүче кануннар да тупланган.



Идегәй

Дастаннар – борынгы бабаларыбызның тормышка фәлсәфи, дини карашы нигезендә барлыкка килгән әдәби эпос жанры. Эпос – грек теленнән алынган, «сәнгатьле сөйләм», «хикәя» мәгънәсендә.

Эпос-дастаннар – әдәбиятның иң борынгы жанры. Аларда экиятләр, мифлар, тарихи вакыйгалар, мәхәббәт романтикасы, каһарманнар батырлыгы чагылдырылган. Анда кыйммәтле тарихи вакыйгалар, сугышлар, табигатьтәге серле күренешләр турында да сөйләнә. Ул шигъри, чәчмә әсәр яисә катнаш рәвештә була.

Бик борынгы халык буларак, татарлар – дөньяда дастанлы булып танылган милләт. Бу, татарларның зур сынаулар аша үтеп тә, бүгенгәчә исән калган, бөек халык булуын тагын бер кат исбатлый. Милләтебез бөеклеген дәлилли торган күп нәрсә хәзер инде югалган, юк ителгән булса да, дастаннар – халкыбызның үлемсез иҗат байлыгы. Мәсәлән, «Идегәй», «Кисекбаш кыйссасы», «Чура батыр хикәяте», «Таһир белән Зөһрә», «Ләйлә белән Мәҗнүн» һәм башкалар.

Дастаннарда чал тарих һәм милләтебезнең асылын ачыклаучы дәлилләр – артефактлар да саклана. Аларда халыкның тормышка карашы, бар булдыгы, рухи бөеклеге сурәтләнә. Зур урынны батырлык һәм мәхәббәт темалары алып тора. Мәсәлән, каһарман ир-егетләрнең, батырларның үз илен, халкын яклау юлында күрсәткән батырлыклары.

Дастаннарны телдән әйтү күчмә тормыш шартларында бик борынгыдан киң таралган. Алар, меңнәрчә еллар буена сакланып, тагын да тулыланып, баеп килгәннәр. Дастан әйтүчеләрне зурлап, шагыйрь, чәчән, акын, дип атаганнар.

Чичән һәрвакытта туйларда, төрле мәҗлесләрдә халыкны үзенең оста сөйләве белән җәлеп итүче кадерле кунак булган. Ул музыка коралларында да уйный белгән данлыклы шәхес саналган.

Чичән матур җырлый, сөйли һәм көйли белүче генә түгел, ул яттан, тоткарлыксыз һәм көчле хисләр уятырлык итеп сөйләүче шагыйрь-импровизатор. Ул, сүз кодрәтен музыка тембры белән көчәйтеп, аны халыкның күңел түренә җиткерә алган. Татарларда дастаннарны музыка коралында уйнап, телдән әйтү гадәте күптән сүрелгән булса да, эпос-дастаннар татарның язма-китап культурасын үстерүгә зур өлеш керткәннәр. Алар халкыбызның әдәби-мәдәни мирасын үстерүдә һәм саклауда да зур роль уйнаганнар. Аларның иң камил булган өлеше, кулъязмаларга язсә китапка әверелеп, халык арасында киң таралган. Шулай итеп, дастаннар көйләү-сөйләү формасында да яшәүдән туктаган. Дастан әйтүчене (сказитель) сөйләүче (чтец) алыштырган. Татар халкы үз тарихы дәвамында эпос-дастаннарны күп иҗат иткән. Аларны кулдан язып һәм күчереп, үзара тараткannар. Авыр чорларда дастаннар халыкның милли үзаңын, гореф-гадәтләрен, телен, милли мәдәниятен, мәгърифәтен үстерү һәм саклау чарасы булып та хезмәт иткәннәр. Алар, гарәп язулы кулъязмалар булып, басма китапларга әверелеп, хәзерге көнгәчә сакланып килгәннәр.

Язма дастаннарда халыкның тарихы, гасырлар дәвамында тупланган акылы, тормыш тәҗрибәсе, тел байлыгы, сүз сәнгате дә лаеклы урын алган.

Эпос-дастаннар хәзер дә, милләтебезнең бай мирасын яшь буынга тапшыру өчен, кыйммәтле рухи чыганаклар булып хезмәт итәләр. Бүгенге көндә дастан батырларының исемнәре, данлыклы вакыйгалары опера-балет, театр сәхнәләрендә, җырларда һәм әдәбият мәйданында яшәвен дәвам итә.



Озак вакыт эзәрлекләүләр аша үтеп тә, исән калган һәм тормышыбызга яңадан әйләнеп кайткан бер генә әсәрне, мәсәлән, «Идегәй» дастанын алсак та – анда катлаулы хакыйкәть ачыла.

Бу тарихи дастан Алтын Урда дәүләтенең таркалу елларындагы серләрне ачыклый. Шул заманда зур роль уйнаган шәхесләрне ул халык каһарманы дәрәҗәсенә күтәрә.

Иң әһәмиятлесе – бу дастанга халкыбызның күз яше, тире, каны түгелгән язмышы сеңгән. Ул туган җир төшенчәсен, аның асылын аңларга өйрәтә.

Бу әсәр мәкер, хыянәт, ялганның әшәкелеген, дуслык, мәхәббәт кебек изге хисләрнең сафлыгын һәм биргән вәгъдәгә тугрылыклы булуның асылын аңлата.

Явызлык үзе белән явызлыкны ияртә. Яманлыкка каршы кылынган яманлык аны үстерә. Бу әсәр менә шуны раслый.

Дастаннар, тормышка карашны киңәйтеп, зуррак масштабта фикерләргә, кешене яшәү мәгънәсенә төшенергә өйрәтәләр. Аларны укыгач: «Ил, Ватан, Ата-Ана, Милләт төшенчәләренең үзкыйммәтен тирәнтен аңлаган кеше үз гомерендә аларга хыянәт итмәячәк!»- дигән фикер туа.

Татар дастаннары үткән юл бик озын һәм катлаулы. Гомумән, дастаннарыбыз, милләтнең үзе кебек, үлемсез. Нинди генә шартларга юлыкса да, татар эпосы үлмәгән, югалмаган. Зур сынаулар үтсә дә, исән калып, камилләшә барган.

Дөньяда эпос-дастаны булмаган күп халыклар бар. Шуны исәпкә алсак, татарларның нык тамырлы бөек халык булуы тагын да ачыграк күренә.

Евразия далаларында таралып яшәүче халкыбызда дастаннар гасырлар буена, рухи азык, күңел юату чарасы гына булмыйча, тарихның хәлиткеч этапларын да чагылдырып, әлегәчә саклап калганнар. Моның өстенә, рухи байлыгыбызның ышанычлы сакчысы буларак, алар, тәрбияви яктан да көчле идеология коралы булып, халыкка хезмәт иткәннәр.

Йомгаклап әйткәндә, дастаннар халыкның үткәнен тирәнрәк белергә, аның рухи матурлыгын тоярга ярдәм итәләр.



## Как беженцы от погромов создали государство Израиль

*Мы продолжаем рассказ об интересной, но не очень любимой в нашей стране теме – зарождении мирового сионистского движения, создании Израиля и той роли, которую сыграли в этом выходцы из России*

*Дмитрий ГРЕКОВ*

# Россия – родина сионизма

*(Продолжение. Начало – в предыдущих номерах)*

### Соображение на троих

Первая мировая война наконец-то сдвинула «еврейский вопрос» из сферы интересов самих евреев в «плоскость мировой политики». 16 мая 1916 года был подписан документ, получивший название «Соглашение Сайкса – Пико» (по фамилиям британского дипломата Таттона Бенвенуто Марка Сайкса и французского дипломата Франсуа Жоржа-Пико). Началось всё еще 10 апреля 1915 года, когда Россия, Франция и Великобритания подписали секретное соглашение о передаче после победы Черноморских проливов Российской империи.

После чего возник законный вопрос о разграничении сфер влияния будущих победителей на территории упраздняемой ими Османской империи. Была сформирована рабочая группа как раз из Сайкса и Пико, которые обсудили вопрос в Лондоне, а в марте 1916 года приплыли в Санкт-Петербург, где получили одобрение царя.

Суть соглашения была в разделе «шкуры неубитого османа». Великобритания получала территорию, соответствующую современным Иордании и Ираку, а также районы вокруг городов Хайфы и Акко. Франция забирала юго-восточную часть Турции, северный Ирак, Сирию и Ливан. Россия должна была получить Босфор и Дарданеллы, Константинополь, Западную Армению и часть Северного Курдистана (район Хаккяри).

Палестину решили не делить (очень уж тут всё сложно…) и оставить под «международным контролем». Каждая из держав имела право определить государственные границы в своей зоне влияния – основывать новые страны, присоединять к себе или оставить туркам «на своих условиях».

### От ослов – к фузилерам

Соглашение держалось в тайне, ибо существовали стороны, которые были бы сильно недовольны его содержанием. Например, Италия – как-то всё-таки прознав о соглашении, она начала требовать, чтобы и ее территориальные интересы также



были учтены. Премьер-министр Великобритании Ллойд Джордж, нуждаясь в помощи Италии на Ближнем Востоке, предложил уступить ей Смирну и часть других османских владений. В апреле 1917 года на встрече в Сен-Жан-де-Морьен англичане и французы согласились на передачу итальянцам Смирны.

Итальянцы, однако, продолжали претендовать на дополнительные территории, населенные греками и турками. Переговоры затянулись до августа 1917 года. Наконец была достигнута договоренность о зоне влияния в Юго-Западной, а также части Западной и Центральной Анатолии.

К этому времени в качестве отдельного политического игрока на «шахматной доске» выступили и евреи. Еще весной 1915 года в рядах британской армии появилось необычное подразделение – Отряд погонщиков ослов.

Командовал ими подполковник Джон Хенри Паттерсон – ирландец, сын протестанта и католички, участник войны с бурами и известный охотник на львов (по его книге позднее снимут известный кинофильм «Призрак и Тьма»). Он дружил с «агентами мирового сионизма», особенно с уже знакомыми нам Зеэвом Жаботинским и Йосефом Трумпельдором. Все они оказались в апреле 1915 года во главе 500 «сынов Израилевых», которые участвовали в боях на полуострове Галлиполи под командой Паттерсона (после ранения его сменил Трумпельдор). Формально отряд действительно доставлял из мест разгрузки на фронт припасы с помощью ослов, фактически часто находился в гуще боевых действий.

В мае 1916 года, после эвакуации английских войск в Египет, отряд был расформирован, но Жаботинский не сдался и попробовал уговорить на «Еврейский легион» французов – однако тщетно. Затем Паттерсон познакомил своего друга с Лео Эмери, помощником премьер-министра Ллойд Джорджа, и идея внезапно обрела второе дыхание. А третье пришло, когда в июне погиб фельдмаршал Херберт Китченер, главный «антиеврей» британской армии — и уже в ноябре 1917 года началось формирование 38-го батальона фузилеров из английских и проживавших в Великобритании российских евреев...

## Состоятельные евреи и нищие бедуины

9 ноября 1917 года была опубликована декларация главы британского МИДа Артура Бальфура, которая провозгласила «создание в Палестине очага еврейского народа» после войны. Вовсе не потому, что английская армия нуждалась в батальоне евреев – нуждался Ллойд Джордж, и не в отряде экзальтированной молодежи, а в банкирах США и Сити, спонсорах сионистского движения, которым нужен был «свой профит» для вложения средств в мировую войну (и влияния на президента США Вудро Вильсона, чтобы тоже уже быстрее поворачивался) — им и стало фактическое провозглашение создания Палестинской автономии.



Артур Бальфур

К тому же английское правительство жалело о том, что в соглашении Сайкса — Пико позволило французам получить Палестину в «совместное пользование» (русских после 7 ноября 1917 года можно было открыто списать со счетов), и рассчитывало после войны с помощью «ручных евреев» добиться «перевеса на местах» или же вообще (как оно и случилось в действительности) отказа французов от «святых мест». Но воодушевленный мировой сионизм в эти материи не вникал и тут же проспонсировал создание еще трех батальонов «королевских фузилеров» – 39-го (из евреев США и Канады), 40-го и 42-го, которые были сформированы уже в 1918 году и вместе с 38-м составили-таки «Еврейский легион».

Существовали, правда, люди, которые сочли появление декларации Бальфура «ножом в спину», «коварным вероломством гяуров» и «бесчестным предательством» — естественно, арабы, и конкретно Хашимиты, правители Мекки, уже год как воюющие за обещания англичан отдать им весь Ближний Восток в «безвременное пользование».

Несмотря на то что официальных соглашений никаких заключено не было, агент Томас Эдвард Лоуренс (будущий Аравийский) и прочие «представители власти» совсем не то обещали шерифу Хусейну и его сыновьям, когда звали на борьбу с османами. Арабы всерьез считали Палестину своим «родным домом», Иерусалим – священным городом, а евреев – понаехавшими, и именно в 1916 году родился арабо-израильский конфликт, вот уже более ста лет «жгущий напалмом» жизнь всего Ближнего Востока, а также его окрестностей...

# ТУГАН ҖИР ИЗГЕ, ТУГАН ҖИР ГАЗИЗ



***Шенталы районындагы Шенталы авылында Ислам динен тотып яшәүче мөселман кардәшләребез бик күп. Хәзер бәян ителәчәк язмам Наил Абдрахман улы белән Суфия Рәшит кызы Дәүләтказыйннар турында булыр. Алар икесе дә Үзбәкстанның Ташкент шәһәрендә дөньяга килгәннәр. Наил абыйның тамырлары Мордовиядәге татар авылыннан, ә Суфия ханымның төп чыгышы Денистән. Аларның әби-бабайлары тирән язмыш кичергән кеше булараk билгеле.***

***Нурсинә Хәкимова***

Суфия апаның бабасы Мөхәммәтсафа белән әбисе Зәйнәпнең яшьлеге бик авыр чорга туры килгән. Авылларда коллективизация чоры башлангач, авылда ике: хәллерәк һәм ярлылар төркеме барлыкка килә. Шул арада ярлылар комитеты да төзелә. Хәллерәк кешеләрнең җирләре, маллары тартып алынып, үзләрен Себергә – каторгага озатулар башлана.

Мөхәммәтсафа белән Зәйнәпнең һич кенә дә газиз туган авылларыннан китәселәре килми. Алар, йорт-җирләрен калдырып, көзге, караңгы бер төндә, качып, авылдан чыгып китәргә мәҗбүр булалар. Иң кадерле булган уллары Рәшит белән берничә айлык кызлары Әсманы алып, Шенталыга килеп, урманда землянка казып яшәүче бер качак кеше янына килеп сыеналар. Хокук саклаучы органнар аларны эзлиләр. Яшь гаиләнең ач килеш, көзге суыкта, яңгыр астында өшеп, урман-кырларда качып йөрүләре аяныч хәлгә китерә. Кинәт салкын тидереп, Мөхәммәтсафа үлеп китә. Зәйнәп, елый-елый, сабыйларын кочаклап, авылга әйләнеп кайтырга мәҗбүр була. Ул авылда фатиргә кереп, шунда яши башлый. Берничә ел азаплана торгач, Бөек Ватан сугышы башлана. Ирлектәй ирләрне фронтка алып бетерәләр. Зәйнәп яшүсмер улы Рәшит белән колхоздагы бөтен авыр эшләрдә катнашалар, аларны урман кисәргә, окоп казырга җибәрәләр. Ә 1943 елда унҗиде яшьлек Рәшитне сугышка алалар. Бик каты барган бәрелешләрнең берсендә яшь егет каты яралана. Аны госпитальгә озаталар. Озак кына дәваланып чыккач, егеткә туган авылына кайтып, сөекле әнкәсе белән кечкенә сеңелесен күреп килергә рөхсәт бирелә, һәм ул авылга кайтып төшә. Якыннарының кеше өстендә, фатирда яшәүләрен күргәч, ул, искерәк булса да, өй һәм сыер сатып ала. Үзе бик озак тоткарланып калмый, яңадан фронтка китеп бара. Билгеле, әнисе Зәйнәп белән сеңелесе Әсма аны елап озатып калалар.

Гомерләр үтә тора. Озакламый фашист мәлгуньнәрне үз илләренә кадәр куып барып, аларны дөмектергәч, сугыш тәмамлана. Авылга батыр сугышчылар әйләнеп кайта башлый. Ә бичара Зәйнәп белән Әсма никадәр өзелеп көтсәләр дә, Рәшит кайтмый. Чөнки тәпле, акыллы, сүзендә тора торган, намуслы егетне хуҗалары бик тиз күреп алган булалар. Алар аны башка солдатлар белән бергә өенә кайтарып җибәрмиләр. КГБда эшкә урнаштыралар. Озак та үтми, спецзадание биреп, Иранга командировкага озаталар. Менә шулай итеп, бер ел гомер үтеп китә.

Зәйнәп ханым, борчылып: “Йа, Раббым! Баламнан бер хәбәр дә юк. Аның үлекме, тереме икәнлеге дә билгесез”, дип хәсрәтләнә. Өстәвенә, өйнең матчасы череп, ул өзелеп төшә. Бәла игезәк була, диләр бит. Сыерлары да үлә. Яшәргә - өй, сөт-катык ашарга сыер юк. Шулхәтле бөлгенлеккә төшкән Зәйнәп, ничек яшәргә, дигән сорауларына җавап эзләп, күршеләренә барып керә. Күршесе, Ташкенттагы туганнарыннан хат алып, шуны кычкырып укый торган чакка туры килә ул. Ә анда: “Кадерле туганнарым, ятмагыз анда, Россия суыгында өшеп, өстәвенә, ачлы–туклы. Бирედә һава торышы бик җылы, рәхәт. Ризык та күп. Монда тормыш итәргә җиңелрәк. Бирегә күчеп килегез!” – диелгән була. Барын да ишетеп торган хатын бик озак тоткарланып калмый, күршеләреннән тизрәк чыгып китә. Бераз уйланып йөргәч: «Торырга - өй, ашарга ризык булмагач, туган җир турында уйлап торырга яра-

мый. Улым Рәшиттән бер хәбәр дә юк, кызым Әсма өчен яшәргә, аның тормышын саклап калу турында уйларга кирәк», – дигән фикергә килә. Шулай итеп, авылда озак тоткарланып тормый, кызы Әсманы ала да, поездга утырып, Ташкент шәһәренә юл тота. Биредә сәяси репрессиядән качып, үзләренә бер мәхәллә булып, Ислам диненә буйсынып яшәгән авылдашлары, аларны ачык чырай белән каршы алып, хәләл икмәкләре белән бүлешәләр.

Зәйнәп эшкә урнаша, гел куркуда торган Әсма тынычланып кала. Шулай, тормыш әкрен генә үз җаена төшә.

Ә Рәшиткә килгәндә, ул, авылга кайтып төшкәч, аптырап китә. Аны биредә каршы алырга беркеме дә булмый. Күршеләре сөйләвен тыңлап торгач, югалып калмый, поездга утыра да якыннары артыннан ерак сәфәргә чыгып китә.

Зәйнәп ханым белән Әсманың шатлыгы чиксез зур була. Пәһлевандай Рәшит гомере буе аларның яклаучысы, ярдәмчесе булып тора.

Тормыш алга китә. Тора-бара Рәшит Мөхәммәтсафа улы төп тамырлары Денис авылыннан чыккан, Минсара исемле унсигез яшьлек чибәр кызга өйләнә. Мәхәббәт нигезендә корылган гаиләдә бер-бер артлы сабыйлары: Рафаэль, Суфия, Хәлил дөньяга киләләр. Рәшит, Ташкент дәүләт университетында укып, юрист, ә Минсара медицина хезмәткәре һөнәрләрен үзләштерәләр.

Тормышлары бик әйбәт булса да, Мостафиннар гаиләсе, гомер буе җирсеп, туган илләрен сагынып яши. Аларның бу турыда искә алмый калган вакытлары бик аз булгандыр. Телләрендә һәрчак бер сүз була: туган илгә кайтырга кирәк!

Мостафиннар гаиләсе безнең туганнарыбыз булгач, шунысы билгеле миңа. Оныклары укудан җәйге каникулга туктагач, Зәйнәп әби алар белән еш кына кунакка кайтып килә, ә Рәшит абый белән Минсара апа чираттагы отпускаларында ял итеп китәләр иде.

Кызганычка, Зәйнәп әби белән Әсма апа, якты дөнья белән хушлашып, мәңгелеккә киткәч, аларның җәсәде чит җирләрдә җирләнеп кала. 1994 елда Рәшит абый белән Минсара апа, лаеклы ялга чыккач, туган якларга күчеп кайттылар. Ахыргы сулышларына кадәр балалары һәм оныклары тәрбиясендә, аларның яратуын тоеп, гамәл кылып яшәделәр. Байтак еллар яшәгәч, бер-бер артлы дөнья куйдылар һәм Денис авылы зиратында җирләнделәр.

Рафаэль абый, Суфия апа һәм Хәлил бүгенге көндә үзләре әби-бабайлар инде. Алар бабаларын, әбиләрен, апалары Әсманы, әти-әниләрен тирән хөрмәт белән искә алалар. Ошбу дус гаилә әгъзаларының сүзләренә караганда, Зәйнәп әби:

– Туган җир изге һәм газиз! Бәхетле кеше генә үз илендә яши! Беркайчан да шуны онытмагыз, туган илебезгә кайтыгыз! – дип, балаларына һәм оныкларына васыять әйтеп калдырган булган.

Суфия апа:

– Әтиебез: «Йа, Раббым! Туган илебезгә кайтып үлсәк кенә ярар иде», - дип тели иде. Аллаһыга шөкер, теләге кабул булды. Шуның өчен, лаеклы ялга чыгуга, бөтенебезне ияртеп кайттылар да инде. Хәзер туган туфракта яталар. Без Ташкентта туып-үссәк тә, күңелебез һәрчак бирегә тартылды. “Җан тартмаса, кан тарта”, дип әйтүләре бик дөрес икән, – дип сөйләде.

Ә мин өстәп шуны әйтер идем.

Рәшит абый: «Кызым, читтә яшәгән вакытта һәрчак күз алдыма бик матур бина килеп баса иде. Ә анда үзе уйнаган пианинога кушылып, матур, йөрәккә үтеп керерлек тавышы белән минем кызым Суфия җырлый дип хыяллана идем», - дип әйткән иде. Дөрестән дә, Рәшит абыйның хыялы тормышка ашкан. Чөнки Суфия апа, гомере буе мәктәптә балаларга музыка дәресеннән белем биреп, шуннан лаеклы ялга да китте. Ә аның тормыш иптәше Наил абый, лаеклы ялда булса да, Шенталы районындагы газ хуҗалыгында инженер булып хезмәт итә.

Әйтергә кирәк, зур югалтулар аша әби-бабасыннан мирас булып калган Ислам динебезне тотып, намаз укып яшәгән Наил абый белән Суфия апабызның тудырып үстергән балалары да дини.

Әминә, Шенталы мәктәбен бетереп, Самар дәүләт педуниверситетында филология факультетын тәмамлагач, Самар шәһәренең данлыклы”Яктылык” мәктәбендә укытучы булып эшли.

Бераз гомердән соң Әминә, мәчеткә килеп, Самар өлкәсе мөселманнарының Региональ диния нәзарәте рәисе, мөфти Талип хәзрәт Яруллинның сеңелесе - хөрмәтле мөгаллимә Сания ханым Мингачевадан дини белем үзләштерә. Сания апа белән яшь кыз арасында дуслык җепләре, бер-берен ихтирам итү хисләре барлыкка килә. Ә көннәрдән беркөнне Әминә һәм Талип хәзрәтнең улы - Ислам очрашалар. Алар бер-берсен беренче күрүдән үк бик ошаталар. Тора-бара гаилә корып җибәрәләр. Аллаһыга шөкер, бүгенге көндә ошбу матур гаиләдә сөекле кызлары: Кәримә, Хәмидә, Шакирә үсеп киләләр. Хәзерге көндә Ислам хәзрәт Самар мәчетләренең берсендә имамлык итә, ә Әминә дини белем бирә.

Наил абый белән Суфия апаның Самар дәүләт политехник университетын тәмамлаган уллары Булат, Сәлимә исемле, югары белемле кыз белән кавышып, гаилә учагын тергезеп җибәрә. Алар Самар шәһәрендәге “Нур” мәдрәсәсен тәмамлаганнар. Хәзерге вакытта ике кызлары: Сәидә белән Мәрьям, тормыш чәчәге булып, матур гына үсеп киләләр.

Балалар һәм оныклар - әти-әнинең, әби-бабайның юанычы, шатлыгы, диләр бит. Дәүләтказыйннар гаиләсе – Наил абый белән Суфия апа, кулга-кул тотынышып, кызлары Әминә белән Ислам хәзрәттән, уллары Булат белән киленнәре Сәлимәдән һәм оныкларыннан канәгать булып, тормыш юлыннан бергә атлыйлар.

Язмам ахырында шушы күркәм гаиләгә:

«Бәхетегез дәвамлы булсын!» – дип телисе килә.

# Җиренә җиткереп эшләгәндә генә, җир дә уңышын мул бирә

***Советлар Союзы чорында эш кешесенә хөрмәт күрсәтү дәүләт идеологиясе нигезендә ятса, хезмәткә дан җырлау яшәү гимнына әверелгән иде. Шуңа да һөнәр осталары, уңган кешеләр һәрвакытта дан һәм хөрмәт казанып яшәделәр.***

*Фәрид Шириязданов*



Кәрам Ганниев

Һәр җитди хезмәт, көч куеп, чын күңел биреп эшләүне һәм зур җаваплылыкны таләп итә. Ә авыл хуҗалыгын алып бару – бигрәк тә. Монда ял көннәре, бәйрәмнәр дә онытыла, ару-талулар да исәпкә алынмый. Кыр эшләрен – «Битва за урожай», уңыш җыю вакытын – «Страдная пора» һәм игенчеләрне «Страдники» дип юкка гына атамаганнар бит инде. Чөнки игенче һәрвакытта, көнен төнгә ялгап, вакытының һәр минутын кадерләп, үз-үзен аямыйча эшли. Шуңа да җир эшенә жаны-тәне белән бирелгән кешене хөрмәтләп: «Ул буразнада туган!» – диләр.

Татарлардагы Җир-Анага карата хөрмәт «кан заманнардан» килгән. Борынгы бабаларыбыз төгәл белгән: Җирне Аллаһы Тәгалә барлык җан ияләренә дә туклану һәм шунда яшәү өчен яралткан.

Җир йөзендә нинди генә кодрәтле түрәләр, патшалар һәм ханнар хакимлек итмәсен, җирләр беркайчан да аларның шәхси милке булып саналмаган. Аллаһы Тәгалә аны бары шулар кулындагы дәүләткә, алар идарә иткән халыкларга яшәү дәверендә куллану өчен генә бирелгән икәнлеген белеп яшәгәннәр.

Ни кызганыч, тик хәзер җиргә караш тамырдан үзгәрде. Ул шәхси милеккә, товарга әйләнгәч, аны тереклек чыганагы буларак зурлау, хөрмәтләүләр дә тукталды.

Ул әллә кайдагы бай җир биләүчеләр кулына күчкәч, шунда көн күргән авылларның киләчәген кайгыртулар да бетте. Күбесе таркалып, шул урыннарда шаулап чүп үсүе дә инде гадәти хәлгә әверелде.

Авыллар хәлсезләнеп, элгәре алар кулындагы җирләрнең җилеген чит-ятлар суырганны күргәндә, ирексездән Крыловның «Свинья под дубом» мәсәле искә төшә. Авылларның тамыры корый торгач, дөньялар кайда барып терәлер икән соң?!

Менә шундый борчулы уйлар биләгәндә, хәзерге вакытта үз авылының җирләрен үзләре эшкәртеп көн күрүче хезмәт батырлары булуы безне тулы өметсезлектән коткара. Аларны ирексездән аждаһаларга каршы сугышка чыккан әкияти батырлар белән чагыштырасы килә.

Җирдә эшләү өчен, никадәр тәвәккәллек, түземлек кирәклеге һәм, кетмәгәндә бәла килеп, куйган хезмәтнең юкка чыгу мөмкинлеге күпләргә билгеле. Бу – табигый хәл. Ә моның өстенә шундый хезмәт ияләренә хөсетләнеп яисә туган авылның җирләрен читләргә сатып, өч тиенлек табыш алырга тырышып, этлекләр эшләүче вак җанлы кешеләрнең дә булуы җанны әрнетә. Бу очракта, үзләренә аяк чалучы корткычларга бирешмичә, җир эшен уңышлы алып барган эшмәкәрләргә сокланмыйча һич тә мөмкин түгел.

Иске Ярмәк авылында яшәүче Ганниевлар нәселе – шундыйлардан.

Түбәндә эшмәкәр Габдулхак улы Кәрам Ганниев һәм аның уллары белән булган әңгәмәбез.

***– Авыл хуҗалыгын алып бару иң борынгы хезмәт булса да, бу өлкәдә яңа эш алымнары, фәнни ачышлар туа тора. Ә Сез, махсус югары белемегез булмаса да, ничек болай җирнең пульсын, сулышын тоеп, аның бар булган ихтыяҗларын белеп эшләргә өйрәндегез?***

– Бу очракта мин «Крестьян академигы" Мальцевны телгә аласым килә. Язын җирнең чәчүгә җитлеккәнен ул, яланаяк йөреп, утырып торып, «арт саны» белән дә тоя белгән. Биле үзен сизгертмәсә, димәк, орлык чәчәргә вакыт җиткән.

Җир белән үзара тыгыз бәйләнеш һәм шундый эчке тоемлау булып, бар куәткә тырышып эшләгәндә генә, җир дә уңышын мул бирә.

Дөрес, монда яңа технологияләрне дә куллану өчен, бай эш тәҗрибәсе булуы да кирәк. Мин үземне белгәннән бирле, әтиемнең бар булдыгы белән җиргә бирелгәнлеген күреп, аңа булышкан чакта җир эшенең серләрен өйрәнеп үстем.



Олы малае - Ганниев Илдар

Әтием, үсмер чактан ук тракторчы һөнәрен үзләштереп, авылда иң беренче механизаторлар исәбендә булган. Тора-бара - трактор бригадасын, аннан соң комплекслы бригаданы җитәкләгән. Аның хезмәтен зурлап, район һәм өлкә тарафыннан Хөрмәт грамоталары, Куйбышев өлкәсенең күчмә Кызыл байрагы, премияләр бирелде. Ул үзе алдынгыларның эш тәртибен өйрәнсә, аның тәҗрибәсе белән уртаклашырга да халык төрле җирләрдән килде.

Мин бабамның да, һөнәр иясе булып, күп атлар, маллар тотканын һәм уңган кеше булуын беләм. Бүгенге көндә үзем һәм өч улым да, ата-бабалар үрнәгендә туган җиргә тугрылыклы булып, бар куәткә тырышып эшләп, туган авылыбызда яшибез.

Мин унөч яшемнән ук мәктәптәге каникул вакытларында олылар белән беррәттән тракторда эшли идем. Ә уналты яшьтән инде тулысынча колхоз эшенә җигелеп, киң профильле тракторчы булып эшли башладым.

Тырышып эшләвемне күреп, баш агроном Зыя абзый Ваһаҗев мине яңа технологияләр кулланып эшләргә өйрәтте. Беренчеләр булып, без элгәре кул белән эшләнгән эшләрне механизацияләүгә алындык. Мәсәлән, суган, кишер, чөгендер, кукуруз, карабодай, мәк кебек яңа культураларны чәчеп үстерә башладык.

Хәзер культивация эшләре яңа техникалардагы компьютерлар ярдәмендә башкарыла. Ә ул чакта күз чамасы белән эшләү зур осталык, төгәллек һәм аеручa җаваплылыкны таләп итә иде. Бу эштә үсемлек белән культиватор арасын киң калдырсаң – чүп баса, нәтиҗәдә уңыш югала. Ә артык якын булса – аларны кисү куркынычы яный.

Шундый катлаулы һәм җаваплы эшләр башлангач, безнең колхозда район һәм өлкә күләмендәге семинарлар үткәрелде. Башка җирләрдән дә тәҗрибә уртаклашырга киләләр иде.

Мин, яшьтән үк тәҗрибәле механизаторларның эш күрсәткечләрен уздырып, һәрвакытта иң алдынгылар исәбендә булдым. Күпсанлы мактау грамоталарына лаек булып, социалистик ярышларда җиңүче дип танылгач, премияләр, медальләр бирелде.

Югары нәтиҗәләргә ирешкән өчен, баш агроном Зыя абзый Ваһаҗевка хөкүмәт тарафыннан Хезмәт Кызыл Байрагы ордены бирелде. Безнең колхозның югары табыш алучы, бай хуҗалыкка әверелүенә ул керткән өлеш дә бик зур булды. Ул чакта, аның кебек, югары белемле, тәвәккәл, новатор агрономнар әле сирәк күренеш иде шул.

Моның өстенә, ул, халык уянганчы, көтүдән алда торып, иртәнге нарядка, бөтен кырларны әйләнеп, төгәл планнар белән кайта. Төнлә дә, комбайннар эштән туктаганчы, ул әле эштә була иде.

Новатор-белгеч һәм үз эшенең остасы буларак, ул миңа да игенче эшенең күп серләрен өйрәтте. Шуңа күрә мин аңа үз гомеремә рәхмәтле булдым.

***– Алдынгыларны матбугат чыганакларында язып, җыелышларда мактап, бүләкләр бирү – билгеле хәл. Ә менә халык арасында тирән ихтирам казану Сезгә кайдан килде?***

– Үткәндәге дәверне мин куанып искә алам. Ул чакта эштә югары уңышларга ирешү, тормышны җайлы итеп көйләү һәм авыл халкына ярдәм итеп яшәү өчен, бөтен мөмкинлекләр дә бар иде.

Авыл, район һәм өлкә советларына депутат булып сайланган чакларда, мин, кулымнан килгәнчә, халык ихтыяҗларын да исәпкә алып, аларның теләкләрен һәм үтенечләрен гамәлгә ашыру өчен дә, бар куәткә тырыштым.

Элгәре шәхси хуҗалыкларда бакча чәчү эшләре гел атлар ярдәмендә башкарыла иде. Авылга техника кайтарылып, барлык эшләр дә механизацияләнә башла-


Кече малае - Ганниев Илшат

гач, атлар саны кими торды, һәм шәхси бакча эшләрен башкару да зур проблемага әверелде. Шунда мин сөреп-чәчү һәм бәрәңгене күмү эшләрен трактор белән эшкәртүне башлап җибәрдем.

Бәлки, моңа карата күпләрнең рәхмәте миңа киләчәктә дә уңышлы эшләр башкарып яшәргә киң мөмкинлекләр биргәндер.

Колхоз производствосын индустриаль эзгә салу юлында һәм авылдагы социаль мәсьәләләрне хәл итүгә үз өлешемне кертә алуымны да мин хәзер горурланып искә алам.

Мәсәлән, авылдагы барлык эшләр механизацияләнгән чорда халыкны эш белән тәэмин итү мәсьәләсе алга баскач, сөт җитештерү комплексы төзү турында карар кабул ителде. Бу мәсьәләне хәл итү юлында миңа да, Куйбышев өлкә советы депутаты буларак, күп булышлык күрсәтергә туры килде.

Авыл читендә сөтчелек комплексы төзелгәч, иллеләп доярка караңгыда, яңгырлы-пычраклы, карлы-буранлы вакытларда җәяү йөргәндә, миңа, Куйбышев өлкәсенең авыл хуҗалыгы идарәсенә барып, колхозга махсус автобус кайтару мәсьәләсен дә хәл итәргә туры килде.



Кәрамның хатыны - Сәрия

Тора-бара колхоз производствосы алга китте. Һәр көнне унар тонна сөт җитештерелә иде. Елына йөзләгән тонна ит, күп ашлык саткач, колхоз миллионлаган табыш ала башлады. Нәтиҗәдә авыл тормышы да гөрләп торды, колхоз исәбенә күп корылышлар барды. Бу бит – башка колхозлар бурычка батып, хөкүмәт кредитлары исәбенә яшәгән чорлардагы хәл!



Ганниев Кәрам һәм кече малае Илшат

Элгәре, колхоз киң җәелгән төзелеш эшләре алып барганда, төзү материалларын булдыру да авыр мәсьәлә иде. Монда шулай ук миңа депутатлык мөмкинлекләрен кулланырга туры килде.

***– Элгәре һәм хәзер дә үзегез, балаларыгыз авылда күпләргә үрнәк булырлык тормыш алып барасыз. Моның сере нәрсәдә?***

– Мин ишле гаиләдә тугызынчы бала булып туганмын. Мондый шартларда үскән балаларның, бер-берсен тәрбияләп, эштә чыныгып, тормышка яраклашып үсүе сер түгел.

Монда мин бер нәрсәне ассызыклап үтәсем килә. Әтиебез, җиде яшеннән тулы ятим булып үскәнгә, гаҗәп тормышчан кеше иде. Ул үзе дә, эшнең рәтен белеп, батырып эшли һәм башкаларны да эшкә көйли белә иде.

Сугыш яралары, авыр елларда колхозның җимерек авыл хуҗалыгын сөйрәп бару, халыкны эшкә күндерү кыенлыклары тәэсирендәме, ул кайвакытта эчкәли дә иде. Бервакыт шуны күргән күрше апа: «Моның бер көтү баласы надан, тормышка яраксыз булып үсәр инде!» – дигән сүзләрен ишетү миңа бик нык тәэсир итте. Шуңа да мин үз гомеремә бу сүзләрнең урынсыз булуын исбатларга тырышып яшәдем. Аллаһыга шөкер, балаларым да уңган, акыллы, тәртипле һәм күпләргә үрнәк күрсәтерлек шәхесләр булдылар. Хәзер бит күп кешеләр, киресенчә, балаларын авыл проблемаларыннан коткару өчен, үзләрен тизрәк читкә җибәрү юлын карыйлар.

Аллаһыга шөкер, минем өч улым да туган авылыбызда, җир эшенә тугрылыклы булып, әле үзләренең йорт хуҗалыкларын да уңышлы алып баралар. Мондый хәл авылда да, тирә-як җирләрдә дә әлегә күренми кебек.

Дөрес, хәзер безгә бик кыен. Монда шунысы үкенечле – хәзерге авырлыкларның күбесе ясалма рәвештә тудырыла. Мәсәлән, авылга нindидер чит-ят кешеләр килеп, халык кулындагы җирләрне сатып алу өчен, актив хәрәкәт башланды. Элгәре колхозны җитәкләгән һәм башка җор телле кешеләр сәер рәвештә, өйдән-өйгә кереп, халыкны үзләренең «пай» җирләрен сатарга күндереп йөрүләр башланды. Бу хәрәкәт әле дә дәвам итә.

Хәлле кешеләрнең, үз акчасына җир алып, аны ышанычлы капиталга әйләндерү максатын аңлап

була булуын. Тик менә элгәре авыл милке булган җирләрне читләргә сатып, авылның киләчәгенә балта чабуны һәм киләчәк буыннарны җирдән мәхрүм итүне берничек тә аңлатып булмый, – дип сөйләде Кәрам Ганниев.



Ганниев Кәрамнең әтисе - Ганниев Габдулхак

Хәзер зур холдинглар, корпорацияләр кискен үсеш алып, җирләр алар кулына күчә бара. Бу очракта фермер хуҗалыкларының алар басымына каршы тора алуы – гаҗәп хәл.

Әлбәттә, мондый гаделсезлекне хөкүмәт үзе хәл итәргә тиеш. Бөтен дөньядагы илләрдә уртача бизнес һәм фермерлар эшчәнлеге даими рәвештә хөкүмәт сагында тора. Мәсәлән, Европа илләрендәге һәм Америкадагы фермерлар җитештергән продукциягә дәүләт тарафыннан 40–50% дотация бирелсә, Япониядә ул 70 процентка җитә. Алардагы урта хәлле фермерларның хөкүмәт сагында булуы дәүләт куркынычсызлыгы сәясәтенең нигезе булып тора. Бу – дөнья күләмендә сыналган, тарихи факт.

Татарлар, үз тарихында нинди генә изүләр, кимсетүләр, золымҗәберләүләр кичермәсен, меңнәрчә еллар дәвамында үз йөзен, үз бәрәкәтен югалтмыйча, тарихта сакланган халык. Милләтебез бүген дә үзен бөтен дөньяга танытып яши.

Ни кызганыч, тик халык белән аралашканда еш кына:

«Хәзер авылда пенсионерлар гына кала. Буш өйләр торган саен арта. Мәктәптә укучы балалар саны кими. Мал тотуның, җир эшкәртүнең бер файдасы юк. Бар нәрсәне дә базардан бер мәшәкатьсез алып була», – дигән сүзләре ишетелә.

Тик тормышның мондый хәтәр юлга басуын хәл итү чаралары турындагы нинди дә булса уңай фикерләр, җылы сүзләр бөтенләй дә ишетелми.

Авылыбыз тарихын барлаганда, борынгы бабаларыбызның мәхәлләэчендә барлык авыр хәлләрне бергә, киңәшеп хәл иткәннәре күренә.

Кызганычка, хәзерге таркаулыкны, үзара дошманлыкны һәм башка түбәнчел кешелек сыйфатларын булдыру юлында күп нәрсәләр эшләнде.

Тик шулай да, авыл администрациясе, авыл мәктәбе, Мәдәният йорты, социаль хезмәт күрсәтү оешмасы вәкилләре, авыл аксакаллары, мәчет картлары хәзер дә борынгылар үрнәгендә киләчәкне бергәләп кайгыртуны гадәткә кертерләр, дип ышанасы килә.

Бай традицияләре булып, үзендә татар халкын данлаган, бөек шәхесләрне тудырган авыл, үз җирләреннән мәхрүм булып, юкка чыкса – бу киләчәк алдында җинаять һәм берниндиди дога да коткара алмастай зур гөнаһ булачак.

Бу очракта Ганниевлар нәселедәй батыр хезмәт иясләренә аяк чалуны туктатып, алар кебекләрне бергә туплап, үзләренә теләктәшлек, ярдәм һәм хөрмәт күрсәтергә өйрәнүдән башларга кирәктер.

Озакламый Кәрам Ганниевның олы юбилее якынлашып килә. Бу уңайдан аңа иң изге теләкләребезне белдерәбез.

Кәрам малае Илдар белән Ярмәк Сабан туенда бүләк алгач



*Нурания Абзалова*

# БАЙТУГАННЫҢ ДАНЛЫ, ГОРУР, ТУГРЫ БЕР УЛЫ



Судьба челове

ТВОИ ЛЮДИ, СЕЛО

Вчера Равкат Акрямович Сагдеев отметил свой 85-летний юбилей. История всегда имеет человеческое лицо, и за крутыми поворотами судьбы страны стоят конкретные люди. Равкат Акрямович в числе тех, кто писал историю Большеглушицкого района, стремясь сделать жизнь окружающих лучше. Такие люди, как он, входят в "золотой" фонд района, прославляющий сельскую глубинку. Ему есть что вспомнить. И свои воспоминания он излагал в рукописях, которые бережно хранятся в архивах. По этим материалам и рассказам самого Равката Акрямовича мы и подготовили публикацию о его жизненном пути

*Елгаларның башы – чишмәләрдә,*
*Сукмакларда була юл башы,*
*Гомерләрнең башы - туган туфрак,*
*Туган нигез – күңел юлдашы.*

*Харрас Әюп.*

Әлеге шигырь юлларын бер тапкыр укып чыктым да, алар минем күңелемә мәңгелеккә сеңеп калдылар. Беренче карашка, гади генә юллар, ә аларда искиткеч тирән мәгънә саклана, бер генә артык сүз дә юк.

«Гомерләрнең башы – туган туфрак»... Чыннан да бит, ата-бабаң туган, аннан соң бу дөньяга үзең аваз салган нигезне онытып буламы соң? Юк, булмый һәм булмаячак та! Ул үзенең җиләкле аланнары, горур таулары, зифа каеннары, яшел шәл ябынган таллары, җәйге әрем исе, кышкы бураннары, ләйсән яңгырлары, челтерәп аккан чишмәләре белән һәрвакыт безнең истә булачак. Боларның барысын да искә алу читтә яшәүче ул-кызларның күңеленә сагынудан дәва була.

Туган якларын сагынып кайтучылар күп. Алар музей-йортыбыз капка төбендә урнашкан самавырдан чишмә суы алалар, истәлекләре белән уртаклашалар. Берараз күңелләренә җылылык өстәр өчен, мин аларны чәйгә чакырам, ә алар рәхәтләнеп ризалашалар.

«Безнең йортыбыз әнә шунда иде, кызганыч, әмма хәзер нигез ташлары гына калган», – диючеләр дә байтак.

Саубуллашканда күп рәхмәтләр әйтеп, «туган йортыбызда булдык сыман», диючеләр дә аз түгел.

Әйе, олы кешеләргә берни дә кирәкми, бары игътибар һәм чын күңелдән сөйләшәсөйләшә эчкән бер чынаяк чәй дә җитә.

Әниемнең: «Кызым, кайтучылар булса, беркайчан да чәй эчермичә җибәрмә. Хәзер бит өстәлдә бар да бар. Ә чит җирләрдән зарыгып, туган якларын сагынып кайтучыларга, аеруча йорт-җирләре инде таралганнарга, ул бик зур хөрмәт булачак», – дигән сүзләрен һәрчак исемдә тотам.

Мин бәләкәй чакта да бездә кótелмәгән кунаклар күп була иде. Үзләрен ашатып-эчертеп, юлга озаткач, әнием белән әбием аларның нәсел-ыруын, әби-бабаларын искә алалар иде.

Музей-йортыбызга килгән кунакларны озатканда күңелемнән генә газизләремә, сезнең изге эшегезне дәвам итәм, дип әйтеп куям.

Шулай шул, барысы да авылда кала алмый. Яшьләргә укырга, һөнәр үзләштерергә кирәк, аннан соң эшкә урнашырга. Күпләре, шул арада үз парларын табып, чит җирләрдә төпләнеп калалар.

Бездән бер йорт аша гына Мәгъшия апа Сәгъдиева әнисе Гашия әби белән яшиләр иде. Мәгъшия апа, бәләкәй балаларын кочаклап, бик яшьли тол калган. Ире Әкрәм абзый сугыштан контузия алып кайткан. 1948 елда Сок елгасында бер баланы коткарам дип керә дә, үзе дә батып үлә. Упкынга эләккән, дип сөйләде халык.

Әнием, Мәгъшия апай бик тәртипле балалар үстерде, дип, сокланып сөйли иде. Җәйге ялга янына оныклары кайта иде. Ә олы малае Рәвгат кайткач, ул күршеләрне чәй эчәргә чакыра иде.

Рәвгат абый белән хатыны Роза апаны мин яхшы хәтерлим. Алар бик чибәрләр иде. Роза апа гел чишмәдән су ташый иде. Мәгъшия апа: «Озакка кайта алмыйлар шул», – дип сыкрана иде.

Җитәкче булып эшләгән Рәвгат абыйның «бобик» машинасы да гел хәтеремдә.

Алардан чәйдән чыккач та, әнием белән әбием, сокланып: «Бигрәк кешелекле балалар үстерде инде Мәгъшия! Кара син аны, ашлык та уңган, Рәвгат тагын капчыгы белән апак кардай он кайтарган», – дип сөйлиләр иде.

– Барысы да авыллардан, этнографик экспедицияләр вакытында җыелган. Самавыр торбасы, кер тактасы, чиләк, агач кашыклар, шак-шок, бөтенесе дә – халык музыкасы кораллары. Ансамблебездә скрипкачы кызыбыз Әминә бар. Аның белән борынгы көйләрне уйнарга өйрәнәбез. Камышлы районындагы Иске Ярмәк, Чулпан авылларында элек өч скрипкачы яшәгән. Аларны белгән кешеләр аша борынгы көйләрне, скрипканы ничек итеп тотарга кирәклеген (чөнки җилкәгә түгел, терсәккә куеп уйнаганнар) сораштык, хәзер инде тамашачыга күрсәтергә әзерләнәбез.

Гомумән, этнографик сәфәрләр искиткеч файдалы, ләкин гаять күп вакытны ала торган нәрсә. Әмма сәяхәт барышында тупланган мәгълүмат, онытылып барган яки бөтенләй кулланылыштан чыккан җырлар, такмаклар, биюләр, көнкүреш кирәк-яраклары, киемнәр – татар халкының бәяләп бетергесез мәдәни мирасы бит ул.

Сүз уңаеннан, шундый бер сәфәрдән XX гасыр башында ук юкка чыккан кыл-кубыз табып кайттык. Ул казах, башкорт, төрки халыкларының музыка коралы булып санала, бик үзенчәлекле моңга ия: ике кыллы скрипканы да хәтерләтә, думбра белән дә охшаш. Аны



Гомумән, минем бер хыялым бар. Шәһәребездә үзебезнең “Татар үзәге” булсын иде. Иҗат төркемнәре анда репетицияләргә җыела, костюмнарын, уен коралларын бер урында саклый алырлар иде. Шунда ук милли музей оештырырлык, бәләкәй генә булса да, кинозал ясарлык мөмкинлек булса, искиткеч шәп булыр иде. Татар җәмәгатьчелеге вакыт-вакыт шунда очрашулар, күргәзмәләр һәм башка чаралар уздыра алыр иде.

Минем студент елларында ук башланган этнографик эзләнүләрем нәтиҗәсендә шактый милли кыйммәткә ия булган экспонатлар җыелды. Аларны, беркемгә дә күрсәтмичә, каядыр саклау “җинаять”, минемчә. Аларны шәһәр музейларына тапшырырга кулым күтәрелми, күпсанлы экспонатлар арасында “безнекеләр” югалырга мөмкин, дип куркам. Хәзерге вакытта экспедицияләр вакытында тупланган такмаклар, җырлар, биюләр төшерелгән видеоларны «Самар фольклоры үзәгенә” тапшырам. Андагы архивтан мәгълүматлар югалмаячак, һәм эшебез бушка булмаячак. Без башлаган изге эш дәвамлы булыр, дип ышанасы килә.

Форсаттан файдаланып, мине этнографик эзләнүләр белән таныштыручы мөгаллимнәрем, Самарның мәдәният университеты профессорлары – Андрей Михайлович Давыдовка һәм Тамара Ивановна Ведерниковага өлкәбез татарлары һәм шәхсән үз исемемнән зур рәхмәтләр җиткерәсем килә. Алар миндә милли культурага мәхәббәт уяттылар һәм үземнең халкым тормышына күбрәк игътибар итәргә өйрәттеләр. Бүгенге көндә дә алар миңа һәртөрле ярдәм итеп торалар.

***– Ә костюмнарны кем тегә?***

– Бу четерекле эшне Самарда яшәүче профессиональ тегүче Наталья Хәйруллинага тапшырдык. Ул, Самарның традицион рус мәдәнияте үзәге хезмәткәре булабарак, тарихи костюмнарны реконструкцияләү белән шөгыльләнә. Төбәгебезнең милли костюмнары турында өлкәнең халык сәнгате, һөнәр һәм кәсеп остасы Наталья Хәйруллинадан да яхшырак белүче юктыр, мөгаен. Ул русларның гына түгел, башка Идел буе халыкларының традицион киемнәре белән дә кызыксына.

***– Финанс чыгымнарны кем каплый?***

Исаклыда яшәүче Максим Радионов исемле оста ясап бирде. Ул борынгы уен коралларын ясау белән шөгыльләнә икән.

Башка милли уен коралларына килгәндә, курай, кубыз, тальянка, гармун, барабан һәм думбрабыз бар. Аларның барысы да – хөрмәтле Мидхәт абыебыз Әминов җыйган инструментлар. Аның осталыгы, халык музыкасына бирелгәнлеге турында сөйләп торасы да юк, дип уйлыйм. Самар өлкәсендә аны белмәгән кеше юктыр. Форсаттан файдаланып, башлангычымны хуплап, "Заман"-ны оештырырга ярдәм итүе, репе-



тицияләр уздырырга зал кайгырткаңы, аккомпаниатор булырга ризалашуы һәм бөтен буш вакытын безгә багышлавы өчен бик зур рәхмәт әйтәсем килә. Аның кебек, ихлас күңелле, ярдәмчел, эчкерсез, беркатлы кешеләр бу дөньяда бик сирәк. Ул булмаса, ансамбль җыелмас иде.

– ***Балалар белән эшләве кыен түгелме?***

– Юк-юк! Мин балаларны бик яратам. Иң зур кыенлык – тел мәсьәләсе. Күпчелек балалар туган телен чит ил теле кебек өйрәнә. Дөрес, тора-бара алар сүзләрне аңлый башлыйлар, акцент шомара. Шулай да, тел проблемасы эш барышына гел аяк чала.

Бернинди авырлыкларга да карамастан, ярты ел дигәндә "Заман" үзен Самар тамашачысына таныта да, Венера Ганиева, Илшат Шаехов кебек Татарстанның танылган сәнгать эшлеклеләренең, Казанның "Ресурслар үзәге" белгечләренең югары бәясен алырга да өлгерде. Танылган артистлар һәм этнография белгечләре бертавыштан: "Ниһаять, Самарда чын фольклор ансамбль барлыкка килде. Андый коллектив Казанда да юк әле. Ялтыр-йолтыр



кием киеп, сәхнәгә чыккан төркемнәр бихисап, ә менә халкыбыз көндәлек тормышта киеп йөргән күлмәк-камзулларын, ыштан-ыштырларын, борынгы көй-моңнарын, биюләрен эзләп табып, бүгенге заман тамашачысына җиткерүче ансамбльләр юк, диярлек. "Афәрин!" – дип "Заман" өчен куандылар һәм уңышлар теләделәр.

- "Ресурслар үзәге" этнографлары һәм белгечләре безне искиткеч җылы каршы алдылар, ансамбльнең чыгышын тын да алмыйча карап, алкышларга күмделәр, костюмнарын җентекләп тикшерделәр һәм бик тә югары бәя бирделәр. Безгә шулкадәр игътибар булыр, дип уйламаган да идек, – дип сөйли Мидхәт Әминов. – Билгеле инде, без аннан канатланып, горурланып, алга омтылырга әзер булып кайттык. Мондый үзенчәлекле, хәтта Татарстанда да булмаган уникаль фольклор төркемебез булу белән бөтен Самар халкы горурлана ала, дип уйлыйм. Безне шәһәр чараларында катнашырга чакыралар, 12–14 ноябрьдә Казанда узган «Туган тел» форумында катнаштык. Оештыручыларга бик зур рәхмәт. Ә сәхнәдә басып торган "матурлыкны" булдыру өчен, күпме көч куелган, күпме финанс чыгымнар киткән, аны без һәм ата-аналар гына белә.

Мин 25 елдан артык үзешчән ансамбль җитәкчесе булып эшлим, сәхнә арты тормышын бик яхшы беләм. Татар активистларына, милли җәмәгатьчелеккә мөрәҗәгать итеп, "Заман" ансамбленә игътибарлырак булуыгызны, кечкенә артистларга һәм җитәкчеләренә милли мәдәниятебезне саклауда ярдәм итүегезне сорыйм. Ә Вәсимәдәй "самородок"ны сакларга кирәк. Шундый яшь булуына карамастан, нинди генә эшкә алынса да, азагына кадәр башкарып чыга, кемгә генә мөрәҗәгать итсә дә, сүзе үтә, молодец! Олылар белән дә, балалар белән дә бик тиз уртак тел таба. Искиткеч талантлы (тавышы бик моңлы, берничә уен коралында уйный), милли җанлы, ару-талуны белмәс кеше ул.

Кыска вакыт эчендә ансамбльне шундый дәрәҗәгә күтәрү, таныту өчен, искиткеч тырышлык, осталык, үҗәтлек кирәк. Әгәр ансамбльгә ярдәм кулы сузучылар да булса, Вәсимә тау-ташны күчерергә дә әзер, минемчә.

БЕЛЕШМӘ

**Вәсимә Фәрдиева,** 2014 елдан башлап, татар мәдәниятен өйрәнү белән шөгыльләнә, күпсанлы халыкара һәм бөтенроссия конкурслары лауреаты, мәдәният институтының соло һәм халык җыры белгечлеге бүлеген тәмамлаган, өлкә күләмендә узган масштаблы чаралар оештыруда катнаша, спектакльләр сәхнәләштерә. Ул моңа кадәр дә, балалар ансамбле җитәкчесе буларак, зур эшчәнлек алып барды, Самарның "Яктылык" мәктәбендә, башка гомум белем бирү учреждениеләрендә, Ялтаның (Кырым) Ренат Ибраһимов исемендәге халыкара музыка мәктәбендә педагог булып эшләде. Хәзерге вакытта «The players» caver төркеме солисты булып тора.

Сорауларыгыз булса,
8 (927) 011–14–75 телефоны буенча мөрәҗәгать итә аласыз.

# КАК ОСТАНОВИТЬ ТРАВЛЮ ПО НАЦИОНАЛЬНОМУ ПРИЗНАКУ?



**Римма НУРЕТДИНОВА,**
*психолог-консультант, клинический психолог, арт-терапевт*

***Травля недопустима ни по какому признаку. Но особенно опасной она становится, когда ребенка упрекают его национальностью. Разбираемся в теме, болезненной для многих детей, родителей и учителей***

## ПЕРВЫМ ДЕЛОМ

Если ребенок услышал в своей адрес нечто обидное и посвященное национальности, то первым делом его нужно успокоить. Важно ему объяснить, что его вины в произошедшем нет.

Помочь понять, что ребенок не виноват, очень важно. Если этого не сделать или отмахнуться фразой «не слушай дураков», эти абстрактные «дураки» могут победить в эмоциональной схватке за спокойствие. Их родители, возможно, тоже не планируют обсуждать столь важные вопросы, как национальность и расизм, думая, что этому научат в школе или «такое моему даже в голову не придет».

Расскажите ребенку, что в его происхождении нет ничего постыдного. Что его национальность – это повод для гордости. Интегрируйте ребенка в национальную культуру.

Национальность – это часть нашей идентичности. Сложные эмоциональные реакции, спровоцированные травлей за внешность, имя или традиции, могут повлиять на восприятие ребенком себя самого в целом. «Я не такой, я плохой», «Я неправильный, ненавижу себя» – такие слова могут быть следствием поврежденной личной идентификации.

Расскажите ребенку, что его право – открыто утверждать, что он гордится своей национальностью, тем, что принадлежит к определенной культуре. Попытка развести «внутреннюю гордость» с внешними проявлениями идентичности может приводить к кризисам и психологическим проблемам. Стесняться говорить о том, какой вы национальности, нельзя.

Обязательно избегайте ксенофобии по отношению к другим культурным кодам и традициям. Выстраивайте рассказ на выделении уникального, не противопоставляя субъективных «хороших» и «плохих», иначе эта публикация уже понадобится родителям других детей.

## ЭТО НЕ ЯБЕДНИЧЕСТВО

Научите ребенка сразу же противостоять любым нападкам. Не нужно это терпеть и ждать систематических оскорблений.

Кто должен разбираться в подборных конфликтах? Разумеется, взрослые. Сразу же, как только случился инцидент, ребенку нужно обратиться к родителям/воспитателю/учителю/завучу/директору. Обидчику необходимо объяснить его неправоту и, возможно, наказать. От этого ребенок не станет «ябедой». Ябедничать – это жаловаться взрослым по пустякам. А в этом случае он пользуется своим правом на защиту. Помощь взрослых здесь необходима.

Администрация учебного заведения должна немедленно включиться и взять на себя ответственность за прекращение травли. Школа – это безопасное, максимально нейтральное место для каждого ребенка.

Если ситуация критическая и не подлежит исправлению, резонно будет сменить образовательное учреждение.

## НАЛОЖЕНИЕ ДВУХ ВОЛН

Может быть наложение двух волн друг на друга: с одной стороны – ксенофобия, с другой – школьная травля как давний и неприятный феномен.

Иногда кажется, что травля плоха только для того, кого обижают. Ему обидно, он расстраивается. Он не хочет ходить в школу, он даже иногда не хочет жить на свете. Да, ему действительно несладко.

Но травля – это плохо не только для пострадавшего. Если в группе людей стало можно издеваться над кем-то, если это становится правилом, если те, кто травят, думают, что так и надо, и никто их не останавливает, – это меняет

всю жизнь класса. Больше никто не может чувствовать себя в безопасности. Сегодня травят Дамира – но завтра им покажется, что Женя «не такой». Потому что здесь привыкли получать удовольствие от издевательств.

Когда человек постоянно боится, ему сложно жить. И учиться сложно, и радоваться, и дружить. Психологи проверяли: если в классе есть травля, дети в нем хуже учатся. Все дети, не только те, кого обижают!

Именно страх самому оказаться жертвой часто заставляет участвовать в травле неплохих, в общем-то, ребят. Им вроде и стыдно, и противно, и неловко, но пока они с теми, кто издевается, пока они смеются вместе со всей толпой, они чувствуют себя хоть немного, но в безопасности. «Сегодня жертва – он, а не я. И очень важно, чтобы всё так и осталось».

Заступиться еще страшней – получится, что я не со всеми, значит, и мне достанется. И, скорее всего, достанется…

Всем неприятно, но все продолжают. Потому что сложилось правило: есть те, кого травят, и есть те, кто травят. Выбирай свое место. Жизни без травли, жизни в дружном классе уже никто себе и представить не может.

Иногда, став старше, люди с болью и стыдом вспоминают, как травили кого-то в детстве. Но тогда это казалось им единственным выходом. Или они просто не понимали до конца, что происходит.

## ТРАВЛЮ НАЧИНАЮТ НЕ ОТ ХОРОШЕЙ ЖИЗНИ

Нужно понимать, что корни этих конфликтов – в психологическом неблагополучии конфликтующих. «Трудные чувства» ищут подходящую мишень. Большинство выбирает в качестве мишени тех, кто на них не похож.

Конечно, травлю начинают не от хорошей жизни. Может быть, у человека плохо на душе из-за того, что дома родители ссорятся, и ему хочется слить на кого-то свое раздражение.

Может быть, он очень хочет быть первым и главным, но не уверен, что на это у него хватит талантов, вот и изобретает такой способ самоутвердиться.

Может быть, над ним самим раньше издевались, и теперь он совсем не хочет оказаться на месте жертвы и побыстрее занимает место обидчика. Когда он вместе с приятелями обижает кого-то, он чувствует силу, защищенность, правоту. Только в эти минуты ему и хорошо, спокойно, не страшно. Поэтому хочется повторить их снова и снова.



## АДЕКВАТНЫЙ ОТВЕТ

Отвечать насилием или травлей не следует. Иногда придется признать, что в мире существуют отвратные личности, и с ними приходится жить рядом. Поэтому следует разработать адекватный ответ, способный защитить себя, и не стать постоянной целью обидчика.

Необходимо обучать детей противостоять буллингу – научить их ассертивному поведению. Это очень важный навык в любой ситуации, а в ситуации травли – просто необходимый. Это, в первую очередь, умение отстаивать свои права и границы и настаивать на своем. А также это: честное, открытое, прямое и уверенное общение; умение сказать «нет», не вызывая агрессии и сильно не расстраивая собеседника; выражение как положительных, так и отрицательных эмоций (в экологичной форме); принятие критики; уверенность в своих действиях и словах; спокойствие в трудной ситуации; самоуважение и уважение к другим людям; поиск компромисса и решения конфликтной ситуации.

Важно научить задавать обидчикам взрослые вопросы психолога: «Ты сейчас так себя ведешь, чтобы компенсировать какие-то свои проблемы?», «Ты сейчас так себя ведешь, чтобы испытать состояние, которое позволит чувствовать себя более счастливым и успешным?», «Через свое такое поведение ты надеешься стать популярнее/показать свою силу/власть, похвастаться, выглядеть лучше на фоне меня» и т. д.

***Не правильно:*** спорить («Я совсем не толстый, просто крупный»); отвечать тем же («Ты сам дурак!», «Ты сама с помойки»); делать вид, что не слышишь, но при этом краснеть и прятать глаза; делать вид, что тебе смешно, если это не так, убегать и прятаться; плакать и жаловаться; бросаться в драку и вообще пытаться непременно все это остановить.

***Правильно:*** пожать плечами («Может, и так»); улыбнуться («Я так рад, что вам весело!»); перевести внимание на обидчиков («Да, я знаю, что тебе нравится так говорить»); задать встречный вопрос («Тебе хочется так думать?»); согласиться («Да, у меня полно недостатков, ты верно заметил»); дать разрешение («Ты можешь так думать, если хочешь»).

Смысл любых правильных реакций – показать, что то, что происходит, – дело обидчиков, а не объекта насмешек. Это они что-то думают, чего-то хотят, скачут-прыгают-кричат, какие-то имеют мнения и интересы. Объект насмешек этим если и интересуешься, то из вежливости.

Поначалу обидчики могут еще больше разойтись. Попробуют кричать погромче и пообиднее. Но если гнуть свою линию, им быстро надоест. Потому что им правда нет никакого дела ни до внешнего

вида Дамира/Жени, ни до его качеств. Им хотелось получить удовольствие от его обиды и от своей власти над ним. А нет обиды – нет и власти, и смысла продолжать тоже нет.

Словом, для профилактики межэтнических (да и любых других) конфликтов нужно учить детей не только толерантности, но и вполне ясным навыкам: рефлексии и самопознанию; держать устойчивую самооценку; не впадать ни в агрессию, ни в жертвенность; правильно реагировать на негативный опыт; уверенно отстаивать собственные права, не нарушая прав других.

# ЭКСПРЕСС-ТЕСТ

Для того чтобы оценить, насколько сильно ребенок или подросток пострадал от травли по национальному признаку, можно воспользоваться экспресс-тестом. Он состоит из 6 вопросов с вариантами ответов. В каждом вопросе допускается один ответ. В конце подсчитывается общее количество баллов (возможный диапазон – от 6 до 24 баллов).

*Примечание: Если ребенок сомневается и не может сделать выбор между двумя пунктами, можно задать ему наводящие вопросы; если это не помогает определиться, можно поставить промежуточный балл, например, 2,5.*

## Как оценить результаты?

***6–12 баллов*** – ребенок или подросток достаточно неплохо справляется с ситуацией самостоятельно; вероятно, он не придает большого значения происходящему, имеет устойчивую самооценку, владеет навыками уверенного поведения, получает поддержку от сверстников. Тем не менее, важно «держать руку на пульсе» и все же провести профилактическую беседу.

***13–18 баллов*** – вероятно, травля принимает более крупные масштабы или у ребенка или подростка недостаточно собственных ресурсов для противостояния единичным нападкам. Взрослому необходимо немедленно вмешаться и провести серьезную работу с коллективом. Возможно, также «жертве» травли понадобится помощь психолога.

***19–24 балла*** – ситуация очень серьезная! Необходима длительная работа со всем коллективом, а «жертве» травли – индивидуальная работа с психологом.

**1.** Слышал ли ты обидные замечания со стороны сверстников по поводу своей национальной принадлежности?
*Нет (1 балл).*
*Да (2 балла).*

**2.** Как сильно ты расстроился (оцени по шкале от 1 до 5 баллов)?
*Совсем не расстроился (1).*
*Немного расстроился (2).*
*Это расстроило меня и напугало (3).*
*Это сильно расстроило, напугало, и я опасаюсь повторения (4).*
*Настолько сильно расстроило, напугало, что я не могу думать ни о чем другом (5).*

**3.** Как часто ты слышал обидные замечания и/или оскорбления на национальной почве?
*Один раз (1).*
*Несколько раз (2).*
*Слышу их постоянно (3).*

**4.** Кто из сверстников изменил к тебе отношение из-за твоей национальной принадлежности?
*Незначимые люди, с кем я обычно не общаюсь, чье мнение не важно (1).*
*Люди, которые и до этого плохо относились, не являющиеся авторитетом в группе (2).*
*Те, кто раньше относился хорошо, но изменил свое мнение в худшую сторону (3).*
*Те, кто и раньше плохо ко мне относился, и они имеют значительный авторитет и влияние в группе (3).*
*Многие близкие друзья от меня отвернулись (4).*

**5.** Есть ли в окружении сверстники, которые продолжают дружить и поддерживать тебя?
*Да, большинство (1).*
*Да, многие (2).*
*Да, несколько (3).*
*Да, один-два человека (4).*
*Нет (5).*

**6.** Случались ли подобные ситуации раньше?
*Нет, впервые с таким сталкиваюсь (1).*
*Да, но я быстро поставил обидчика на место (2).*
*Да, если бы не помощь взрослых, я бы не справился (3).*
*Да, меня все время кто-то обижает, я не знаю, что с этим делать (4).*
*Да, постоянно так происходит, наверное, я этого заслуживаю (5).*





*Наступает новый год, символом которого является дракон. Это очень многогранный персонаж. В данной статье мы рассмотрим некоторые представления, связанные с драконом, его образ в фольклоре разных народов.*

*Михаил Кржижевский*

# КРЫЛАТЫЙ СИМВОЛ ГОДА

Существа, напоминающие драконов, прослеживаются еще в мифологии древних народов.

В русских сказках крылатый дракон – Змей Горыныч, у которого может быть три, шесть, девять, двенадцать голов – персонаж отрицательный, с ним борются храбрые богатыри и побеждают его. Аналогичная ситуация прослеживается в фольклоре разных народов Европы, а в индийской мифологии есть змей Вритра, которого побеждает главный бог ведического пантеона Индра, о чем повествует «Ригведа».

В другой древней книге – «Авесте», являющейся священной для зороастрийцев, говорится о злом коварном драконе Дахаке, которого победил богатырь Трайтаона. На основе Дахаки возникли поверья про дракона-аждаха в фольклоре татар, башкир, казахов и многих других мусульманских народов. В одних вариантах он прилетает из-за далеких гор, в других живет в водоемах со стоячей водой, но обычно приносит вред – глотает или всех подряд, или требует в жертву красивых девушек. В сказаниях разных народов есть богатыри, победившие указанного дракона. Иногда аждаха приносит и пользу – сторожит спрятанные сокровища по просьбе их хозяина, а потом возвращает ему их в указанный срок.

Совсем другим является дракон в традиционной китайской культуре, а также в культуре стран, испытавших сильное китайское влияние. Здесь это доброе существо, где бы он ни обитал – в водоеме или в пещере. О добрых драконах повествуют местные легенды и сказки. Одна из китайских сказок называется «Глаза дракона». В ней рассказывается о том, как бедный человек Цуй Хэй-цзы подобрал маленького дракона, выкормил и вырастил его, а затем отправил жить в отдаленную пещеру. Впоследствии этот человек перестал быть добрым и стал, как говорится, злоупотреблять своим положением – обращался к дракону с разными просьбами, напоминая при этом, что когда-то помог ему. Так, Цуй попросил дракона отдать ему женьшень, который рос около указанной пещеры. Все это, однако, было еще ничего, но вот у императрицы заболели глаза и было объявлено, что исцелить ее может только глаз дракона. Император обещал должность министра тому, кто принесет такой глаз. Жадный, корыстный Цуй отправился к дракону и уговорил того пожертвовать глазом, вновь напомнив ему о своей былой доброте. Так этот человек стал министром и принялся притеснять народ. Однажды он, подобно старухе из «Сказки о рыбаке и рыбке» Пушкина, совсем потерял

рассудок из-за алчности и пришел к дракону с требованием отдать ему и второй глаз – пришлось дракону его съесть, поскольку всякому терпению приходит когда-нибудь предел.

Среди высоких гор, по соседству с Индией и Непалом, расположился Бутан – один из последних экзотических уголков, который и сегодня посещает немного туристов в силу его труднодоступности и высокий платы за пребывание в стране. Живут здесь разные этнические группы, наиболее многочисленной из которых является бхотия. Они называют свою страну Друк-Юл – «земля дракона», изображения этого существа можно встретить там повсюду.

В Юго-Восточной Азии находится Вьетнам. Как и соседние государства, он многоэтничен. Основной национальностью Вьетнама являются вьеты (кинь), по имени которой страна получила свое название.

Ронг – вьетнамский дракон – считается здесь, как и в Китае и других соседних странах,



добрым, полезным существом. Он может жить в водоеме, пещере, на небесах. Дракон, приносящий дождь, в прошлом символизировал правящего монарха, а также силу и процветание народа. Во время традиционного новогоднего праздника Тэт устраиваются шествия с изображением дракона.

Вернемся в наши края, в Поволжье.

Скульптурный памятник дракону установлен на месте поселения волжских булгар в Елабуге – об этом уже писалось в нашем журнале.

В легендах об основании Казани также говорится о крылатом драконе, который обитал под землей. По одной из версий, он до сих пор живет в озере Кабан.

Здесь следует отметить, что образ дракона является в татарском фольклоре неоднозначным. Помимо указанного отрицательного персонажа аждаха в татарских сказках есть Белый змей шахмара, который помогает героям. Символом Казани стал крылатый змей-дракон Зилант – в литературе есть упоминание о том, что этот образ восходит к временам Волжской Булгарии. После взятия города войсками Ивана Грозного изображение такого змея было включено в царскую печать. В XVIII веке, при императрице Екатерине II, был утвержден герб Казанского наместничества с изображением дракона. На основе этого герба возник герб современной Казани. Символом этого города признан дракон, олицетворяющий такие качества, как мощь, величие, мудрость, а также бессмертие и вечное возрождение. Изображения дракона встречаются в разных местах в Казани.



Так что в Республике Татарстан изображений дракона немало. Статуи, запечатлевшие подобные персонажи, есть и в нашей области – в комплексе «Замок Гарибальди», находящемся в селе Хрящевка и воссоздающем атмосферу средневековой Европы.

Что послужило основой для подобных легенд и сказаний? Наверняка кости вымерших динозавров, которые находили в разные времена. А, может быть, также и встречи с живыми существами – похожими, но менее крупные. Называют же иногда варана с острова Комодо драконом!

В джунглях Юго-Восточной Азии обитают ящерицы, получившие название летучих драконов. От других ящериц они отличаются широкими кожными складками по бокам, которые во время прыжка раскрываются и позволяют этим существам планировать по воздуху на десятки метров. Хоть эти ящерицы и невелики ростом – взрослое существо достигает в длину немногим более 20 сантиметров, но все они – настоящие живые драконы, и притом крылатые.

На представления о драконах непосредственно повлиял и культ змей – этому будут посвящены другие статьи.



*Приближается Новый год – праздник, любимый и детьми, и взрослыми, объединяющий всех членов семьи. В этой связи стоит вспомнить о некоторых семейных традициях башкир – наиболее близкого по культуре народа к татарам.*

*Михаил Кржижевский*

# О НЕКОТОРЫХ ОСОБЕННОСТЯХ БАШКИРСКИХ СВАДЕБНЫХ ТРАДИЦИЙ В ПРОШЛОМ И НАСТОЯЩЕМ

Как известно, знакомство с традициями своего народа, приобщение к родной культуре обычно начинается в семье. Семейно-брачные обычаи являются важной составной частью традиционной духовной культуры любого народа. Их изучение представляет большой интерес не только для этнографов, но и для руководителей и активистов национально-культурных объединений – организаторов и участников различных мероприятий, направленных на сохранение и поддержание традиционной культуры своего этноса.

Семейно-брачные обряды башкир представляются достаточно изученными. Их описание встречается в фундаментальном исследовании С.И. Руденко, посвященном этнической истории и особенностям культуры башкир, к которому часто обращаются на страницах нашего журнала. Традиции семьи и брака подробно исследовал башкирский этнограф Н.В. Бикбулатов – сам родом из Челябинской области, объездивший много башкирских поселений. Особенности свадебного фольклора обстоятельно описала Р.А. Султангареева. О башкирской свадьбе много писала Ф.Г. Галиева – одна ее статья, например, посвящена специфическим чертам башкирской свадьбы в условиях современности.

Вместе с тем, данные обряды, подобно другим, имеют свою локальную специфику и разных групп башкирского населения. В данной статье автор использовал материалы полевых исследований, проведенных в разные годы среди башкир Самарской области.

Как и в других местах расселения башкир, здесь свадьба состояла из трех основных этапов. Каждый из этих этапов включал в себя целый комплекс ритуалов. Первый этап – сватовство, когда отец жениха посылал сватов к родителям предполагаемой невесты и в случае согласия стороны договаривались о свадебных расходах, калыме за невесту и о приданом

невесты. Второй этап – обряд бракосочетания, назначаемый после уплаты женихом большей части калыма и проходивший в доме невесты. Третий этап – собственно свадьба. Она устраивалась после полной выплаты калыма и сначала проходила в доме невесты. Традиционная свадьба сопровождалась пиром и всевозможными состязаниями. Затем молодая жена покидала родительский дом, а ее отъезд сопровождался исполнением песен и обрядовых причитаний – сенляу, многие из которых имеют местное происхождение.



Обычно девушек выдавали замуж с их согласия. Молодые люди обоих полов, даже если они жили в разных деревнях, часто встречались на праздниках, во время проведения игр и т. д. Все это способствовало укреплению знакомств и возникновению взаимных чувств. В некоторых фольклорных произведениях говорится даже о том, что девушки из знатных родов сами выбирали себе женихов. Так, различные варианты эпоса «Алпамыша» бытовали у разных групп башкир, в том числе у самарских. Главной героиней этого эпоса является дочь Айляр-хана по имени Барсынхылу – красавица, которую в эпосе называют подобной Солнцу и Луне. Кроме того, она была умной, прилежной и к тому же с детских лет считалась настоящей богатыршей и побеждала в борьбе многих мужчин-батыров. Барсынхылу решила сама выбрать себе жениха. Девушка гордо заявила отцу, что не пойдет замуж ни за хана, ни за другого знатного человека, а выйдет только за того, кто сможет одолеть ее в борьбе. Многие пытались состязаться с Барсынхылу, но девушка побеждала каждого. Лишь могучий прославленный батыр по имени Алпамыша сумел одержать над ней победу и взять красавицу Барсынхылу в жены. Впоследствии, правда, она помогла своему мужу выбраться из плена, что в какой-то мере явилось ее реваншем за поражение в состязании.




Вместе с тем жители башкирских поселений Самарской области отмечают, что иногда родители все же выдавали замуж дочерей без их согласия. Так, одна местная жительница рассказала автору о том, как в середине прошлого века мать выдала ее замуж за человека, которого она прежде никогда не видела, и поэтому вначале не хотела выходить за него. Случалось и так, что на смотрины приводили не саму невесту, а ее младшую сестру, отличавшуюся большей красотой, поскольку, согласно традиции, старшая сестра должна выйти замуж раньше младшей. Во время свадебного пира невеста была с закрытым лицом, поэтому подмена обнаруживалась слишком поздно…

В башкирских селах Самарского края значительную роль в обрядах брачного цикла играли дети. Так, во время посещения женихом невесты они в шутку утаскивали у него обувь, а потом возвращали за подарки. Дети пели на свадьбах, участвовали в играх «ак тирек» («белый тополь») и других. Эти традиции сохраняются и сейчас.

Среди послесвадебных обрядов и сегодня большое значение имеет обряд хождения за водой, совершаемый молодой женой на второй день после переезда в дом мужа. Она должна была прийти с ведрами и с коромыслом к водному источнику, которым пользовалась семья мужа, набрать воды и аккуратно принести ее в дом мужа, ставший и ее домом. Проливать воду нельзя – иначе семья будет несчастливой. И сейчас этот обряд соблюдается самарскими башкирами, правда, за водой обычно ходят теперь не к естественному водоему, а находящемуся поблизости колодцу или даже к колонке. Обычно на территории области башкирские парни женятся на девушках из других деревень, в чем прослеживается отголосок традиции брать жену из другого башкирского племени, хотя сегодня в одном и том же поселении проживают представители разных башкирских племен и родов.

Наряду с браками, заключавшимися с соблюдением всех вышеупомянутых традиций, имели место так называемые «браки уволоком», происходившие в результате похищения невесты. Иногда такое похищение, как пишут исследователи, происходило даже без ведома девушки, но чаще она давала согласие. Причиной похищения обычно служило нежелание родителей девушки выдавать ее замуж за данного юношу (до революции это часто мотивировалось принадлежностью юноши к более бедному слою населения), а также слишком большой калым, запрашиваемый за невесту. Обычай похищения существовал и у самарских башкир: по свидетельству стариков, для жениха считалось более престижным похитить невесту, нежели жениться путем официального соглашения. Исследователи указывают, что такой обычай существовал у башкир и в начале XX в. После похищения родители девушки были вынуждены согласиться на брак, и свадьба проходила по упрощенному образцу.



О практике похищения невест повествует также художественная литература. В романе известной башкирской писательницы Х.Л. Давлетшиной «Иргиз» события разворачиваются в башкирских поселениях Самарского края в начале XX в. Главному герою романа – простому труженику Айбулату его старший брат Котлояр предложил похитить любимую девушку – дочь местного богатея.

Подобный обычай существовал и у соседних народов многонациональной Самарской области – например, у татар и чувашей.

В прошлом у башкир существовал обычай левирата, когда после смерти мужа его вдова становилась женой младшего брата мужа или его племянника. Не случайно младший брат мог иногда назвать жену своего старшего брата «запасная», что также нашло отражение в литературе. В песенном творчестве башкир также содержатся сведения о левирате. Такой песней является песня под названием «Шаура», известная в различных вариантах разным группам башкир, в том числе жителям Самарской области. Легенда к этой песне рассказывает об упомянутом выше обычае.

Уже давно «браки уволоком» и обычай левирата ушли в прошлое, так же как и обычай выплачивать калым, хотя сохранилась традиция вручения невесте подарка (махр или мэхэр) со стороны родителей жениха.

На башкирской свадьбе можно увидеть традиционные танцы, услышать национальные песни, попробовать блюда этнической кухни.

Башкиры Самарского края, как и жители других регионов, обычно вступали в брак с представителями своего народа, иногда с соседями-мусульманами – казахами и татарами. Сегодня также заключаются браки с русскими, чувашами и другими народами нашей многонациональной страны. Дети в таких семьях приобщаются к традициям как материнского, так и отцовского этноса. Все это способствует взаимодействию культур в регионе, в том числе взаимовлиянию семейно-брачных традиций.

# Наилә Хөсәенова: “ШИГЫРЬЛӘРЕМ, СЕЗГӘ МИН ҖАН ӨРДЕМ...”

***Әйе, Наилә апа, шигырьләрен нарасыйлардай күреп, аларны назлап үстерә. Шагыйрәнең шигырьләре кәгазьгә генә язылып калмыйлар, алар, аның хис-тойгылары аша үтеп, җанланалар.***

*Миләүшә ГАЗЫЙМ*



Иҗат җимешләрендәге “Мин – авыл баласы”, дигән юллары бу ханымның туган ягы – Ульян өлкәсе, Иске Мастяк авылы турында язган шигырьләренә шигарь (девиз) булып тора. Өзелеп ярата ул туган авылын, аның халкын!

Иске Мастякның сихри табигате бишегендә тибрәлеп үскән Наилә ханым туган җиренә мәдхия җырлый, аңа соклана, гомере буе аны сагынып яши. Туганнарын, күршеләрен кадерли, зурлый.

Ана теле, милләт, әхлак, тәрбия, тарих – төрледән-төрле шундый темалардан торган киңкырлы иҗатны зыялы ханым гына булдыра ала. Медицина белгече булып, шушы өлкәдә 25 ел хезмәт иткәнен белгәч, ә поэзиягә таланты кайдан барлыкка килде икән, дип гаҗәпләнергә мөмкиннәр. Сере гади. Аның күңеле хисләрдән һәм моңнан тукылган, тамырларында дәрт-дәрманлы татар каны ага.

Наилә Хөсәенова - соклануга лаек ханым. Ул, иң беренче чиратта, шәхес, аннары гына шагыйрә, язучы. Иренә тугры хатын, улларына – яхшы ана, оныкларына – үрнәк әби.

Декабрь аенда Наилә апа 65 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Иҗат чишмәгез саекмасын, кадерле Наилә ханым!

Түбәндә шагыйрәнең кышкы темага багышланган иҗат җимешләрен тәкъдим итәбез.

## *Буран җырлый үз көйләрен*

*Буран җырлый бүген үз көйләрен,*
*Карлар ява иркә, җилбәзәк.*
*Ике якта язмыш сөргәннәргә*
*Нинди ялкын тагын соң кирәк?*

*Ап-ак карлар чолгый сыныбызны,*
*Урый-урый безне ак төскә.*
*Күңелләр дә кире кайтты бүген*
*Онытылып барган ак хискә.*

*Икебез дә озак еллар инде*
*Давыл, җилләр аша үткәнбез.*
*Туган тойгыларны әле яшерәлми,*
*Ниләр күтеп икән яшибез?*

*Рәхмәт, язмыш, бер генә кич*
*Кайтарсаң да безгә үткәннән.*
*Ике бала кебек, җитәкләшеп,*
*Без йөредек хисләр чигеннән.*

*Ә хәзер мин, үз-үземне онытып,*
*Йомшак ак карларга уралам.*
*Күзләреңдә бәхет төсе күреп,*
*Назлы кочагыңда югалам.*

## *Табигатьнең төнге җыры*

*Кышкы төн... Тәрәзәгә карап*
*Утырамын пәрдә артыннан.*
*Тынган авыл... Әллә инде ул да*
*Буран улавыннан куркынган.*

*Усал җилләр карны урый-урый*
*Өеп куя өйләр өстенә.*
*Кар таулары булып йортлар калган,*
*Җемелдәшә “күзләре” генә.*

*Җанга рәхәт җылы өйдә миңа,*
*Тыңлап торам морҗа улавын,*
*Мич астына качкан чикерткәгә*
*Песиемнең кушылып мырлавын.*

*Тышта суык, өйдә мич кабызган,*
*Сикерә утның кызыл телләре.*
*Шартлап өйнең бүрәнәсе туңа,*
*Тынып калган чана эзләре.*

*Сирәк кенә эт тавышы кушыла*
*Табигатьнең төнге җырына.*
*Ә мин һаман гашыйк булып карыйм*
*Сихерләнгән кышның юлына...*



## *Хуш кил әле, Яңа ел!*

*Акбүз аттай атлап, Яңа елым,*
*Хуш кил әле, үт син түрләргә.*
*Синең белән без бәйлибез бүген*
*Якты көннәр алда үтәргә.*

*Алып килче ап-ак карың белән*
*Җир йөзенә тыныч иртәләр.*
*Дуслык чәчәк атсын Җир йөзендә,*
*Калыкмасын һич тә киртәләр.*

*Куанычлар өстәп адәм күңеленә,*
*Иман нуры иңсен Күкләрдән.*
*Табын тулы ризык Раббым бирсен,*
*Ямь табылсын эшләп яшәүдән.*

*Җил тузгытып, көмеш юлдан атлап,*
*Чылтырат син бәхет моңнарын.*
*Яңа елга өмет белән керик,*
*Теләкләрнең теләп зурларын.*

## *Кышкы әкият*

*Яңа елда, Җирне акка күмеп,*
*Канатларын җәеп, сихерләп,*
*Йомшак кар ява, табигатьне кочып,*
*Энҗе юрган ябып, кадерләп.*

*Назлы җил дә, әкрен генә исеп,*
*Җирне үбеп, карны иркәли.*
*Әйтерсең лә алар, бер җай табып,*
*Кышкы җырны бергәләп көйли.*

*Энҗе кар бөртеге куна керфегенә*
*Ак каенның, бизәп карашын.*
*Төз имәнне сынап җиле өрә,*
*Бозга күмеп инеш агышын.*

*Болыт арасыннан, шаян күзен кысып,*
*Тылсымлы ай юллый сәламне.*
*Якты йолдызларны як-ягына җыеп,*
*Могҗизадай нурлый галәмне.*

*Буран, алып китеп балачакка,*
*Текә таудан чана шудыра.*
*Хисләр аша, эретеп кочагында,*
*Яшьлек төне учак кабыза.*

*Аяк астында шыгырдаган ак кар*
*Әкият сөйли ялгыз юлчыга.*
*Чыршы тирәсенә җыелганнар төсле*
*Әулияләр чынга ашарга.*

*Түзеп кара шушы матурлыкны*
*Күзәтергә тәрәз артыннан.*
*Кулдан тотып, күңел алып китте*
*Энҗе сипкән чана юлыннан...*

## *Күз алдымнан китмисең, балачак*

*Җил үкереп елый. Ачык капка*
*Шыгырдап сыкрый кебек суыктан.*
*Әллә кайда усал бүре улый,*
*Нидер сизеп шушы шомлыктан.*

*Тышта кышның зәһәр төне,*
*Өйдә җылы, мич яккан.*
*Тәбәнәк өй түшәменә*
*Керосин лапмасы таккан.*

*Балчык өйнең тәрәзәсен*
*Кыш бизәп, пәрдә таккан.*
*Төнге күктән якты ай*
*Ызбага нур тараткан.*

*Ишек ачыла. Әнкәй керә.*
*Кулындагы чиләктән*
*Сөтнең хуш исен сизәм,*
*Аң җуярлык шул истән.*

*Мич каршындагы почмакта*
*Сөт көтә нәни бозау.*
*Сарык, кәҗә бәтиләре,*
*Песи дә тора уяу.*

*Аклап куйган мич башында*
*Морҗа сызгырган моңга*
*Әбием кушылып сөйләгән әкият*
*Ашарга тора чынга.*

*Күз каршымнан үтеп китә*
*Җен, пәри, әулияләр.*
*Басмадагы Су анасы,*
*Урманда – Шүрәлеләр...*

*Әкият булып истә калган*
*Ул сөйләгән чал чорлар.*
*Ачлык, сугыш, үлән ашап*
*Үткәргән авыр еллар.*

*Кочагына кысып, үбеп маңгаемнан,*
*Бар уйларны юрап яхшыга,*
*Дога укып, китә идек икәү*
*Мич башында татлы йокыга.*

*Әле дә булса бу хатирә*
*Күңелдән югалмаган.*
*Сәлам башлы өй эчендә,*
*Балачакта тик калган...*

## Өч җен күрдем...

Яңа ел җитәр алдыннан яшьлектә булган бер хәл искә төште. Туган авылыма каладан кунакка кайткан идем. Иртүк мунча ягып җибәрдем. Монысы әле мунчаны җылытыр өчен генә. Кичкә табан ныклап яктым. 31нә каршы рәхәтләнеп юынып чыгарга уйладым. Әбием белән әнием үзләрен шундый сабыр тоталар, ә минем, юынып, чәчләр киптереп, клубка тансага чабасы бар бит!

Түтәне, әчесе беткәндер инде, дип, әнкәйнең теңкәсенә тиеп беттем. Ул мунчаны тикшереп кайтты да, барсаң ярый, дип, кулыма сөлге тоттырды. «Курыксаң, син юынганда, мунча ишегалдында утырып торырмын», - дип тә өстәп куйды.

«Син нәрсә инде, нидән куркыйм, мунча тәрәзәсе өй тәрәзәсенә карап тора бит, аннары, юк-бар хорафатларга ышанмыйм мин», - дип, кул селтәдем.

Мунча ишегалдында керәчин лампасын кабыздым да эчкә кереп киттем. Лампаның яктысы сәкегә төште, ә анда...

Күз алларым караңгыланып китте. Нәкъ сәкенең уртасында чәчәкле, чуклы күлмәкләргә киенгән өч хатын утыра.

Алар үзара нидер сөйләшәләр кебек тоелды миңа. Шул мизгелдә хәлем китте, кулымдагы лампа төште, кычкырып җибәреп, өйгә атылдым.

Әбием белән әнием, сикереп торып, ни булды, дип, мине тынычландырырга тотындылар.

«Анда сәкедә өч шайтан хатыны юына», - дип итәкләренә башымны куйдым да үксеп елыйм.

Әбием, башымны сыйпый-сыйпый, мунчага өч мендәрне киптерергә куйганын әйтте. Алырга онытканн икән. Ул, догалар укып, мине озаклап өшкерде. Аннары өчәүләп мунча кердек. Кайткач, бал белән чәй эчтек. Тансага бару теләгем югалды.

Озак кына сөйләшеп утыргач, әни урынымны җәйде. Ә мин, үз караватыма ятмыйча, әби белән әниемнең уртасына кереп ятып, изрәп йокыга киттем.

Бик озак еллар, авылга кайтып, мунча керергә баргач, иң элек, теге "өч җен" утырган сәкегә карый торган булдым.

# КАР БӨРТЕГЕ, КУН КУЛГА...

***Ак кар бөртекләре әйләнә-әйләнә, әкрен генә җиргә төшә. Урамда аклык, пакьлек, сихри тынлык. Мондый көнне өйдә утырып буламы соң? Саф һавага чыгып, йөгерәсе, дуслар белән уйныйсы, чана шуасы, кар бабалары әвәлисе килә! Киемгә, бияләйгә төшкән кар бөртекләренә сокланасың: гаҗәеп матур алар, кояш яктысында җемелдәп торалар, карап туймаслык! Нәкъ Шәукәт Галиев шигырендәгечә: «Кар бөртеге, кун кулга, бераз ял ит син шунда», дип әйтәсе килә.***

***Гөлназ Таипова әзерләде***

Шәукәт Галиев

## КАР БӨРТЕГЕ

Кар бөртеге,
Кун кулга,
Бераз ял ит
Син шунда.
Бер карасам,
Гел боз син,
Бер карасам,
Йолдыз син.
Искитәрлек,
Матур син.
Ничек җирдә
Ятарсың?
Ашыкмачы,
Очынма!
...Кар бөртеге
Учыма
Төште дә
Бөтерелеп,
Мактаудан
Бетте эреп.



Әминә Бикчәнтәева

## БУРАНДА

Тышта ыжгырып
Җил-буран дулый,
Күзеңне ачып,
Карап та булмый.
Шундый буранда
Нәни энесен
Бакчага илтә
Апасы Гөлсем.
– Курыкма, энем,
Җилдән-бураннан,
Батырлык яхшы
Куркак булганнан.

Фирая Зыятдинова

## АЙНУР ҮПКӘЛӘДЕ...

Ап-ак кына, йомшак кына
Кар явып киткән кичтән.
Мондый матур, йомшак карны
Ул көтә иде күптән.
Тәгәрәтеп җепшек карны,
Ясап куйдык Кар бабай!
Менә, малай, бабай инде –
Бар бабайларга бабай!
Иртәгесен Айнур, торып,
Тәрәзәгә караса,
Кар бабайдан җилләр искән –
Эреп беткән ләбаса!
Айнур аңа үпкәләде –
Үзен ташлап киткәнгә...
«Чын кыш түгел икән лә бу, –
«Алдакчы» кыш икән лә!



Җәүдәт Дәрзаман

## ҖЕПШЕК КӨНДӘ

Бүген иртән көн җепшеткән,
Кар явып үткән иде.
Без, малайлар, мондый көнне
Зарыгып көткән идек.

Йөгереп чыктык урамга, –
Кар атышып уйнадык.
И уйнадык, и уйнадык,
Тик барыбер туймадык.

- Әйдә, - диде шунда кемдер,
- Кар бабай ясыйк бергә!
Вил чапты кишер алырга,
Нил йөгерде күмергә.

Ә дигәнче үсте бабай -
Үзебездән дә биек.
Эчкә сыймый шатлыгыбыз –
Киттек тирәли биеп.

Күмер күзләр янып тора,
Тап-таман чиләк бүрек.
Кар бабабыз җанлы кебек,
Китеп бармасын берүк.

Абдулла Алиш

# КУЯН КЫЗЫ

Бер соры куянның үзе төсле зур колаклы, бик иркә, бик кадерле бер кызы булган. Ул аны бик-бик ярата икән.

Көннәрдән беркөнне куян иркә кызына өр-яңа киез итекләр алып кайтып биргән.

– Мә, бәбкәм, аякларың туңмасын, сызламасын, – дигән.

Кызы бу бүләкне бик шатланып алган. Әнисенә рәхмәтләр укыган. Хәзер инде ул, яңа киез итекләрне киеп, рәхәтләнеп йөри икән. Ләкин куян кызы җылы итекләргә өйрәнмәгән булган, ул алардан бик тиз туйган, салып ташлаган. Әнием тапмасын дип, аларны яшереп куйган. Әнисе аларны эзләп табып, баласына кигезә, ә ул салып ташлый икән. Әнисе кигезсә – ул салган, әнисе тагын кигезгән, ә ул тагын салып ташлаган.

Кар өстеннән дә, боз өстеннән дә яланаяк йөгерә икән. Бер көн буе шулай йөгергән, икенче көнне дә шулай яланаяк йөргән, өченче көнне инде аксый-аксый әнисе янына килгән.

– Әни, әни, минем аягым бик авырта! – дигән. Әнисе аның аякларына караган да аптырап калган.

– Кызым, кызым, якты йолдызым, синең аягың шешкән ич, – дигән.

«Инде ни эшләргә?» – дип уйга баткан куян. «Бу баланы кая алып барырга, ничек дәваларга?» – дип кайгырган.

Шулвакыт нәрсәдер кычкырган. Куян агач башына күтәрелеп караган икән - тиенне күргән. Ул куянга болай дигән:

– Кайгырма, туганкай, йомшак куянкай, кызыңның аягын бик тиз төзәтеп була. Моның өчен «доктор Айболит»ка барырга, аңардан киңәш сорарга кирәк, – дигән.

Куянга чын-чынлап булышырга тотынган, «доктор Айболит»ның өенә үзе илтәргә булган.

Куян кызын күтәргән дә «Айболит доктор»га киткән, тиен, агачтан агачка сикереп, аңа юл өйрәткән.

Барып җитсәләр, «доктор Айболит»ның эше бик күп икән, аңа урманның төрле ерткычлары дәваланырга килгәннәр. «Балаларны чиратсыз карыйм мин», – дигән «доктор Айболит». Куян кызын доктор бүлмәсенә алып кергәннәр, нәрсә белән авыруын сөйләп биргәннәр. «Доктор Айболит» куян кызының аягына дарулар сөрткән һәм шулвакытта куян кызына:

– Аягың төзәлгәч, киез итекләрне инде салкын көннәрдә бер дә салма, сүзне тыңла, тагын начар хәлгә калма, – дигән.

«Доктор Айболит»ка алар бик зур рәхмәтләр әйткәннәр, саубуллашып, өйләренә кайтып киткәннәр. Өч көн дигәндә, куян баласының аягы төзәлгән. Ул инде хәзер киез итеген бер дә салмыйча киеп йөри икән.



# ТАБЫШМАКЛАР

Тышка куйдым – таш булды,
Өйгә керттем – су булды.
Инде нихәл итәрмен,
Утка куйдым – пар булды.
*(Боз)*





Баш–аягы булмаса да,
Үзен кирәк саныйлар.
Бик яратканга сабыйлар,
Кышын кулдан салмыйлар.
*(Бияләй)*

Ике агай тездән,
Калышмыйлар бездән.
*(Ишек)*

Йолдыз, йолдыз вак кына,
Яфраклары ак кына.
Өс киемеңә куна,
Тәнгә тисә – су була
*(Кар бөртеге)*





# Пирог «Бялиш Кайнар»




Подготовила Гюзэль Абдрафигова

## Ингредиенты:

Тесто:

- Сметана . . . . . . . . . . 2 ст. л.
- Маргарин . . . . . . . . . 200 г
- Яйцо. . . . . . . . . . . . . . . . 1 шт.
- Соль, сахар по вкусу
- Сода, гашенная уксусом . . . . . . . . . 1/2 ч. л.
- Мука

Начинка

- Творог . . . . . . . . . . . . 500 г
- Яйцо . . . . . . . . . . . . . . 5 шт.
- Рис (крупа) . . . . . . . 1/2 ст.
- Манка (крупа) . . . 2 ст. л.
- Масло сливочное . 150 г
- Соль . . чуть менее 1 ч. л.
- Сахар . . . . . . . . . . . . . . 2 ч. л.

## Рецепт приготовления:

Ингридиенты простого теста на сметане смешать без долгого вымешивания, поместить в холодильник на 25 мин.

Для начинки сварить рис до готовности, остудить. Творог перетереть через сито, перемешать до однородности с яйцами и солью. Добавить свареный рис и растопленное сливочное масло, скорректировать соль. Жидкую начинку из влажного творога можно подправить добавлением манки. Для жирного рыночного творога можно уменьшить количество сливочного масла. Начинка готова.

Охлажденное тесто разделить на две неравные части. Большую часть раскатать до толщины 5 мм





и выложить в формы так, чтоб свисали края. Выложить начинку и уплотнить. Из второй меньшей части теста раскатать пласт, ориентируясь на диаметн формы и накрыть начинку. Края защепить и сделать в центре надрез для выхода пара. Выпекать в предварительно разогретой до 180 °С духовке примерно 40-50 минут. Пирог получается очень нежный, поэтому желательна разъемная форма.

Подавать можно как теплым, так и холодным. Приятного аппетита!

